Безнең МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

10

октябрь 2019

ISSN:2500-011X

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС һӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

НИКОЛАЙ ИНДЮХОВ «КӨЗГЕ ТЫНЛЫК»

КАЗАНГА ШӘЕХ КИЛДЕ

Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең Ислам эшләре һәм иганәчелек буенча баш идарәсенең рәисе шәех, доктор Мөхәммәд Матар Сәлим бин Абид Әл Кәгъби Татарстан Республикасы башкаласы Казанга килде. ТР мөселманнары Диния нәзарәтендә булган очрашуда Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, мөфтинең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин, мөфтинең мәгълүмати сәясәт буенча киңәшчесе, «Хозур» нәшрият йорты җитәкчесе Ришат Хәмидуллин, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Аксакаллар шурасы рәисе Айрат хәзрәт Әюпов, нәзарәтнең аппарат җитәкчесе Фәрит Вәлиев, Татарстанның Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендәге даими вәкиле Тимур Хәйретдинов һәм башкалар катнашты.

Фотолар dumrt.ru сайтыннан алынды

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең Мирас 12 +

10 (310)

октябрь 2019

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

96

48 **ШӘҖӘРӘ КАПКАСЫН АЧУЧЫ...** *Фәузия Бәйрәмова*



84 **КЕМ УЛ – КАРӘХМӘТ?** *Фатиһ Кутлу*

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 **Әхмәт Саттар**

ТАРИХИ МИРАС

4 **Сөембикә.** *О.Иванова*
14 **Этрусклар – Рим остазлары.** *С.Шәмси*
21 **Хәтер көне**. *Х.Бәдигый*
22 **Кем ул Лотфи Исхакый?** *Ч.Сафиулла*
26 **1920 нче еллардагы татар рухи тормышы.** *И.Таһиров*
32 **Археографик көндәлек.** *М.Госманов*
39 **Төрк тарихына бер караш.** *Н.Каштанов*
42 **«Курчак уйнар идем менә».** *М.Фәйзи*

ТАТАР ГАМЕ

48 **Шәҗәрә капкасын ачучы...** *Ф.Бәйрәмова*
54 **Туган ил каян башлана?** *Э.Шәрифуллина*
59 **Сәнгатьчә дә, тарихи да...** *Ә.Шәрипов*
64 **И, бөек китап...** *Н.Гыйләҗева*

ТӨРКИ ДӨНЬЯ

66 **Хикмәтле сүз.** *Абай*

ДИНИ МИРАС

68 **Ислам дөньясы.** *Габдерәшит Ибраһимов*

ӘДӘБИ МИРАС

74 **Хөсәен мирза.** *Ф.Бурнаш*
82 **Кем ул – Карәхмәт?** *Ф.Кутлу*

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН

91 **Гомәр Бәширов көндәлегеннән**

ХӘТЕР САНДЫГЫ

94 **Бер рәсем тарихы.** *Ә.Зарипов*

96 **Сурәтле хатирә**
98 **Мәктәпләр һәм сабакташлар.** *Л.Лерон*
102 **Истә, һаман да истә!**

СӘНГАТИ МИРАС

104 **Нәдер, Гали абый, Мингали Исламович...** *Ә.Зарипов*
107 **Борынгы татар милли музыка уен кораллары.** *Р.Гыйләҗев*

ХӘТЕР САГЫНДА

113 **Татарстан Республикасының Милли китапханәсе**

116 **«Безнең мирас» хәбәрләре**
118 **Мирасворд**
119 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Октябрь*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов
Лотфулла Шәфигуллин

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-93)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-93)

Бүлек мөхәррире
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

Заказ №О-2599. Тираж – 2150 данә. Формат 70x108 1/16.
Басарга кул куелды: 24.09.2019.
Чыгу көне: 01.10.2019.
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе иректе.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела. Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, Кукмара туган якны өйрәнү музееннан алынган фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды. Тышлыктагы Н.Индюхов рәсемнәре ТР Дәүләт сәнгать музее тупланмасыннан алынып бирелде.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Төзәтү: Журналның 9 нчы санында «Безнең заман һәм замандашлар» дигән текстта, техник сәбәпләр аркасында, авторның фамилиясендә хата киткән. Әлеге язманың авторын Роза Хәбибуллина дип укуыгызны сорыйбыз. Автордан һәм укучылардан гафу үтенәбез.

Тышлыкның 1 нче битендә – **«Күзгә тынлык». Николай Индюхов рәсеме.** 2000 ел.

Әхмәт Саттар
(1939-2018)

ШИГЫРЬЛӘРЕМ – КОШЛАРЫМ

Дала сыман ачык шигырьләрем,
Белми дала аран-бикләрне.
Шигырьләрем – азат кошлар сыман! –
Канатлылар белми чикләрне.

***

Минем шигырь – дүрт көпшәле мылтык,
Оста ата беләм – мәргән кебек!
Көпшәләрдән ләкин ядрә түгел,
Сүз коела – энҗе-мәрҗән кебек!

***

Җир әйләнә Галәм казанында,
Ачык йолдызларның капкасы.
Ут – мәңгелек түгел, ул да сүнә,
Һәр савытның була капкачы!

***

Тыю-кисәтүләр хәттин ашкан,
«Ярамый!»лар тора кисәтеп.
Гүя бу ил – төрмә. Һәм биредә
Табалмассың чынлык кисәген...

***

Тугач та без – үлем тоткыннары,
Суласак та ирек һавасын.
Кешелегең күпме данлы булса,
Мәңгелеккә шулай авасың!

***

Карт паровоз – ялда. Елларны ул
Өстерәгән, миче көйрәгән.
Ә бабайлар безнең, паровоздай,
Еллар аша
Азатлыкны алга сөйрәгән! ■

СӨЕМБИКӘ

Ольга Иванова

«Сөембикә». Билгесез рәссам эше

Ахыры. Башы журналның 3 нче (2019) санында.

Тәрҗемәчедән.

Сафагәрәй белән Сөембикәнең уллары Үтәмеш тормышлар болганган чакта дөньяга килә, хан гаиләсе, эчке һәм тышкы дошманнарыннан саклану өчен, Казаннан берничә тапкыр китеп торырга мәҗбүр була. Озакламый 42 яшьлек Сафагәрәй дә вафат була, Сөембикә аның варисы исеменнән дәүләт белән идарә итәргә керешә.

Ханлык яңадан-яңа тетрәнүләр уртасында яши. Рус баскынчылары, әледән-әле Казан диварлары астына килеп, тынычлыкны боза. Бу һөҗүмнәрдә аларга көч өстәп, казаклар һәм Бәхтияр Зүзин җитәкләгән пермьлеләр белән бергә (тарих үзенең «каһарман»нарын белергә тиеш!), Шаһгали дә зур тырышлык күрсәтә. 1551 елның маенда Зөя (Свияжск) ныгытмасы корыла, шулай итеп, Тау ягы Иван IV кул астында кала. 11 августта Казан диваны, һаман да нәрсәгәдер өметләнеп, Үтәмешгәрәйне әнисе белән бергә Мәскәүгә озатырга карар кыла. Шаһгали 16 августта 500 кешелек яу белән (аларның 300е Касыйм татарлары була) Казанга килеп төшә. Хакимияттен кансыз җәзалаулар, кан-яшь белән ныгытырга азапланган бу адәмчеккә халыкта мөнәсәбәт үзгәрми. Шуңа рус ягы аны үз наместнигы белән алыштырырга ниятли. Карамзин һ.б. рус тарихчылары язганча, Шаһгали, имештер: «Мин – мөселман һәм үз динемә каршы бара алмыйм... Казанны, – килешү буенчамы, көч беләнме, – алсагыз алыгыз, әмма миннән башка гына», – дип, Зөя ныгытмасына чыгып китә... Ханлыкны, билгеле булганча, кан коеп яулыйлар. 1552 елның 2 октябрендә Иван IV, җиңүче сыйфатында, Нургали капкасыннан Казанга килеп керә. Әмма әле азатлык өчен көрәш тагын биш еллап дәвам итә.

Шаһгалига көчләп кияүгә бирелгән Сөембикә улы белән очрашырга тырышып карый, аны Нугайга озатуларын үтенә. Бәкләр бәге Йосыф та, шул ук таләпне куеп, Иван Грозныйга ярсулы хатлар яза, әмма Мәскәү, кырык сылтау табып, әле сабыйлыктан чыкмаган Үтәмешне үз «кочагы»ннан җибәрми, аны чукындырып, патша сараенда сак астында тота. Хөр җанлы Сөембикәне исә Шаһгали сөргенгә озата, ул шунда үлә, ә карайөз «ире» аны үз төрбәсендә күмдерергә дә каршы була. Шуңа күрә ханбикәнең кабере бүгенгәчә нәмәгълүм булып кала...

Кадерле кунакларны гына кабул итә торган зиннәтле зур бүлмәгә төз сынлы, ыспай хан-кияү ук кебек атылып килеп керде. Башын югары чөйгән Сафагәрәй бу юлы, Сабан туенда батыр асты калганнан бигрәк, җиңүче кыяфәтендә иде. Шулай да, бәкләр бәге Йосыф кукраеп утырган тәхеткә якынлашкач, кияү балакай аңа, хөрмәт күрсәтеп, баш иде:

– Хәерле көн, Мангыт тирмәсенең кодрәтле хакиме! Сезнең белән бергә, бөек вә зирәк хакимнәр тудырган затлы нәселегезне дә сәламлим! – дигәннән соңра колагына гына: – Селямалейкум, бабам[1],– диде.

Аның кырымча сәламләү сүзләре күпне күргән бәкләр бәген дә тетрәнеп куярга мәҗбүр итте. Йосыф әллә кайчан, байтак сулар акканчы, таныклы Гәрәйләр нәселеннән берәүне – Казан тәүге тапкыр куып җибәргән Сафагәрәй ханны – Фатыйма исемле нугай хатыны белән Сарайчыкка килеп сыенганыннан бирле хәтерләми дә диярлек иде. Ул чакта әле дала хакиме, бу чибәр яшь хан, кыргый җанвар алымнары белән, сөйкемле вә сөекле кызын кулга төшерер, үзенең кияве булыр, дип уйламады. Биш ел узганнан соң, тол калган Сөембикә Сафагәрәйнең хатыны булырга ризалык бирде, кырымлы хан исә, Фатыйманы һәм аның балаларын мал-варислыктан мәхрүм итеп,

[1] Селямалейкум, бабам – кырымтатар телендә: исәнмесез, әтием (тәрҗ. иск.).

Сөембикәне өлкән ханым (ханбикә) дәрәҗәсенә күтәрде. Яшерен-батырын түгел, ул чакта әлеге хәбәр Йосыфны куандырды, әлбәттә; барысыннан да бигрәк, эти кеше сөекле Сөембикәсенә – нугайның бәкләр бәге кызына – тиешле кадер-хөрмәт күрсәтелүенә өметләнде. Сөембикәнең Җангали хан белән кимсетелеп яшәвен инде Йосыф илчеләрдән һәм ханбикәнең үзеннән сирәк кенә килгән хатлар аша белә иде. Әлеге юллар арасыннан ул, бәгыре каный-каный, кызының газап чигүләрен аңлап-әрнеп укыды. Ә бу ир-егет, хәзер аның каршында башын иеп басып торган кырымлы, Сөембикәгә барысын да – ихтирамын да, мәхәббәтен дә бирде кебек. Йосыф аның бер генә ягын кабул итә, кичерә алмады: ул да булса, яшь ханның акылсызлыгы, кызу канлы холкы. Шуның аркасында, Сафагәрәй Мәскәүнең бөек кенәзе белән пычакка-пычак килде, бу уңайдан сак кына кисәтү һәм киңәшләрне колагына элмәде. Инде менә нәтиҗәсен күрсен: ул бүген – тирмәсез хан, ә уллары – Сөембикә белән Сафагәрәйнең дәвамчысы туса, беркайчан да атасының җиренә варис-ия була алмаячак... Йосыф, бармак буыннары агарып чыгардай итеп, йодрыкларын кысты. Менә монысын – Сафагәрәйнең Казаннан сөрелгәннән соң Сөембикәгә карата мөнәсәбәте үзгәрүен – ул гафу итә алмый да алмый инде.

Нугай хакиме башын артка чөйде, каршысында торган кияү балакайны усал карашы белән бораулады. Ә тегесе нәрсәдер әйтмәкче иде, ахрысы, бәкләр бәге аның тавышында мескенләнү һәм ялвару ың-шыңнарын ишеткәндәй булды. И-и, текә маңгайлы Сафагәрәйгә дә болай тезләнеп торыр чак җиттемени?!

– Айдынъыз, багъча бою юрип келейик. Риджа этем сизге, бабам[2].

Йосыф һаман дәшмәде, әле ул киявенең үтенечен, бу ни бу, дип аңларга тырышып азаплана иде. Нәрсә күрсәтмәкче соң Сафагәрәй – гарештән сөрелгән дип әйтерлек хан: тәвәккәллегенме, әллә акланырга, җаваплылыктан качарга теләвенме яки тагын нindидер бүтән берәр сәләтенме? Ачу акылны китәрә дигән сүз бар. Ярсып уйлау башны туры юлдан яздыра, шуңа күрә, нугай аксакалы тыңлаусыз күз кабакларын йомды һәм бары шул чакта гына кияү балакаеның ниятен аңлагандай булды: бу, мөгаен, бәкләр бәге белән сөйләшүне чит колаклар ишетүеннән качырып, тәхет тирәсендә бөтерелгән морза һәм нөкәрләр колагыннан читкәрәк алып китәргә дә нидер әйтергә җыенадыр. Беркавым уйланып алгач, Йосыф Сафагәрәйгә аклану мөмкинлеген бирергә карар кылды, башсыз кияве, бәлки, хаклы дадыр: бу бит гаилә эчендәге сөйләшү, аның эчтәлеген никадәр аз кеше белсә, барысына да шулхәтле яхшырак булыр. Морзабәк, башы белән генә ым кагып, яраннарын озатты һәм ашыкмый-нитми генә бакчага таба юнәлде. Сафагәрәй, артык сүз дәшмичә, аңа иярде. Ике хакимнең артыннан, тиешенчә ара калдырып, сак та кузгалды.

Әлегә бушап калган бакчада, комлы сукмак буена утыртылган розалар тирәсендә бик өлкән яшьтәге бакчачы – кытай бабай кайнаша иде. Бәкләр бәге аңа сәлам бирде дә, кулларын артка куеп, әкрен генә алга таба атлады. Ул Сафагәрәйгә беренче башлап сүз әйтергә мөмкинлек куйды, кияве моны шунда ук сизде.

– Беләм, бабам, – дип башлады ул, – Сезнең алда вә Сөембикә ханбикә алдында гаеплемен. Бүген бердәнбер теләгем – шул гонаһымны юу. Миңа яугирләр бирегез, бәкләр бәге. Ант итәм, инде бу җәйдә үк кызыгыз Казан сараена кайтыр.

Йосыф туктады, уйланучан карашы читекләренең бизәкле очларына текәлде.

– Риджа этем сизге, бабам, – дип, тагын да акрынрак тавыш белән өстәде Сафагәрәй, – миңа Сөем белән күрешергә рәхсәт итсәгезче. Ул авырый, дип ишеттем, аның өчен борчылудан һәм сагыштан йөрәгемә кан сава. Мин аны бик яратам, бабам.

---

[2] Айдынъыз, багъча бою юрип келейик. Риджа этем сизге, бабам – кырымтатар телендә: әйдәгез, бакча буйлап йөреп килик. Үтенәм сездән, этием *(тәрҗ. иск.)*.

Йосыф янә озак кына дәшми торды, авыр уйларына бирелеп, яшел яфрак яра башлаган алмагач ботакларына карады. Ул аларны күрә дә, күрми дә кебек иде. Сафагәрәй дә, башын иеп һәм язмышы хәл ителүен көтеп, тынып калды.

Моңарчы дәшмәгән бәкләр бәгенең тавышы карлыгып һәм йөрәк әрнүе белән тулы икәнен сиздереп чыкты:

– Сафагәрәй, әле кичә генә, булдыксыз идарәче булганың, кызымны чак кына харап итми калганың өчен, башыңны чабып ташларга теләгән идем! Ләкин, күрәсең, хан, синең үз сакчы фәрештәң бар һәм, Аллаһ хөкеме белән, бу фәрештә минем Сөембикәм булып чыкты. Бүген иртән, хаста хәлендә килеш, урыныннан торып, ул миңа килде. Сине кичерүемне үтенде. Аның эзләрен үбәргә дә лаек булмаган син юньсезне! – Бәкләр бәге, кинәт дөрләп киткән ачуын авырлык белән генә басып: – Ул да сиңа гаскәр бирергә дә Казан тирмәсен кайтару юлына озатуны үтенде, – дип дәвам итте. – Сөембикәм моны мөмкин кадәр тизрәк эшләүне сорады, чөнки ханбикәнең йөрәк астындагы бала Казан җирендә туарга тиеш. Ә балалар, беләсең, Сафагәрәй, көтеп тора алмыйлар!

– Бала?! – Аяк астында җир упса да, Сафагәрәй бу кадәр таң калмас иде. – Сөембикә бала көтәме? Йа Аллаһ!

– Син күккә карап, аннан ярдәм көтәргә ихтыярлы, – дип мыгырдап куйды бәкләр бәге, – ә мин, далада кызым кичергәннәрдән соң, баланың ана карынын ташламавын могҗиза дип саныйм. Димәк, ул тормышка теше-тырнагы белән ябышачак!

Йосыф елмайды һәм кинәт, нәрсәдер исенә төшкәндәй:

– Яугирләр бирермен мин, тик бер вәгъдәңне алмакчы булам, – дип өстәде.

– Бар теләгеңне үтәргә әзермен, бабам.

– Әгәр ханбикә ул-малай тапса, тәхетемне аңа мирас итеп калдырырмын, диген!

Сафагәрәй, җиңел сулап, кулын күкрәгенә куйды:

– Ант итәм: бу – минем иң кайнар теләгем булачак һәм мин аны тормышка ашыру өчен барысын да эшләрмен.

– Ә хәзер, – дип йомшарып әйтте Йосыф, – хатының янына бар. Ул сине көтеп алҗыгандыр.

Сафагәрәй, канатлар үскәндәй, бәкләр бәге Йосыфның хәрәмханәсенә илтүче баскычтан очып кына менде. Шундагы хезмәтче, кыска аяклары белән теркелдәп, аның артыннан көчкә өлгерде. Саран гына яктыртылган тар коридорга кереп, нindидер могҗиза белән, хатыны бүлмәсенең ишеген тапты хан. Шуның каршысында беравык каушабрак басып торды, кулы ишек тоткасы буйлап шуды, тимер бөҗраның бөтен төерләрен тоеп узды. Сафагәрәй карасу төскә буялган ишеккә, аның теге ягында ни хәлләр булып ятуын ишетергә теләгәндәй, яңагы белән дә сыенды хәтта. Эчтә тынлык кына хөкем сөрә иде, шуңа, тәвәккәлләп, ишекне ачып җибәрде. Аның күз алдында, бу сарайның бөтен зиннәтен, җылысын үзенә сыендырган кебек, гүзәл бер манзара ачылды. Бу кадәр затлы, кыйммәтле җиһазларда кайгыртучан атаның кызына, Казаннан аерылып киткәннән соң, югалткан бар тынычлыгын кайтару, күңел китеклеген йомшарту теләге күренеп тора иде. Сөембикә үзе биек тар тәрәзә буенда, алтын парча белән тышланган диван өстендә утыра. Тезләрендә ачылган китап ята, әмма ул укымый, уйга чумып, күзләрен йома төшкән. Ачылган ишек тавышына ханбикә башын борып карады... һәм тынсыз-өнсез калды.

Сафагәрәй аның шултиклем үз, бераз ябыга төшкән, әмма шуңадыр да тагын да якынрак һәм сөеклерәк булып тоелган йөзенә комсыз күзләре белән йотардай итеп карады:

– Сөембикә...

– Сафагәрәй! – Ул аңа таба кулларын сузды һәм хан, түземлеген җуеп, хатыны каршысына ташланды.

Ир ханбикәнең учларын, йөзен үбеп туя алмас кебек иде, тезләнеп, түгәрәкләнеп килүче, хәтта иркен ефәк күлмәк аша да беленеп торган тыгыз эчен калтыранган бармаклары белән сак кына иркәләп алды.

– Мин инде, Аллаһ безгә мондый рәхмәтен күрсәтер, дип өметләнми дә башлаган идем, җаным.

Хатын көлеп җибәрде, иренең күптән түгел генә кырылган башыннан сыйпап узды.

– Тулы бер ханлыкны шуның аркасында югалтырга мөмкин, дип уйладыңмыни син?

Хан аңа бик җитди карап куйды да:

– Вәгъдәм шул, сөекле бикәм, сиңа да, булачак балабызга да Казан тәхетен көзгә хәтле кабат кайтарачакмын, – диде.

Сөембикә тар учлары белән аның йөзен кочып алды, тагын да ныграк иелә төшеп:

– Мин сиңа ышанам, ханым-хуҗам, – диде.

– Тагын бер вәгъдәм: әгәр синең белән улыбыз туа калса, мин аны варисым итәчәкмен.

Сөембикә бер мизгелгә тынып калды, күзләрендә икеләнү шәүләсе күренде:

– Казанлылар моның белән килешә алмаска мөмкин, синең бит улың – Бүләк солтан бар инде.

– Әмма Бүләк Казанны бүтән күрмәс. Кайчандыр әйләнеп кайта калса, аның янында әнисе Фатыйма булачак. Сөембикә, син һәм мин шул көнне күрербезме икән әле?

Ханбикә, көтмәгәндә инеш булып ага башлаган яшьләрен тыярга тырышып, күз кабакларын кысты:

– Син хаклы, Сафагәрәй, мин хәзер балабыз турында гына уйларга тиеш.

***

953 нче сәнәнең рабигыссани[3] ае ахырында нугай иреклеләре гаскәре яу сәфәренә чыгарга әзер иде. Ул арада Әтил ярларыннан Казан тәхетендә Шаһгали ханның янә патшалык итә башлавы турында хәбәр килеп иреште. Бу яңалык Сафагәрәйне тагын да ашыктырды, ул инде икенче көнне үк нугай атлы гаскәренең алгы сафына басты. Аны, чапкын сөйләве буенча, барыбер Казан сарае кабул итәсе килмәгән Мәскәү ялчысы Шаһгали куркытмый иде. Ул башкала диварлары астына килеп җитү белән, Мәскәү яклылар белән казанлылар арасында ызгыш-талаш башланган, ди. Иске «яңа» хан үзе белән өч мең Касыйм казагын һәм мең урыс укчысын алып килгән, ә казанлылар баскыннарны калага кертүдән баш тарткан, имеш. Шаһгали пошаманга калган һәм үзен яклаучылардан башка гына пайтәхеткә аяк басарга курыккан. Ул, мескен, берничә көн-төнен шәһәр ныгытмалары эргәсендә чатыр корып үткәргән, Казан карачылары белән бертуктаусыз сөйләшүләр алып барган. Дивандагы түрәләр ханга, «башкалага читтән хәрби көчләр кермәскә тиеш» дип язылган килешү-солых кәгазен селеккәләп, аның бозылуы турында кычкырганнар. Ниһаять, Шаһгали бу таләпкә күнәргә мәҗбүр булган һәм Казанга йөзләп кешедән торган шәхси сагы астында гына керергә җөрьәт иткән. Шәһәргә воеводалары белән килгән урыс илчесенә шулай ук якты чырай күрсәтмәгәннәр, үзенә Казан диварларының тышында урын табарга кушканнар. Шаһгали диванның бар таләпләрен үтәгән, тик казанлылар моның белән генә дә тынычланып калмаганнар, яңадан-яңа шартларын куеп торудан туктамаганнар. Мондый хәлгә тарыган Шаһгали бик тиздән үзен хаким дип түгел, ә тоткын итеп тоя башлаган.

[3] 953 нче сәнәнең рабигыссани ае – 1546 елның июне.

Бу мәгълүмат Сафагәрәйне шатландырды: бәс, Шаһгали Казан җирендә ул кадәр үк көтеп алынган хан түгел икән, Сафагәрәй, уңышка өметләнеп, иркен сулыш алып сәфәргә чыга ала дигән сүз. Бәкләр бәге Йосыф, киявенә фатиха биреп, аны юл догасы укып озатты, колагына гына шундый сүзләр пышылдады:

– Безнең сөйләшүне онытма, хан.

Сафагәрәй килешкән кебек башын иде, ләкин җавап кайтармады. Бәкләр бәге авыр сулап куйды: үҗәт тә соң инде бу кырымлы, бәлки аның кисәтүләрен истә дә тотар, әмма озаккамы?

Әле кичә кичен генә бәкләр бәге Йосыф Сафагәрәйне үз катына чакырып, аның белән алдагы сәясәт турында сөйләшкән иде:

– Тәкәбберлегеңне тый, хан, Мәскәү белән татулаш. Аның белән ачуланышу яхшыга илтмәс, урыслар хәзер артык көчәйде. Ә без – Бөек Урда нәселләре кайчандыр олыслар вә яулап алынган җирләрне нык йодрыкка йомарлап тоткан көчне югалттык. Мәскәү, әнә, Сарайга барып баш игәнен, ясак түләгәнен инде хәтерләми дә. Хәзер без бер-беребезгә дошманга әйләндек, талашабыз-чәйнәшәбез, үз тирмәләребездә хакимият бүлешәбез, хак диндәгеләрнең дә туганлыгын оныттык, Чыңгызхан кануннарын хәтерләмибез. Ә Русь көчле. Бабагыз – кодрәтле Миңлесафагәрәй, Русьны да яклап, Зур Урда монголларын кыйнап җибәргән чактан соң, урыслар ничек үсте, нинди гайрәт-куәт җыйды! Мин картны алар алдында бил бөгәргә җыена, дип уйлыйсыңмы, ә-һе-һе! Үзем өчен курыкмыйм мин, ә синең тирмәң, андагы халкың азат булсын иде, дип борчылам. Мондый дошман белән яхшы оршышуга караганда начар солых әйбәтрәк.

Нугай хакиме кияве белән кырымлылар турында да, муеннарына камыт кигезгәнгә түзеп тора алмаган хөрлек сөюче казанлылар хакында да гәп куертты. Кайбер нәрсәләрдә Сафагәрәй аның белән килешкән дә кебек иде, ә кайчакта, дәшмичә генә канәгатьсезлеген белдереп, кашларын җыерып-җыерып алгалады. Озын гомерендә акыл җыйган нугайлының киңәшләрен тотармы-юкмы Казан ханы, – әлегә Аллаһның бер үзенә генә билгеле.

***

Атлы гаскәр, Сарайчыктан кузгалып, бик күптәнге заманнарда ук Казанга хәтле салынган кәрван юлы буйлап китте. Пайтәхет янына килеп җиткәндә, инде Шаһгалине хаким дип игълан итеп өлгергәннәр иде. Диварлар астына килеп баскан нугайлылар каланы ярсытты, халыкны таяк тыгып болгаткан кырмыска күченә әйләндерде. Казанлылар ярты ел эчендә Сафагәрәйнең гөнаһларын онытып өлгергән иделәр инде, ә урыслар тәхеткә кабат «артыннан төртеп» менгезгән бәндәне үзләрен мыскыллау-мәсхәрәләү дип кенә кабул иттеләр. Халык, Шаһгалине тәхеткә чакырып китергәне өчен, Боерган сәедне дә әрләде. Казан ике көн кайнады һәм, Сафагәрәйнең капкаларны ачарга тәкъдим ясавына колак салып, зирәк әмирләр белән морзалар Касыймнан килгән сугышчыларның әллә ни нык булмаган каршылыгын сындыруга ирештеләр. Чебен дә үтеп керә алмастай ныгытма капкаларын шар ачып куйды, Сафагәрәй хан Казанга, кан коймыйча диярлек, җиңүче булып керде. Әмма Кечүк кылычы үзенә корбаннар сорый иде. Хаким үз каршысына әсир ителгән касыймлылар белән Шаһгалине дә китереп бастырырга боерды. Ләкин бәреп төшерелгән ханны күпме эзләп тә таба алмадылар. Сафагәрәйгә бары ул мескеннең, бөтен тирә-юньдә ыгы-зыгы, мәхшәр купканыннан файдаланып, дәрвиш чапаны кигән хәлдә, җир асты юлыннан чыгып качканын күргән хезмәтчеләрен генә шаһит буларак тотып китерделәр.

Мәскәү, әлеге түнтәрелешне белгәч, бик ачуы чыгып әтәчләнде, әмма аның чикләренә

Кырым ханы Сәхибгәрәй янап торганлыктан, Казанны йотарга тырышулары гел генә тамагына тыгылганын онытмаган яшь кенәз Иван башбирмәс татарларга гомумән кул селтәргә булды. Бу – мәскәүлеләрнең ханлык өстеннән астыртын һәм ачыктан-ачык хакимлек итүе шактый вакытларга алып ташланган дигән сүз иде.

Җәйге бөркү кичтә Сафагәрәй Сарайчыктан – Сөембикә ханбикәдән килгән мәктүбне укып утыра иде. Аның кәгазьгә төшкән һәр сүзе генә түгел, хәрефе дә йөрәгенә ут салды: «Сагыштан үләрмен, ахрысы. Аерылып тору тобасы мине аска, төпкә сөйри. Сине шулкадәр күрәсем килә, җаным! Мин сиңа көн-төн язам, язу карам сиңа әйтәсе килгән сүзләремнән алдарак кибә. Әй, елгалар язу карасына, ә яр буендагы камышлар каләмгә әйләнсә, ул чакта сине сагынуымны һәм яратуымны язып бетерә алырмынмы икән?»

Сафагәрәй сөеклесенең хуш исен саклаган кәгазьне иреннәренә тидереп, ике бармагы белән кысты. Ул да бит аны сагынудан саргая, күзләрен, елмаюын, тавышын, хәтта яшен ялтыравы кебек кинәт кабынып киткән һәм төпсез дәрт чоңгылына төшеп сүнгән оршышкан чакларын да юксына. Бер хатын да аңа бу кадәр ләззәтле тойгылар бүләк итәргә сәләтле булмады. Ә ул аңа бары тик иң олы мәхәббәте һәм көчледән-көчле көнләшүе белән генә җавап кайтара ала иде. Сөем башкаларның берсенә дә охшамаган, аңа тиң бердәнбер газизе булды.

Хуҗасының ялгызлыгын бозып, уйларын бүлеп, Кечүк килеп керде. Углан, башын иде дә:

– Хаким, диван фетнәчеләрнең язмышын хәл итүегезне көтә, – диде.

Сафагәрәй йөзе белән аңа таба борылды, кырыс чыраеннан инде мәхәббәт хыяллары юып алынган сыман иде.

– Аларга миннән нинди карар кирәк соң? – дип, мыек астыннан хәтәр генә елмаеп сорады ул кырымлы аркадашыннан.

– Кичерүегезне-ярлыкавыгызны телиләр...

– Кичерүнеме? – Хан көлеп җибәрде. Ярсу тулы корычтай күзләре генә елмаймады. – Казанлыларны таныйм. Баштан алар үзләре ызгыш-талаш оештыралар, ә инде әҗерен алыр чак җиткәч... – Сафагәрәй, сүзен әйтеп бетермичә, кылычын тартып чыгарды: – Таныйсыңмы, Кечүк, бу кылычны? Ул хаиннәрнең канын татыр әле, дип вәгъдә иткән идем, хәтерлисеңдер. Синең бүләгең аша үтәргә тиешләр алар, и углан! Мин – бу ханлыкта иң югары торучы зат шулай боерам!

Мәскәү яклылардан иң күренеклеләре – Кадыш, Чуранарык һәм Баубәк әмирләре үлем касәсен җәй ахырына таба эчтеләр. Ул көннәрдә Сафагәрәй ханның хәрәмханәсе Казан җирләре чигеннән кереп бара иде. Хакимнең хатыннары килгән көнне башкала, Шаһгали тәхеттә арты җылынганчы да утыра алмый калуын һәм күренекле аксөякләрне йоткан мәхшәрне дә онытып, яңадан күп кешене алгысыткан җанлану кичерде.

Кечкенә тирмәләр тезмәсеннән торган кәрван, ашыкмыйча гына, бөтен саклык чараларын күреп, озак тукталышлар белән алга баруында булды: сабыр-салмаклыкның төп сәбәбе – бала табар вакыты якынлашып килгән ханбикәне сакладылар. Бәкләр бәге Йосыфның кушуы буенча, аңа йомшак кына тирбәлеп бара торган аерым тирмә сайлап алынган иде. Сафагәрәй хан җәйнең соңгы көннәренең берсендә, ниһаять, яраткан хатынын кочагына сыендыруга ирешә һәм, тавышына тантана төсмерләре чыгарып, антының яртысын үтәгәнен игълан итте:

– Хәзер, Сөембикә, – дип өстәде ул, – эш синнән генә тора. Варисның дөньяга килүен көтәрбез.

– Әгәр кыз туса?.. – дип икеләнеп сорады ханбикә.

– Ул чакта, киләсе табышың улыбыз булыр! – дип, ныклы ышаныч белән җаваплады Сафагәрәй.

Ә Сөембикә хафага төште. Ул, сүлпәнләнеп, гадәттә булмаганча акрын кыймылдый башлады, әледән-әле бераз хәле киткәнен тоеп, һич сәбәпсез куркуга сабышты. Инде торган саен ешрак:

– Бу авыр көнне үткәрә алмам, Газраил[4] яныма килеп җитәр! – дип сөйләнде.

Аны барысы да – табиблар, хезмәтчеләр, кендек әбиләре һәм хәтта хаким үзе дә – юкка гына тынычландырырга азапландылар. Куркуы барыбер таралмады. Бу көннәрдә ханбикә Фәйрүзә[5] белән генә бераз тынычлана иде. Алтын чәчле гүзәлкәй Сөембикә янында озаклап утыра, кулларыннан иркәләп-назлап тота һәм көлмичә түзмәслек сүзләр белән үзенең бала табарга курыккан вакытларын искә төшерә... Кайчакта кече ханбикәнең күңелле хикәяте озакка сузылган ютәл белән өзелеп ала. Бу йөткерү Фәйрүзә бикәдә теге кышкы сәфәрдән соң барлыкка килде, әмма вакыт үтү белән дә узмады, киресенчә, көчәя генә барды. Табиблар һәм үләннәр белән имләүче әбиләр дә, шифа китапларында язылган бөтен алымнарны эшкә җигеп, сынап карадылар югыйсә. Бикәгә сарымсак, сары май һәм бал кушып кайнатылган фасоль мае эчерделәр, тәнен җылыта торган катнашмалар белән удылар, төрледән-төрле төнәтмәләр ясап бирделәр. Кайчакта хәле җиңеләйгән кебек булса да, аз гына вакыт үтүгә, зәхмәтле чир яңа көч белән килеп ябырыла иде.

– Ә тагын, ханбикә, – дип, сүзен көлә-көлә дәвам итте Фәйрүзә, – мин бит әле Сезне төшемдә күрдем. Кулыгызга балта тотып торасыз, имеш, ә бу – малай табасыгызга чып-чын юрама.

Сөембикәнең борчулы йөзен, ниһаять, кыюсыз гына елмаю нуры яктыртып алды:

– Син шуңа ышанасыңмы, Фәйрүзә?

– И ханбикә, бу төш юраулык – минем өстәлдә гел тора торган китабым! Андагы юрамаларның яртысын яттан беләм. Туры килмәгән берсе дә булганы юк әле, ышаныгыз.

Көзгә бер көнне ханбикәнең бакча буйлап йөрисе килде. Бөтен әйләнә-тирә салкын яңгырлар башланыр алдыннан була торган аяз-якты, алтын төсләргә чумган иде. Аны бу якларда «әбиләр чуагы» дип борынгы заманнардан бирле йөрткәннәр. Хезмәтчеләр, ханбикәгә төренергә булышып, җылы киемнәр алып керделәр. Венециядән кайтарылган зур көзге каршысында үзен күздән кичереп, Сөембикә, тирән сулыш алып, затлы мех белән каймаланган камзулына кулларын тыккан гына иде, кинәт ухылдап, баскан җиренә утырды.

– Ханбикә, Сезгә ни булды? – Аңа киенергә ярдәм итүче Хәбирә көтелмәгән бу хәлдән югалып калган иде.

Сөембикә, яшь тулган күзләрен тутырып, өлкән хезмәтчегә карады:

– Менә монда нәрсәдер чәнчеп куйды, ә хәзер билдән тарта! – Һәм шунда ук, тирәюнендәге һәммәсен куркытып, кычкырып та җибәрде.

Ханбикә яткан бүлмәдә ыгы-зыгы купты. Хезмәтчеләр бер-берсенә комачаулаганнарын сизмичә йөгерештеләр, шул мәлдә үзе дә югалып кала язган ханбикәнең Өйәнисе кул астына килеп кергән беренче кәнизәкнең йомшак җиренә чәпелдәткәнче, әрлебирле буталыштылар.

– Җәһәт кенә кендек әбисенә йөгер, Җәгъфәр агага әйт, хәбәрне ханга җиткерсен! – диде ул әлеге кәнизәккә кырыс кына.

Ә бала багучы үзе Хәбирәгә булышырга ашыкты. Алар ухылдап утырган ханбикәне икәүләшеп идәннән күтәрделәр.

– Аллаһ берүк ярдәменнән ташламасын, – дип пышылдады Өйәни. – Башланды шикелле.

---

[4] Газраил – үлем фәрештәсе. Авторда – Җәбраил *(тәрҗ. иск.)*.
[5] Фәйрүзә – Сафагәрәйнең кече хатыны *(тәрҗ. иск.)*.

Аннары, бала табарга торган хатынның колагына гына ишетелерлек итеп, тынычландыргыч сүзләрен әйтте:

– Барысы да тиешенчә бара, ханбикә, курыкмагыз. Озакламый кендек әбиләре һәм хаким үзе килер.

– И Фәйрүзә... – дип елый-елый ыңгырашты Сөембикә. – Мин монда Фәйрүзә бикә булуын телим!

– Кемне күрәсегез килә, ханбикә, барысын да дәшеп алырбыз! Ә хәзер без, Хәбирә белән, киемегезне алыштырып, урыныгызга яткырыйк әле.

Хан, дәүләт эшләрен ташлап, тиз генә йөгереп килде һәм кендек әбиләре артыннан ук ханбикә янына атылып керде. Сөембикә, аны күрү белән, кулына чытырдап ябышты:

– И-и! Сафагәрәй, мин шулхәтле авыр хәлдә бит! Безнең балабыз... ул мине эчтән тураклый сыман!

Дулкынланудан агарып киткән Сафагәрәй, шуңа да карамастан, шаяртырга маташты:

– Күрәсең, туганчы ул кулына кылыч алган икән, җанбикәм, ул тиңсез бер яугир булыр!

Хаким хатынын тынычландырмакчы була, ә үзенең хәвефле күзләре кендек әбиләренең каударланып әзерләнүеннән аерыла алмый.

Ниһаять, кендек әбиләренең иң өлкәне, ханбикәне бик тәфтишләп караганнан соң, хан алдына иелеп:

– Хаким, бөтенесе үз нәүбәте буенча бара, борчылырга бер җитди сәбәп тә юк, – диде.

– А-ай, үләм! – дип ыңгырашты ятагында Сөембикә.

– Мин моңа юл куймам, җаным, тормышым мәгънәсе бит син, – дип, Сафагәрәй ханбикәнең бәргәләнгән кулларын тыярга тырышып кысты. – Кечүкне синең авылыңдагы әбекәйне алырга җибәрдем. Ул сине бер мәртәбә коткарып калган, хәзер дә үләргә бирмәс, иншәАллаһ.

Аңы томан белән капланган Сөембикә тулгак тотулар арасында сорап куйды:

– Ә Фәйрүзә кайда? Ул бит янымда булырга вәгъдә итте...

Хезмәтчеләрнең берсе, дөресен әйтмәкче булып, авызын ача язган иде, аны шунда ук хакимнең кырыс карашы астында шап итеп ябып та куйды. Бүген таңда барысына да мәгълүм булды: Фәйрүзә бикә үлем хәлендә ята. Төнлә кече ханбикәнең тәне бик нык кызыша башлаган һәм табиблар гаҗизлектән кулларын гына як-якка җәйгәннәр. Шул зәмһәрир суыкта каһәр суккан куылу аркасында алган чир инде яшь хатынның җанын суырып чыга иде.

– Сөем, кадерлем... – Сафагәрәйнең тавышы бу юлы тагын да тынычландыргычрак булып яңгырады. – Фәйрүзә бикә сине бит нәкъ бүген табарсың дип белмәде. Ул үзенең улын күреп килергә рөхсәт сораган иде...

Тулгаклардан хәле киткән ханбикә аз гына вакытка онытылып торган арада, Сафагәрәй хәрәм агасының күзләренә сораулы карашын юнәлтте. Җәгъфәр ага бары тик башын сагышлы итеп чайкап кына алды. Ятагында чарасыз бәргәләнгән Фәйрүзә бикә өстендә котылгысыз үлем шәүләсе эленеп тора иде...

Кичкә таба, Сөембикәнең газапланулары соңгы чиктән ашканда, тулгак тотулар шултиклем ешайды ки, кендек әбиләре инде хәрәм агасына бала табасы хатын янына им-томчы карчыкны дәшеп кертергә куштылар. Кырыс әбекәй шунда ук эшне үз кулларына алды. Ханбикәне тиз генә күздән кичереп, ныклы ышаныч белән:

– Малай дөньяга килергә тора! – дип белдерде.

– Кайдан беләсең син, кортка, малай булырмы әле яки кызмы? – дип, арага кысылып куйды Сафагәрәй.

Им-томчы ханга ялт кына карап ярып салды:

– Минем әле беркайчан да ялгышканым юк, хаким. Ә Сезгә мин әйтер идем, хатын-кызның бала табуы – ир-ат тамаша кыла торган көрәш түгел...

– Юк, авырлыклары вә газаплары бетмичә, хатынымны ташлап, ә үзем варисымны күрмичә, беркая да китмим!

Сафагәрәйнең гаҗәпләнүенә каршы, күпне күргән кырку холыклы карчык килешкән төстә башын какты:

– Телисез икән, кала аласыз, хаким, тик безгә комачаулык итәргә генә уйламагыз!

Һич көтмәгәндә ярсып китүе иң кыю яугирләрнең дә өнен алган Сафагәрәй куркусыз карчыкның мондый кыланмышыннан хәйран калды. Тик, ягымлы гына җикереп, аның авызын капларга өлгерә алмады, Сөембикә янә әче итеп кычкырып җибәрде. Шыңшу-ыңгырашулар, еламсырап бәргәләнүләр генә бүлгәләп алган бу газаплы тавыш инде аның тамагыннан түгел, күкрәгеннән килә иде һәм им-томчы хәбәр салды:

– Вакыт.

Им-томчы әбекәй бала табарга тотынган хатын өстенә иелде һәм, үз эшен белгән оста сыман, дәртләнеп, нидер кыландыра башлады. Хәрәмханә кендек әбисе аның артында ап-ак җәймә, җылы су белән әзер тора иде. Бер мизгелдән карчык юеш кызыл гәүдәчекне күтәреп алды да җәлт кенә бәләкәй арт шәрифенә чәпелдәтеп куйды. Нәни куллар шунда ук калтыранып алды да, иркен бүлмәне сабыйның көчле тавышы яңгыратты.

– Сезнең улыгыз туды, хаким! – дип, кыска гына хәбәр салды им-том итүче һәм малайны кендек әбисенә тапшырды.

Ханның күз алдында булган бу тамашадан каушап-аптырап калуын күрде ул, әлбәттә, һәм, барыбер, ачуланып әйтмичә булдыра алмады:

– Хаким, нишләп әле бу матур малайны кулыгызга алмыйсыз?! Ай, бу ирләр һәрвакыт бер генә нәрсәне телиләр! Тотыгыз, менә Сезгә варисыгыз!

Сафагәрәй инде бу кыю карчыкны урынына утыртырга өлгермәде, аның бәхетле көлү авазы әйтер сүзен дә авызында бикләп-йомып калдырды һәм хан улының ак җәймәгә төрелгән кош баласы кебек кенә җип-җиңел, әлегә сөяге дә беленмәгән нәфис гәүдәсен кулына күтәреп алды:

– Сөем! Күрәсеңме? Аллаһка шөкер, туды бит, туды без шулхәтле көткән улыбыз! Мин аңа Үтәмеш дип исем кушармын. Бу дөньяга рәхим ит, булачак хаким!

Сөембикә, урыныннан калка төшеп, йөзе самими-ихлас куаныч белән яктырган иренә елмаеп карады. Ә хан исә сабыйны, сак кына күкрәгенә сыендырып, тәрәзәгә таба алып китте һәм тагын да өскәрәк чөйде:

– Күз сал ошбу калага, ошбу бәхетле илгә, Үтәмеш-Сафагәрәй, алар киләчәктә синеке бит! Озын гомерле бул һәм Казан халкына игелекләр генә кылып яшә, бөек нәсел варисы!

– ИншәАллаһ, – дип пышылдады ханбикә, кулларын күкрәгенә кушырып. – Алдагы юлың уң булсын иде, улым. Халкыңнан аерылмыйча, аның белән бер тән, бер җан булып яшәргә язсын. Бисмилләәһир-рахмәәнир рахиим, Аллаһ Тәгалә вә Тәбарәкә!

Әле генә аваз салган тереклек иясе белән бергә дөнья да яңадан тугандай булды, анда, салават күперендәге сыман, аллы-гөлле төсләр уйный башлады. Хан йортының хуҗасы белән хуҗабикәсенә, аларны алда әле озын-озак һәм бәхетле көннәр, айлар, еллар көтәдер кебек тоелды...

*Урысчадан **Мөдәррис Вәлиев** тәрҗемәсе* ■

Безнең мирас №10 октябрь 2019

ЭТРУСКЛАР – РИМ ОСТАЗЛАРЫ*

Солтан Шәмси

Укучыга этруск телендәге берничә язма үрнәкләрен күрсәтмәсәк, алынган темабыз ачылып бетмичә калыр шикелле. Мәсәлән, этрускларда вафат булган кешене яндырып, аның көлен кечкенә өй моделе эченә урнаштыру, амфорага яки махсус ясалган урнага салу гадәте дә булган. Табигый, андый очракта көл салынган савытка яки урнага берәр язу да язып куйганнар. Бу халык вафат булган кешегә карата нинди теләк яисә үзенең кайгысын нинди сүзләр белән белдергән икән?

Мәсәлән, без б.э.к. VII гасырда ук көл салынган амфорага этруск хәрефләре белән текст язылган. Текст сүзләр арасында аралык калдырмыйча тоташ бирелгән. Белгәнебезчә, этрускларның язу рәвеше уңнан сулга таба. Тоташ язылган язуны мәгънә бирә торган аерым сүзләргә ничек бүлеп чыгарга? Гаять катлаулы эш бит. Сүзләрне нинди тел нигезендә бүлеп чыгу да күп сораулар тудыра. Шуны ачыкламыйча, әлеге эшкә тотыну тиешле нәтиҗә бирмәячәк. Бу очракта безгә төрки телне белүебез ярдәмгә килә. Компьютерда этруск алфавиты булмаганга, без әүвәл этруск хәрефләрен барыбызга да билгеле латин хәрефләре белән язып чыгарга тиеш булабыз:

MINIUSILEMTLUUANICE

Аннан соң текстны кириллицага күчерәбез:

МИНИ(м) УЗИЛ ЕМТ ЛУ УАНИСЕ

Шулай кириллицага күчергәндә төркичә мәгънә бирә торган сүзләрне аерым язып чыгабыз. Монысы да җиңел эш түгел, зур тәҗрибә, интуиция таләп итә. Инде шушы борынгы заманда язылган тексттан, төрки-татар теленә нигезләнеп, аңлаешлы җөмлә төзеп карыйк. Ул болай була:

«Мине(м) өзелә өмет, үле юанычы!»

Кешенең, вафат булган туганы яки баласы өчен зур кайгыга бирелеп, өмете өзелүе бик табигый хәл, әмма җөмләнең икенче өлеше аңлашылып бетми. Ни өчен көл салынган бу савыт үлгән кешенең юанычына әйләнгән соң? Моны аңлау өчен, этрускларның дини-фәлсәфи карашларын белергә кирәк. Алар кеше үлгәннән соң да яшәвен дәвам итә, дип ышанып яшәгәннәр. Этрусклардан соңрак дәвердә барлыкка килгән монотеистик диннәр (бер Аллага инану диннәре) дә шул хакта сөйлиләр түгелме соң? Димәк, вафат булган кешенең физик тәне яндырылганнан соң аның көле затлы амфорага салынган килеш кадерләп саклануы аңа канәгатьлек китерә, ул шуннан үзенә юаныч таба. Җөмләнең соңгы өлеше нәкь шуны белдерә сыман. Бу язуның мәгънәсен төрки телне белмәгән бер кеше дә ачып сала алмас иде. Этруск теленең нигезен төрки тел тәшкил итүен бу мисалда без бик ачык күрәбез.

Икенче мисал. Бу очракта мәет көле амфорага түгел, махсус урнага салынган, аңа шактый озын текст та язып куелган. Текстның хәрефләрен ачыклап бетерү, дөрес итеп уку зур тырышлык һәм белем таләп итә. Текст ачыкланып беткәч, аны тагын латинча язып чыгарга туры килә:

Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2019) санында.

*Фәнни-популяр тарихи бәян.

LAQISUELKASNASMINI MULUUANICEMENEQUAS

Тоташ язылган бу текстны ничек итеп аерым сүзләргә бүлеп чыгарга соң? Этруск язулары белән шөгыльләнүчеләргә даими рәвештә менә шундый кыен мәсьәләләрне хәл итәргә туры килә. Бу инә белән кое казуга тиң. Табышмакны ачарга безгә төрки телне белү ярдәм итә. Тырыша торгач, тоташ текст аерым сүзләрдән торган шундый рәвешкә керә:



Мәрхүмнең көле салынган урна

LA QIS UELKAS NAS MINIM ULU UANICE MENEQU AS

Хәзер инде шушы тексттан төрки-татарча җөмлә төзеп карыйк. Әлбәттә, ул борынгы телдә язылган, хәзерге татар теленә туры килеп бетми:

«Лә кыз уелкас, нас минем улу, уаниче минеку аз».

Хәзерге татар телендә ул болай яңгырый:

«Кыз үлгәннән соң минем назым үлде, юанычым аз калды».

Өченче мисал. Бу очракта кабер ташына язылган кыска текстка мөрәҗәгать итәбез. Анда нәрсә язылган икән? Гадәттәгечә, башта этрускча текстны латин хәрефләре белән язып чыгабыз:

UEL(a): SEOQE TUIAC

Инде кириллицага күчерәбез:

УЕЛ(а): СЕОКЕ ТУ(а) ИАШ

Татарча мәгънәсе шундый җөмлә килеп чыга кебек:

«Уйла: сөеке (сөеклең) туа яшь!»

Без инде этрускларда үлгәч тә яшәү дәвам итә, дигән ышану яшәве турында әйтеп узган идек. Бу очракта да, кабер ташындагы сүзләрне укыган кешегә мөрәҗәгать итеп булса кирәк: «Уйла (яки бел): сөеклең үлгәннән соң яшь туа!» – диелә.

Язу астына ике тәгәрмәчле арбага җигелгән канатлы пар ат алдыннан йөгереп баручы ниндидер канатлы зат та ясалып куелган. Әлеге рельефның нәрсә аңлатканын ачыклап булмады. Күрәсең, ул этрускларның дини карашларына бәйле берәр сюжетны чагылдырадыр. (Этрускча текстлар этруск теле белгече Нәсим Сәхапов тарафыннан тәрҗемә ителде.)

Менә тагын бер кызыклы этруск язуы: латинчага күчергәч, ул шундый рәвешкә керә: TINSQUIL, аны кириллицага күчерәбез, ТИНСКУИЛ килеп чыга. Бу очракта да ике сүз бергә кушылган, араларына кыска сызык куеп тормаганнар. Тин – этрускларның баш алласы. «Куил» сүзен этрускологлар «бүләк» (дар) дип тәрҗемә иткәннәр. Бәлки, аның нигезен «кую», шул ук «багышлау» сүзе тәшкил итәдер? Әлеге язу Ареццо шәһәрендә җир казу эшләре вакытында табылган бронза Химераның уң аягына язылган булган. Димәк, кемдер баш алла Тинга бронзадан коелган шушы Химера сынын багышлаган һәм шул хакта язып та куйган.

Еш кына һөнәрчеләр, рәссамнар, сынчылар үзләре башкарган яки иҗат иткән әйберләргә исемнәрен язып куя торган булганнар. Бу гадәт борынгы заманнан безнең көннәргәчә килеп җиткән.

Бронзадан коелган Химера. Арреций шәһәрендә казу эшләре барышында табылган. Этрусклар сәнгате үрнәге. (Б.э.к. V гасыр)

Бер төркем этруск сүзләренең төрки телгә якынлыгын укучыга күрсәтеп алсак, кызыклы булыр, дип уйлыйм. Моның өчен без аталы-уллы Н.Н. һәм И.Н.Хөсәеновларның «Роман-герман телләренең төрки нигезләре сүзлеге» (Уфа, 2017) исемле гаҗәеп кызыклы фундаменталь хезмәтенә мөрәҗәгать итәрбез. Бу хезмәт фәндә өр-яңа сүз булып тора. Ул тарихи процессның ничек барганын яңача күзалларга ярдәм итә, бер үк вакытта төрки телнең гаҗәеп борынгылыгын да ачып сала.

Мисалларны этруск һәм татар телендәге туганлыкны белдерүче терминнарны күрсәтүдән башлыйсы килә, чөнки алар иң борынгы, үзгәрүгә бирешми торган сүзләр булып тора. Әүвәл этрусккасын, аннан татарчасын китерәбез:

anei – әни;
atei – әти;
papa – баба, карт атай;
api, avei – әби;
axa – ага;
afuna – абый;
num – энем;
sec – сеңел;
falzas – балдыз, өстендә нокталы s «ш» дип укыла;
fala – бала;
noc – онык;
cis – кыз;
exeө – егет, ө – «т» дип укыла.

(Н.Н.Хөсәенов, И.Н.Хөсәенов. Роман-герман телләренең төрки нигезләре сүзлеге. – 840 б.)



Мәетләр өчен төзелгән гаилә төрбәсе – тумули

Инде Ф.Р.Латыйпов тарафыннан 1982 елда алфавит тәртибендә төзелгән сүзлеккә мөрәҗәгать итик. Сүзләр әүвәл этрускча, аннан татарча бирелә.

«А» хәрефенә башланган сүзләр:
ac – ак;
akil – белем; акыл;
akiluna – зирәклек;
akun – якын;
aө – ат, ө – «т» хәрефен белдерә;
aөas – адаш;
axr – ахыр, үлем;
alp – алып, батыр;
aras – агач;
ara – ара.

«С» (к) хәрефенә багланган сүзләр:
caөnis – катнашу;
cal – кал;
capc – капу, капка;
caru – коры;
celu – көлү;
cem – кем;
cemul – кемдер;
ces – көч;
cese – кеше; s – «ш» хәрефен белдерә;
ciem – кием.

«Ө» (т) хәрефенә башланган сүзләр:
өan – дан; ө – «т» хәрефен белдерә;
өanurare – танылу;

θra – басып тора;
θun – тын (алу);
θuruna – бүрәнә, колонна;
θuta – тота;
θrna – торна (кош);
θezince – (төзенке, ягъни төзәтелгән);
θucu – туку, кертү;
θezan – төзәнү, бизәнү әйбере.

«M» хәрефенә башланган сүзләр:
macvil – мактау;
marca – марка, сыйфат;
masu – басу;
mate – мәте, татарда «кызыл балчык»;
meit – мәет;
mene – мәңге;
mi – мин;
mlac, milac – мөлек;
mucum – мөһим;
muri – бүре.

«T» хәрефенә башланган сүзләр:
tamer – тимер;
tarc – төрек, кодрәтле;
tatnal – татлы;
tesim – түзем;
tes, tesna – төш, урын;
tin – этрускларның баш алласы Тин;
tra – утыр!
tumuli – курган рәвешендәге мәетләр күмә торган төрбә;
tur – тор, яшә!
turi – туры, каршыда.

«Z» (з) хәрефенә башланган сүзләр:
zat – зат, затлы;
zer – җир;
zus – сүз;
zusleva – сүзләр.

(Сүзләр Ф.Р.Латыйповның «Исследование этрусского и минойского языков на основе фоноэволюционной пратюркской гипотезы и комбинаторно-частотных методов». (Уфа, 1999) китабына урнаштырылган «Этрускча-русча сүзлек»тән алынды).

Н.Н. һәм И.Н.Хөсәеновларның «Роман-герман телләренең төрки нигезләре сүзлеге» (Уфа, 2017) исемле фундаменталь хезмәтендә китерелгән бер таблица этруск һәм татар телләренең уртак нигезләрен күрсәтү ягыннан гаять кызыклы факт булып тора. Анда атамаларның, исемнәрнең, терминнарның ясалышы ачып салынган.

Авторлар мисал итеп Римда хөкем сөргән этруск патшалары Тарквинилар исемен алалар һәм шушы исемнән нинди сүзләр ясалуын ачып салалар:

латинча – Tarkvini – этрусклардан чыккан Рим патшалары;
этрускча – Tarchna (Таркна) – Тарквиниларның этрускча исеме;
этрускча – Tarchon – Таркна шәһәренә нигез салучы;
татарча – тархан – татарлардагы феодалларның титулы, шулай ук татар авыллары, елгалары атамасы да;
татарча – Тарханов – фамилия;
этрускча – Тарк – этрускларның үзатамасы (Ф.Латыйпов);
төркичә – төрк – төрки халыклар атамасы.

Мисал өчен безгә бик тә таныш татар сүзе «алып»тан нинди сүзләр ясалуына игътибар итик:
Латинча – Alp – Апеннин тауларының төньягында урнашкан таулар (Альпы);
Этрускча – alΘazel – бик биек, Θ – «т» дип укыла;
Этрускча – alp – батыр, герой, озын буйлы;
Татарча – алып – көчле, баһадир (Алып батыр);
Татарча – олпат – дәрәҗәле, абруйлы;
Татарча – олы, зур.

(Н.Н.Хөсәенов, И.Н.Хөсәенов. Роман-герман телләренең төрки нигезләре сүзлеге. – Уфа, 2017. – 144, 792 битләр).

Без Ф.Р.Латыйповның сүзлегеннән татарча яхшы аңлашыла торган сүзләрне генә сайлап алдык. Этруск телендә төркилектән ерак торган, аңлавы кыен булган һәм әлегә бөтенләй аңлашылмаган сүзләр дә бар. Бу телдә язылган шактый озын текстлар да табылган. Аларның беркадәресе тәрҗемә дә ителгән. Галимнәр, үзләре белгән телләргә нигезләнеп, менә ничә гасыр дәвамында этруск телендә таныш сүзләр эзлиләр. Бу телне б.э.к. яшәгән үле телләр белән дә чагыштырып карыйлар. Нигездә, этруск теленең серен һинд-ауропа теләре аша ачарга тырышалар. Тик агглютинатив тел булган этруск телен (сүзнең тамыры үзгәрми) флектив телләр (сүзнең тамыры үзгәрә) ярдәмендә аңларга тырышу бик зур кыенлыкларга очрый. Шул сәбәпле, күпчелек галимнәр этруск теленең серен ача алмый интегәләр. Һәм киресенчә, этруск теленең серен ачу өчен ачкыч итеп төрки телне алганда бу ысул зур уңышларга китерә. Галим Ф.Р.Латыйпов һәм башка галимнәрнең уңышлы тикшеренүләре моның дәлиле булып тора. Бу – бик тә перспективалы юнәлеш.

Күренекле этрусколог А.И.Немировский: «Этруск теленең Кече Азия белән лексик бәйләнешләре исә берәр борынгы халыкның телен тиррен теленең башлангычы дип санарга мөмкинлек биреп җиткерми, – дип язган иде. – Ләкин, гомумән алганда, лингвистик мәгълүматлар тирреннар тарихының башлангыч чорында аларның Кече Азия һәм Урта диңгезнең көнчыгышындагы борынгы мәдәниятләр белән тыгыз бәйләнештә торуы турында сөйли» (Нем., 98). Ф.Р.Латыйпов исә этрусклар Италиягә б.э.к. II меңьеллык азагында Палестина, Ливан, Сирия территорияләреннән килгәннәр, дигән фикердә тора. Ул болгарлар һәм кыпчаклар, гомумән барлык төркиләрнең ерак бабалары – барысы да Борынгы Якын Көнчыгыштагы Убейд археологик культурасы вәкилләре булганнар дип саный. (Ф.Р.Латыйпов сайтындагы «Хазары, булгары, этруски...» мәкаләсе.) Әмма автор мондый нәтиҗәгә килүен нинди дәлилләр белән исбатлый икән? Шуны беләсе иде. Убейд археологик культурасы ул бик борынгы, планета тарихының тирән серләре белән бәйле культура. Шуңа күрә мин авторның бу фикере белән килешә алмадым.

Ф.Р.Латыйпов сүзлегендә «т» хәрефенә башланган сүзләр арасында «тумули»

дигән сүз бар. Бу сүзгә ачыклык кертеп үтәсе килә. Тумили – таш нигезе 1,5-2 метрга күтәртелеп корылган түгәрәк курган сыман төрбә. Таш түбәсе әллә ни биек булмаган гөмбәзне тәшкил итә. Аның тышкы ягына бераз балчык та түшәлгән һәм анда үлән үсә (фотода шулай). Италиянең Тоскана өлкәсендә (элекке Этрурия территориясе) бүгенге көнгә хәтле сакланып калган «тумули»ларның эченә керер өчен эшләнгән ишеге дә бар.

Мине «тумули» сүзе уйланырга мәҗбүр итте. Атлантида һәлакәтеннән сакланып калып, Канар утрауларында яшәгән гуанч халкында да андый курган сыман төрбәләр «тумули» дип атала икән. Бу сүзнең ике халыкта да бер үк нәрсәне аңлатуы нәрсә турында сөйли соң? Бер-берсеннән шактый ерак урнашкан ике халык мәет сала торган төрбәләрен бер үк сүз белән атыйлар. Алар арасында нинди уртаклык бар? Этрусклар кебек серле халыкның Көнчыгыштан түгел, Көнбатыштан килеп урнашуы турында да ышанып язучылар бар. Кайбер тикшеренүчеләр этрускларны Атлантида белән бәйле халык дип саный. (Френк Джозеф. Гибель Атлантиды. – М., 2004.)

Тумули – төрки сүз. Тамыры ук аның төркилеген күрсәтеп тора. «Тум-түм»нән башка сүзләр дә ясала. Мәсәлән, «түм-түгәрәк», «түмгәк» һ.б. Ә инде аның мәетләрне урнаштыру өчен ясалган махсус курган сыман корылма булуын истә тотсак, ул «җирләү, томалау» мәгънәсенә якын тора, дип әйтергә мөмкин. Әлеге сүз этруск теле аша латин теленә дә «tumulo» рәвешендә кергән, шул ук «җирләү», «күмү» мәгънәсен бирә икән (Ф.Фәттахов). Бу атлантлардан калган сүз булса кирәк. Атлантиданың бер чите Үзәк Америкадагы Мексиканың Юкатан ярымутравына бик якын торган. Ул заманда Үзәк Америкада һәм Урта диңгез буенда диңгез империясе Атлантиданың күп колонияләре барлыкка килгән. Шунысы кызык: Үзәк Америкада да, Урта диңгез бассейнында да без төрки телдә сөйләшүче кавемнәрне күп очратабыз. Ә атлантлар нинди телдә сөйләшкән? Атлантида халыклары арасында прототураннар – баба тураннар (прототуранцы) дигән халык булган. Борынгы греклар төркиләрне «touranoi», ягъни тураннар дип атап йөрткәннәр.

Эзотерик чыганаклар бу хакта ачыктан-ачык сөйли. Е.П.Блаватская да үзенең «Тайная Доктрина» исемле фундаменталь хезмәтендә кешелек дөньясында беренче телләр барлыкка килү турында сүз алып барганда агглютинатив телләрне дә телгә ала: «Агглютинативная речь: эти лингвистические характерные особенности (сүз атлантларга кадәр яшәгән Өченче Раса, ягъни Өченче Кешелек дөньясы – Лемурия цивилизациясе дәверендә барлыкка килгән «односложный» моносиллабик тел турында бара. – *С.Ш.*) развились в агглютинативные языки. На последних говорили некоторые расы атлантов, тогда как другие родственные группы Четвёртой Расы (Атлантиды. – *С.Ш.*) сохраняли основной язык...» (Е.П.Блаватская. Тайная Доктрина. Антропогенезис. Т.2. Кн.3. М., 1993. – С.251).

Димәк, агглютинатив телләр Атлантида заманында ук барлыкка килгән иң борынгы телләргә керә. Бу исә агглютинатив тел булган төрки телнең дә шул заманда ук барлыкка килүе турында сөйли.

Бүлекне исә төрки телләр һәм төркиләр тарихын тикшерүче атаклы шәхес Олжас Сөләймановның тирән мәгънәле сүзләре белән тәмамлыйсы килә: «Качественное рассмотрение явлений культур, языков, письменностей, вышедших из ареала Древнего мира (Передняя Азия, Малая Азия, Средиземноморье) не обойдется без привлечения тюркских материалов. И тюркология должна подготовиться к этому неизбежному повороту – надо привыкать видеть тюркскую древность в общепланетарном, а, значит, в общеисторическом контексте...» («Тюрки в доистории», с.117.) ■

15 ОКТЯБРЬ – ДӘҮЛӘТЧЕЛЕГЕБЕЗНЕ САКЛАП ШӘҺИД КИТКӘН КАҺАРМАН БАБАЛАРЫБЫЗНЫ ИСКӘ АЛУ КӨНЕ

Фото «tatar-inform.ru» сайтыннан алынды

ХӘТЕР КӨНЕ

Хәнәфи Бәдигый

Телгәләнә бәгырь,
Өзгәләнә үзәк
Якынлашкан саен Хәтер көне.
Искә төшә шунда
Татар тарихының
Кара канга баткан хәтәр төне –
Варфоломей төне.
Җимерелгән Казан,
Ишетелми азан,
Татар ут-кан, зар-яшь эчендә...
Бүген әрни йөрәк
Көнче, хыянәттән,
Туган илен саткан өчен дә...
Аһ орулар тынмас,
Үкенүләр бетмәс,
Хәтерләтер аны Хәтер көне!
Күтәрелсә ае,
Иле, теле, дине,
Яктырып китәр күк кара төне –
Варфоломей төне.
Тарих үчле түгел,
Нәфрәт илче түгел,
Нигә яшәргә уфтанып гелән:
Күтәрелә Казан,
Ишетелә азан,
Дуслаштырмый дөнья кем белән?!
Хәтер сандыгында –
Теткәләнгән келәм,
Татар җаны сыман –
Моны син дә, мин дә беләм...
Зинданнарга ябып,
Тукмап төйгәндә дә,
Дошманнарның котын алдык без.
Кулга түгел, җанга
Богау салганда да,
Хәтер белән алга бардык без.
Башын салса салды,
Тез чүкмәде татар,
Башбирмәсләр булып калдык без!
Тәре йөртүчеләр,
Куштан мөртәтләрне
Пугач явы белән өркеттек.
Изге аебызны,
Мәгърур Ак барсны
Төп Канунга кабат беркеттек.
Без бит бу көннәрне,
Тешне кысып түзеп,
Дүрт-биш гасыр буена көттек.
Кыйблабызга карап,
Юл табарбыз, әйдә,
Киләчәккә таба без китик!
Хәтер көне кабат,
Кабат хәтерләтер
Ерактагы тарих, элекне.
Ул искәртеп торыр,
Гел кисәтеп торыр,
Баш имәскә һаман,
Тез чүкмәскә һаман,
Кол булмаска тәмам,
Суыртмаска бөтен җелекне!.. ■

КЕМ УЛ ЛОТФИ ИСХАКЫЙ?

Чыңгыз Сафиулла

Финляндия Ислам җәмәгатенең мөтәвәлли хәйятенә 1986 елда Истанбулдан хат килде. Аны Мәхмүт Таһир исемле милләттәшебез юллаган. Мин Таһир әфәнде белән элегрәк, ул Әхмәдвәли Мәңгәр белән Финляндиягә килгәч танышкан идем.

Бу хатның ни өчен Финляндия татарлары мәхәлләсенә юлланганы соң гына беленде: Лотфи Исхакыйның кабере Истанбулда Ферикөй каберстанында табылган һәм озак еллар буе игътибардан читтә калган икән. Таһир әфәнде бу вазгыятькә хурланган һәм, каберне ничек тә булса, күтәртеп, кабер ташын арулатып баштагы хәленә кертер өчен күп эш башкарырга теләгән.

Лотфи Исхакый – Финляндия татарларына таныш шәхес. Ул Тампере һәм Турку шәһәрләрендәге мөселманнарга хезмәт итеп, биредә күп еллар яшәгән.

Истанбулдан беренче хат 1986 елның маенда килде:

«Хөрмәтле Финляндия Ислам җәмәгате рәисе Абдулла Али! Сезләргә сәламнәрем соңында хәерле еллар һәм Рамазан аенда сәламәтлек теләп, Рамазан бәйрәме белән тәбрик итәмен! Бу хат белән Сезләргә шуны белгертмәкче булам. Мәгълүматыгыз, заманында Финляндия Ислам җәмәгатен төзүдә иштирак иткән (катнашкан. – Ред.) Петербург җами имамы Лотфулла Исхакый Истанбулда Ферикөй каберстанына күмелгән, кабергә билге ташы куелган. Бу көннәрдә Истанбулга юлым төшеп,



Лотфи Исхакый кабере

каберстанга барып чыктым. Мәрхүм Лотфи Исхакыйның кабердәге ташны тәртипсез хәлдә күрдем. Кабер җир белән тигез хәлгә килгән, өсте чүп-чар белән тулы. Каберне арчып, бертөрле тәртипкә кертергә тырышып, нәтиҗәдә, кабер ташын мәйданга чыгардык. Баш очындагы ташта шул язу бар:

«CEMİYETCİ, EGİTİMCİ, İLERİCİ AYDIN ULEMADAN PETERSBURG BÜYÜK CAMİ'İ İMAMI KAZANLI LÜTFÎ İSHAKÎ ÖLÜMÜ 18. EYLÜL.1925».

Кабер өстендәге икенче ак мәрмәр таш өстендә шул язулар билгеле:

«Pitersburg cami käbir imam, hatibı ulamai nıbametdin Lütfulla bin Fathulla Ishaki zadä 18 1344 safi».

Бу каберне аянычбер хәлдә күргәч, шуны бертөрле тәртипкә кертергә имкян (мөмкинлек. – Ред.) юкмы, дип, шул хатны язарга булдым. Каберне җир тигезлегеннән күтәртү вә язуларын яңарту өчен, кабер ташлары осталары хакы 120-130 америка доллары чамасы булачак.

Әгәр дә Рамазан аенда җәмәгатегез арасында садакалар, иганәләр җыелса, бәлки шул кабер мәсьәләсен шул ярдәмегез вә садакалар белән хәл итәргә мөмкин булыр. Без исә, кирәксенсәгез, эш ягыннан ярдәмле булырбыз. Бу, әлбәттә, сезнең ихтыярдагы эш. Әгәр дә шул кабер тәртипкә кертелсә, вазыйфабызны үтәгән булырбыз.

Хөрмәтләрем белән – Мәхмүт Таһир.

PS. Без бу каберне тәртипкә китерер өчен танышрак булган таш осталары белән сөйләштек. Адреслары шулдыр: Ташчы Хөсәен вә Хәлил Карабулут, Mezarlik kapi Disi No 10. Feriköy – Istanbul».

Ихтимал, башка таш осталары башкарак хакта истәрләр. Шуны тик билге итеп язам».

Моңарга каршы Финляндия Ислам җәмәгате тарафыннан хат юлланды. Мәхәллә рәисе белән киңәшеп, җавап хатын мәхәлләнең кятибы *(секретаре. – Ред.)* вазыйфасында әзерләдем. Кыскача тексты болай иде:

«Мәхмүт Таһир әфәнде, Анкара, Төркия

Хельсинки, 23.2.1987.

Сезнең 1.5.1986 тарихлы язуыгызны алдык, зур мәмнүният белән. Эчтәлегенә керештек. Тәбрикләүләрегезгә рәхмәтләребезне белгертәбез. Мәрхүм Лотфи Исхакыйның каберен тәртипкә кую өчен сезнең исемезгә 170 америка доллары суммасы күндерелә. Язуыгыздан аңлавыбыз буенча, бу сумма белән башланган эшегез уңачак. Сезгә эшләрегездә, тормышыгызда уңышлыклар теләп, хатыбызны бетерәбез.

Хөрмәтләр белән, Финляндия Ислам җәмәгате, Чыңгыз Сафиулла – урынбасар-кятиб».

Истанбулдан икенче хат.

«11.9.1987.

Хөрмәтле Финляндия Ислам җәмәгате мөтәвәлли рәисе, кятиб вә мәхәллә!

Сезләргә сәламнәрем соңында хәерле тормышлар илә калам. Мәрхүм Лотфи Исхакыйның кабере тәртипкә кертелде. Ферикөй мазарлыгына (зиратына. – Ред.) капкадан кергәч, дивардан икенче сафта 50 адым кадәрле киткәч, алдыгызда Исмаил Тугун кабер ташы чыгар. Шул кабернең артында мәрхүм Лотфи Исхакыйның кабере булыр. Планны сызып бирәм».

Моңардан соң Истанбулдан бернинди дә хәбәр килмәде. Мәсьәлә яңадан 2018 елның ахырларында мәйданга чыкты. 1986-1987 елгы хатларны кулыма алып, Лотфи Исхакыйның кабер ташы нинди хәлдә икәнлеген белергә теләдем. Бер төрек танышым



Лотфи Исхакый кабере күрсәтелгән схема. 1 нче санда – Рөкыя вә Хөсәен Хөсни Әвсан каберләре, 2 нчедә – Исмаил Турун кабере

белән элемтәгә чыгып, алардан кем дә булса Истанбулдагы Ферикөй каберстанына барып, Лотфи Исхакыйның каберен тапмасмы һәм фотога төшереп, Финляндиягә юлламасмы икән, дип хат юлладым. Таһир әфәнде хатындагы хаританы да җибәреп, Ферикөй каберстаны бик зур икәнлеген белгерттем. Бәхеткә, бер атна да үтмәде, рәсемнәр килде.

Лотфи Исхакый – Санкт-Петербург мәчете имамы

Лотфи Исхакыйның туган вакыты, туган җирләре һәм яшьлек еллары турында миндә мәгълүмат юк. Ул Петербургта имам булып эшли һәм җомга намазларында хөтбәне беренчеләрән булып үз телебездә сөйли. Актүктән сәүдә итәргә Финляндиягә киткән бабаларыбыз гадәттә Петербургта туктый торган булган һәм, әлбәттә, алар Лотфулла хәзрәт укыткан җомга намазларында да катнашкан.

Лотфи әфәнде Петербургта биш сыйныфлы, 50-60 шәкерт укый торган рус-татар мәктәбен дә оештырып җибәрә. Дәресләр ул корган тәртип белән укытыла. Моңардан тыш, төрек теле дә укытылган. Ислам дине нигезләре төп фәннәрдән булган. Шул ук укыту тәртибендәге мәктәп системасын Лотфи Исхакый Финляндиядәге татар балаларына да күндерә. Кызганыч, гомере кыска булу сәбәпле, ул максатларына ахыргача ирешә алмады.

Лотфи Исхакыйның алдынгы фикере буенча, кыз балалар да ир балалар кебек үк укыту мөмкинлекләренә лаек булырга тиеш. Моның өстенә ул ханымнарның, кыз балаларның ирләр белән тигез хокуклылыгы өчен дә тырыша. Аның тырышлыгы вә мәгърифәтле кешеләр, иганәчеләр ярдәме белән, 1910 елда Актүк авылында кызлар мәктәбе ачыла. Шушы елда Лотфи Исхакый олуг мәгърифәтче Гаяз Исхакый белән бу авылны зиярәт итә. Алар шунда мәктәптәге укыту ысуллары турында фикерләшә. Алдынгы укытучы табар өчен, Лотфи Исхакый мәшһүр ислам галимнәре белән элемтәгә чыга. Буби мәдрәсәсенең мәшһүр мөдәррисләреннән булган Габдулла һәм Гобәйдулла Бубилардан да ярдәм сорый.

Нәтиҗәдә, Рәйхана туташ Батырша бу эшне ризалык белән кабул итә. Ул гыйлем һәм тәрбия хезмәтен зур тырышлык белән башкара. Аның шәкертләре заманы өчен яхшы гыйлем һәм тәрбия алып кала. Әмма Рәйхана туташ, Хәсән Җәмалетдинга кияүгә чыгып, Финляндиядә яши башлый.



Хәйят әгъзаларының 1923 елда алынган фотосы. Алгы рәттә, сулдан: Сафа Исмаил, Вәлиәхмәд Хәким, Лотфи Исхакый, Абдулла Баттал-Таймас, Җәмалетдин Йосыф. Арттагы рәттә: Җәмалетдин Гарифулла, Гомәр Габдерәхим, Гайсә Бәшәр һәм Гыймад Җәмалетдин

Лотфи Исхакыйның Финляндиядәге хезмәте

Лотфи Исхакый тышкы кыяфәте буенча күркәм вә һаман да матур костюмнан йөри торган була. Ул Тампере шәһәренә 1900 нче елларның башларында берничә мәртәбә килә, әмма 1922 елдан соң гына дәвамлы рәвештә яши башлый. Монда ул ислам мәхәлләсен, фин-төрек мәктәбен оештыру һәм мәчет салу өчен тырыша.

Юлланган гариза буенча, 1923 елның 18 октябрендә Финляндия хөкүмәте мәчет төзү турында карар кабул итә. Карар нигезендә, төзелеш өчен хәйят раслана. Бу хәйяткә менә шушы шәхесләр тәгаенләнә: сәүдәгәр Гомәр Габдерәхим – Хельсинки шәһәреннән; сәүдәгәр Бәдретдин Гарифуллин – Поридан; мөгаллим Абдулла Баттал – Хельсинкидан; мәзин Гайсә Бәшәров – Хельсинкидан; имам Вәлиәхмәд Хәким – Хельсинкидан; сәүдәгәр Җәмалетдин Хәсәнов – Оулудан; сәүдәгәр Хәсән Хөснетдинов – Лахтидан; имам Лотфулла Исхаков – Туркудан; сәүдәгәр Сафа Исмәгыйлев – Туркудан; сәүдәгәр Җәмалетдин Йосыф – Тампередан; сәүдәгәр Имаметдин Җәмалетдинов – Тампередан.

Шулай итеп, 1925 елда Финляндия Ислам җәмәгате оеша. Бу вакытта Лотфи Исхакый җәмәгать эшлеклесе, Турку шәһәрендә мәзин вазыйфасын үтәп яши. 1920 нче елларда Турку шәһәрендә йөздән артык татар яшәгәне мәгълүм.

1925 елда мәчет төзелеше, иганә җыю хәрәкәте башлана. Нәтиҗәдә, кыска вакыт эчендә 125000 фин маркасы җыела (2019 = 38000 €) һәм Лотфи әфәнде, чит илләрдән дә матди ярдәм юнәтү өчен, Лондон аша Истанбул сәфәренә чыга. Шул ук елда Истанбулда кинәт хасталанып, вафат та була.

Лотфи Исхакыйга Финляндиядә һәм татар дөньясында тиешле дәрәҗәдә ихтирам, лаеклы хөрмәт бирелгән, дип әйтеп булмый. Атаклы тарихчы Абдулла Баттал-Таймас әлеге шәхеснең вафаты уңаеннан җибәргән кайгы хатында Габдулла Тукай шигыреннән барыбызга да мәгълүм юлларны юкка гына китерми:

«Бармыни бездә гомумән чын кеше кадрен белү?!
Без аны кайдан белик, мискин үлеп аңлатмагач?!» ■

Безнең мирас №10 октябрь 2019

ТАССР

1920 нче еллардагы **татар рухи тормышы**

Индус Таһиров

ТАССР төзү турындагы Декрет, халкыбызның аңа кадәр сәнәкчеләр фетнәсе, коточкыч ачлык кебек фаҗигаләр кичергән булуына да карамастан, мәдәниятебез үсешенә зур этәргеч бирә. Республиканың тууы киң җәмәгатьчелек тарафыннан кайчандыр юкка чыккан дәүләтчелегебезне торгызудай кабул ителә, иҗатчыларыбызга көч һәм дәрт өсти. Бу елларда аларның берсеннән-берсе талантлырак, оптимизм рухындагы әсәрләре дөнья күрә.

Татарлар совет чорына үзләренең милли мәгариф системасы, дистәләгән газет-журналлары, үз театрлары, зур тизлек белән үсә баручы музыкаль мәдәнияте белән килеп керә. Ләкин шул ук вакытта совет системасына хас авырлыклар да үзен сиздерә башлый. Бу иң элек дин өлкәсендә чагылыш таба: имамнарга, дини мәктәп-мәдрәсәләргә һөҗүм башлана.

Дөньякүләм танылган дин галиме Муса Бигиев 1920 елда Николай Бухаринның «Азбука коммунизма» исемле әсәренә каршы «Азбука Ислама» китабын язып, коммунистик идеяне, аның башында торган Марксны тәнкыйтьли. Галим, шушы китабын бастырыр өчен, Ташкентка юл тота, әмма аны шунда ук кулга алалар. М.Бигиев ниятеннән баш тартырга җыенмый: төрмәдән чыгуга ук Берлинга бара һәм андагы «Кавияни» нәшриятында мөһаҗир татар байларының акчасына, Гаяз Исхакый мөхәррирлегендә 1500-2000 данә тираж белән китабын бастыруга ирешә. Әмма галимне янәдән кулга алалар. Дөньякүләм ислам җәмәгатьчелегенең йогынтысы белән генә ул азат ителә. Галимҗан Ибраһимов, Муса Бигиевнең гражданлык батырлыгына зур бәя биреп, болай дип яза: *«Пролетариат үзәге Ленинградта яшәп тә, ул, курыкмастан, революциягә каршы, капитализм нигезләрен яклап, китабын яза алды»*.

Каршылыклар иң элек мәгәриф системасында чагылыш таба. Баштарак – акырынлап, ә соңрак зур тизлек белән дини нигезгә корылган мәгариф системасы таркатыла. Бу процесс РСФСР Халык мәгарифе комиссариатының 1923 елның 3 гыйнварындагы карарыннан соң бигрәк тә зур тизлек ала. Бары тик СССР һәм ТАССР Үзәк Башкарма комитетлары белән ГПУның Көнчыгыш бүлегенең озак тарткалашулары нәтиҗәсендә генә Уфа шәһәрендәге Үзәк Диния нәзарәте каршында бердәнбер мәдрәсә сакланып кала. 1927 елның гыйнварында ВКП(б) Үзәк Комитеты Политбюросы ТАССР Һәм БАССР Үзәк комителарына дини мәктәпләрне тулысынча ябарга һәм моны махсус карар белән ныгытырга тәкъдим итә.

Дини мәгарифкә һөҗүм баштарак Ризаэддин Фәхреддин, Галимҗан Баруди кебек дин әһелләренең тырышлыгы белән акырынайтылып килгән булса да, соңрак аларның да йогынтысы бетә. Атаклы дин әһелләренең үз язмышлары да кыл өстендә кала. Г.Исхакый, Ф.Туктаров, С.Максуди, М.Бигиев, Г.Баттал, З.Кошай, Тимер Яруллиннар, илне ташлап, мөһаҗирлеккә китәргә мәҗбүр була.

Дини-милли мәктәпләр нигезендә совет мәгариф системасы урнаша башлый.

Татар язучылары партия һәм совет эшчеләре арасында. Икенче рәттә (сулдан уңга): 2. Г.Ибраһимов, 3. Ш.Сүнчәләй, 4. Г.Ильясов. Уфа, 1920 [Татарская АССР: история создания (1917-1920гг.). - Казань: Заман, 2017. - С.195.]

Күп урыннарда мәчетләр ябылып, бинаалары мәктәп һәм клубларга тапшырыла. Болар, әгәр дә авыл җыеннарында кабул ителгән күп санлы стандарт документларга ышансаң, халыкның үз теләге белән тормышка ашырылган булып чыга. Чынбарлыкта әлеге эшләр мәҗбүри рәвештә башкарылып, халык мәчетләрне ябуга, аларның манараларын кисүгә зур каршылык күрсәтә.

Шушы үзгәрешләр нәтиҗәсендә, республикада 2118 башлангыч һәм урта совет мәктәбе эшли башлый. 1925 елга аларның саны 10048гә җитә. 162200 укучы баланың 76200е татар була. 1919 елның көзендә Казан университеты каршында рабфак, ә аннан соң татар рабфагы ачыла. 1925 елны рабфакларда укучы татарларның саны 1000гә җитә.

1920-1925 елларда Казанда һәм кантоннарда 10 авыл хуҗалыгы мәктәбе һәм техникумы эшли башлый. 1921 елдан Казанда Авыл хуҗалыгы институты оештырыла.

Республикабызның Кәшшаф Мохтаров җитәкчелегендәге хөкүмәте дә авылга һәм

аграр секторга махсус игътибар бирә. Бу өлкәдә ТАССР җир эшләре буенча халык комиссары Юныс Вәлидов зур эшләр башкара. Аның тырышлыгы белән, Идел буенда һәм башка уңайлы урыннарда «Кызыл байрак», «Чыңгыз» (хәзерге Нагорный), «Мәгариф», «Нариман» кебек яңа татар авыл һәм бистәләре барлыкка килә.

Әдәбиятта татар яңарышының традицияләрен Г.Ибраһимов, Г.Камал, М.Гафури дәвам итә. Алар тирәсендә Кави Нәҗми, Муса Җәлил, Һади Такташ, Фәтхи Бурнаш, Гали Рәхим, Шәйхи Маннур, Хәсән Туфан, Таҗи Гыйззәт, Сәйфи Кудаш, Нур Баян, Салих Баттал, Төхфәт Ченәкәй, Габдрахман Минский, Мәхмүт Максут, Афзал Шамов кебек дистәләгән талантлы язучылар һәм шагыйрьләр өлгереп җитә. Шушы яшь буын кайнап торган бертөрле генә булмаган иҗтимагый тормышта үз урынын эзли. Дискуссияләр, әдәби кичәләр шаулап үтә, үзара бәхәсләр дә булмый тормый. Гадел Кутуй әйткәнчә, бу яшьләр төрле төркемнәргә бүленеп иҗат итә. Бер төркемгә Фатыйх Сәйфи, Закир Гали, Исмәгыйль Рәмиев кергән булса, икенчесенә Кави Нәҗми, Г.Толымбай, Х.Туфан, Г.Сәгъди, М.Гали берләшә. Тагын бер төркемне Гомәр Гали, Газиз Иделле, Һади Такташ, Гадел Кутуйлар тәшкил итә.

Яшьләр күп вакыт сыйнфый һәм революцион идеяләр белән мавыга, элеккеге культура казанышларын инкяр итә. Хәтта Тукай бакчасына да таш атучылар була. Фәтхи Бурнаш, Шамил Усманов, Садри Җәләлдан торган төркем Галимҗан Ибраһимовның иҗатына шик белдерә.

Кайберәүләренең революцион идеяләр белән мавыгулары шул кадәр көчле була ки, алар үз араларыннан да дошман эзли башлыйлар. Мәсәлән, Фәтхи Бурнашны – хан заманнарын сагынуда, Гадел Кутуйны буржуй баласы булуда гаеплиләр. Фәтхи Бурнаш өстеннән университет студентлары катнашында әдәби суд та оештырыла.

Бу чорның гади булмаганлыгы «Җидегәнчеләр эше»ндә дә чагылыш таба. Яшьләр фикердәшләрен Казанда гына түгел, шундый ук процесслар барган Уфадан да эзли башлый. 1928 елны Габдрахман Минский, Гадел Кутуй һәм Төхвәт Ченәкәй, БАССР язучылары белән дуслык мөнәсәбәтләрен урнаштырыр өчен, Уфага килә, каләмдәшләре белән әдәби кичә оештыра. Анда Мәҗит Гафури, Гадел Кутуй, Габдрахман Минский һәм Төхфәт Ченәкәй үз әсәрләрен укый, башка чыгышлар да була. Шушы гөр килеп торган кичәдә үзара бәхәсләр дә кузгала. Тәҗрибәле әдип Мәҗит Гафури яшьләрне берләштерергә, килештерергә тырыша. Нәтиҗәдә, егетләр үзара аңлашуга, килешүгә ирешә, үз фикердәшләрен таба. Казанлылар Уфадан зур ризалык белән кайта.

Әмма кемдер Уфада «Җидегән» исемле яшерен буржуаз оешма төзелде, дигән коткы таратып, аны органнарга җиткерә. Оешма эшендә катнашуда гаепләнеп, Гадел Кутуй, Габдрахман Минский, Сәйфи Кудаш, Нәкый Исәнбәт, Сәгыйть Агиш һәм Төхфәтулла Ченәкәй кулга да алына. Болар – алтау. Ә җиденчесе кем? Тиешле органнар аптырый. Анысын һич ничек тә билгели алмыйлар. Шик берничә кешегә төшә. Аларның берсе «Кызыл Татарстан» газетасының мөхәррире Сафа Борһан булса, икенчесе – Галимҗан Ибраһимов.

Х.Наумов фамилияле берәү «Октябрь» журналының 1931 елгы бер санында болай дип язган: *«Ачыктан-ачык әйтергә кирәк, Галимҗан Ибраһимов большевик түгел, ул – милләтче. Ул татар милләтчеләренең омтылышларын һәм максатларын «Җидегән» исемендәге әдәби агентура аркылы тормышка ашыра»*.

Казан һәм Уфада чыга торган газеталар кулга алынучыларга карата пычрак кампания җәелдереп җибәрә, язучыларны бер-берсенә өстерә башлый. Моны ике республиканың да партия оешмалары хуплап тора. Газеталар, үзара ярышкандай,

«җидегәнчеләр»не һәм «солтангалиевчеләр»не фаш итәргә тотына. Нәтиҗәдә, дистәләгән шактый яман, юкны бар иткән мәкаләләр дөнья күрә.

Тикшерү эшләре ярты елдан артык дәвам итә. 1931 елның 11 сентябрендә ОГПУ үзенең 114819 нчы тикшерү йомгагын: *«Монда гаепләнүчеләрнең җинаятен раслардай материал юк... Аларның эшчәнлеге совет легальлегенең чиген үтми... Эшне туктатырга, кулга алынучыларны азат итәргә»*, – дигән сүзләр белән тәмамлый.

Карар чыга чыгуын, әмма гаепләнүчеләрдән милләтче мөһере алынмый. Шушы мөһер аларның кайберләрен гомерләре буе озата бара. Менә берничә мисал. 1937 елның 25 июлендә Татарстан өлкә комитеты секретаре Галим Мөхәммәтҗанов НКВД органнарына архивлардан «Җидегәнчеләр эше»н казып чыгарырга һәм Кәрим Тинчурин турындагы материалларны табарга боера. Күрәсең, сәләтле драматургка да чират җиткән, аңа да, бернинди катышы булмаса да, «Җидегәнчеләр» шәүләсе төшкән булып чыга.

Сәйфи Кудаш турындагы истәлекләрнең авторларыннан берсе 1941 елны Гадел Кутуйны ТАССР мәгъариф халык комиссары итеп билгеләү мәсьәләсе тикшерелүе турында яза. Мәсьәлә каралганда берәү: «Ул бит контрреволюцион «Җидегәнчеләр» оешмасында торган», – дип әйтеп куя. Шуның белән мәсьәлә үзеннән-үзе ябыла, әмма бу вакыйга шагыйрьнең йөрәгендә тирән эз калдыра. Шуннан соң ул ирекле рәвештә фронтка китә һәм аннан әйләнеп кайтмый.

Ә җиденче «җидегәнче»не эзләү дәвам итә. Шик Сәйфи Кудашка төшә. 1938 елның 10 июлендә Уфада контрреволюцион хәрәкәттә катнашуда гаепләнгән Шаретдинов Шиһаб, сорау алу вакытында 1919 елда кызыллар тарафыннан атылган талантлы шагыйрь Шәехзадә Бабичның әсәрләрен чыгару эшен башлап җибәрүчеләрнең Төхфәт Чөнәкәй һәм Сәйфи Кудаш икәнлекләрен, аларның башкорт авылларында шагыйрь турында материаллар җыеп йөрүләре турында әйтә, икесенең дә «Җидегән» оешмасында торганлыкларын күрсәтә.

Профессор Хатыйп Миңнегулов үз хезмәтләрендә фаҗигале язмышлы Шәехзадә Бабичка зур бәя бирә, аның татар әдәбиятындагы лаеклы урынын билгели, шагыйрьгә карата кылынган гаделсезлекләрне фаш итә. Бабич татар телендә язылган беренче китабын 1916 елда Троицкида үзе бастырган була. 1922 елда аның шигырьләр җыентыгы Казанда Г.Ибраһимов тарафыннан нәшер ителә. Олуг әдип «Вакытсыз үлем» исемле кереш сүзендә: *«Ул үзенең иң кыйммәтле әсәрләрен гади һәм матур итеп, әдәби татар телендә язды»,* – дип ассызыклаган. Шагыйрьнең «Ни өчен кызылларга кушылдык» шигырен мин татар телендә 1919 елда басылган иң беренче нөсхәсеннән махсус укыдым.

Шәехзадә Бабич – Сәйфи Кудашның яшьлек дусты. 1929 елны шагыйрь үлеменең ун еллыгына багышланган кичәдә аның иҗаты турындагы докладны да С.Кудаш ясый. Бу «Җидегәнчеләр эше»нең һәм аның «җиденче»сен эзләүнең иң кызган чагы була.

1937 елны Кудашны Өлкә комитетына чакыралар һәм аңа, болар кемнеке икән, дип, ике дәфтәр күрсәтәләр. Ул аларның Бабичныкы икәнлеген әйтә. Аңардан моны белә торып сорыйлар, чөнки кулъязмаларның соңгы битләрендә Бабичның үз имзасы була. Кудаштан, озаклап, Г.Ибраһимов турында сорашалар. Әле моңа кадәр Ибраһимов кулга алынмаган була. Өенә кайткач, Сәйфи Кудаш бу хакта хатыны Зөһрә ханымга сөйли һәм инде чиратның Ибраһимовка да барып җиткәнлеген әйтә. Алар төне буе Ибраһимовның үз имзасы белән тамгалаган 16 томын һәм 21 хатын яндырып чыгалар.

Мифик «Җидегән»дә катнашуда гаепләп, Кудашны 1950 ел башларына кадәр эзәрлеклиләр, эшеннән алалар, язганнарын бастырмыйлар. Нәтиҗәдә, ул 38 яшендә II группа инвалидка әверелә һәм 141 сумлык пенсиягә яшәргә мәҗбүр була. Ачтан үлмәс өчен күлмәкләрен, бүрекләрен, хәтта чалбар һәм свитерларына кадәр сатырга мәҗбүр була.

1940 елның 26 февралендә партия членлыгына кандидат Сәйфи Кудаш эше Өлкә комитеты бюросында тикшерелә. Язучының 1930 елда «Җидегән» оешмасында катнашуы һәм аны фаш итүдә ярдәм күрсәтмәгәнлеге өчен 1935 елны гаепләнүе тикшерелә. 1957 елда бер төркем башкорт язучылары КПСС Үзәк Комитетына Сәйфи Кудашны татар милләтчелегендә гаепләп хат юллый. Янәсе, ул 1941 елга кадәр башкорт телендә бер генә әсәр дә язмаган.

Сәйфи Кудаш 1964 елны Зыя Ярмәки белән Казанга китәргә тиеш була. Ләкин урамда барганда берәү С.Кудашның башына китереп суга һәм аны аңсыз хәлдә хастаханәгә илтәләр. Хәлен белергә килгән Б.Бикбай һәм Гайнан Әмири җинаятьченең шул хатны язучылардан берсе икәнен әйткән.

1962 елны Татарстан Югары Советы Президиумы рәисе С.Г.Батыев Сәйфи Кудаш исеменә язган хатында, үзенә партиянең XX съездыннан «җидегәнчеләр»гә караган материаллар белән танышу эше тапшырылганлыгын хәбәр итә. «Нәтиҗәдә, – дип яза ул, – андый, советка каршы оешманың булмаганлыгы ачыкланды». Батыев, шул ук вакытта «партия органнарына оялаган намуссыз кешеләрнең 1930 елның 11 сентябрендәге ОГПУ тикшерүе нәтиҗәсен партиядән яшереп калдырганлыкларын да җиткерә[1]. Булмаган яшерен оешманың «җиденче»сенең язмышы шулай хәл ителә.

Ләкин татар әдәбияты үсешен шушы авыр елларда да туктатмый. Г.Ибраһимов, М.Гафури, Ш.Камал, Г.Камал бер-бер артлы затлы әсәрләр иҗат итәләр. Алар арасында Галимҗан Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр»е, «Дала кызы», «Тирән тамырлар»ы, Мәҗит Гафуриның «Кара йөзләр»е, Шәриф Камалның «Матур туганда»сы һәм тагын бик күп әсәрләрне атап була.

Яшь буын әдәбиятчылары арасында татар поэзиясенә саф сулыш өрүчеләрдән Һади Такташны махсус билгеләп үтәргә кирәк. Ул, чын мәгънәсендә, үз иҗатында романтиканы һич кенә дә гади булмаган совет чынбарлыгы белән тоташтыра алучылардан берсе. Аның «Гасырлар һәм минутлар», «Провокатор» кебек әсәрләре татар әдәбиятының алтын фондына керде.

Ил картасында ТАССР барлыкка килүнең бер сәбәпчесе – атаклы революционер Шамил Усманов та бер-бер артлы матур әсәрләр язган. Ул шушы елларны җәмәгатьчелек тарафыннан киң танылган «Канлы көннәрдә», «Кызыл байрак астында» һәм романтик рухтагы «Памир радиосы»н иҗат итә.

Романтик рухлы әсәрләр тудыручылар арасында Кави Нәҗминең дә үз урыны бар. Аның шушы еллардагы хикәя һәм шигырьләре актив укыла торган әсәрләр арасында була. «Шобага» хикәясе аеруча аерылып тора. Әдипнең биографиясендәге гражданлык батырлыгын раслый торган бер факт аерым бәяләүгә лаек. Татарстан пролетар язучылары ассоциациясе җитәкчесе кабинетына берәү Гадел Кутуйны «Җидегән»нең оештыручысы буларак фаш итү нияте белән килә. Кави Нәҗми аны шунда ук кабинетыннан куып чыгара.

Әсәрләре татар сәхнәсендә зур уңыш казанган Галиәскар Камал, яңа татар

---

[1] Кудашева С., Кузеев Р. Жизнь, длиною в один век. Воспоминания. – Уфа: Изд. Восточный университет, 1998. – С.116.

драматургиясен барлыкка китерүчесе буларак, халык традицияләренә таянып иҗат итә. Ул, профессор Йолдыз Нигъмәтуллина язганча, халык тормышын динамикада, гөрләп торган рәвештә, көчле сатирик образлар ярдәмендә бирә белгән. Аның әсәрләренә төгәллек, үткенлек хас.

Тамашачыларның игътибарын җәлеп иткән пьесалар арасында Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану»ы, Кәрим Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар»ы һәм «Казан сөлгесе» аерым урын алып тора.

К.Тинчурин – Г.Камал традицияләрен уңышлы дәвам итүчеләренең берсе. Аның иҗатындагы яңалык Салих Сәйдәшев белән бергә музыкаль драмага нигез салу була.

Салих Сәйдәшев үзенең иҗат юлын «Сәйяр» труппасында башлап җибәрә. Талантлы музыкант хәрби хезмәттә дә Оренбург шәһәрендәге Беренче армиянең политбүлеге оештырган татар драма театрының пианисты була. Композиторның аннан соңгы тормышы Казанга бәйле. Ул 30дан артык пьесаны музыка белән баета. Иң уңышлы спектакльләр арасында «Зәңгәр шәл», «Наемщик», «Кандыр буе», «Бишбүләк», «Күзләр» югары урын алып тора.

Драматургиянең уңышлары Таҗи Гыйззәт һәм композитор Җәүдәт Фәйзинең иҗади дуслыкларына да бәйле.

Мәдәни тормышның иң зур вакыйгаларыннан берсе – В.И.Виноградов һәм С.Х.Габәши тарафыннан иҗат ителгән беренче татар операсы «Сания». Аның төп партияләрен С.Аида, Г.Кайбицкая, М.Рахманкуловалар башкарган.

Бу елларда китап бастыруга һәм китапханә челтәренә дә зур игътибар бирелә. 1923-1824 елларны Татарстан китап нәшрияты 107 исемдәге китап нәшер итә. Аларның 88е – татар телендә. 1924-1925 елларда – 150 китап, 143е – татар телендә. 1925 елны республикада 150 китапханә, 211 клуб, 305 изба-читальня, 70ләп кызыл почмак эшли.

1921 елның 19 апрелендә ТАССР Мәгариф комиссариаты каршында, Галимҗан Ибраһимов җитәкчелегендә, Академүзәк барлыкка килә. 1924 елга анда уку-укыту әдәбиятын язуны координацияләү өчен авторлар коллективлары формалаштыру тәмамлана, I, II баскычлы мәктәпләр өчен программалар төзелеп бастырыла. Академүзәк тарих, археология, этнография, татарны өйрәнү һәм тюркология фәннәренең үсешенә дә зур игътибар бирә, балалар әдәбияты китапларын әзерләп чыгаруны да җайга сала.

Зур-зур каршылыклар, фаҗигале вакыйгалар булып торуга да карамастан, 1920 нче елларда татар мәдәнияте һәм әдәбияты зур уңышларга ирешә. Аңа киләчәк үрләрне яулау мөмкинлекләре ачыла. Шул елларның ахырында – 1930 нчы елларның башында ныгып, 1937 елны иң биек ноктасына җиткән репрессияләр бу мөмкинлекләрнең тормышка ашырылуына киртә куя. Йөзләгән татар зыялылары әлеге сәясәтнең корбанына әверелә. ■



АРХЕОГРАФИК КӨНДӘЛЕК*

Миркасыйм Госманов

II сәфәр.
Рязань өлкәсе, Касыйм шәһәре
23 июль-22 август 1964 ел

3.08.64.

Бүген ял иттек. Бүртенгәнче йокладык. Алтын комда озак-озак кызындык. Күшеккәнче су кердек. Төштән соң мунчага бардык: үзебезне дә, китап тузанына каткан күлмәкләрне дә юдык.

4.08.64.

Райисполкомда тиешле документлар алгач, Шырын (Подлипки) дигән авылга киттек. Касыймнан ерак түгел.

Бригадир өйдә юк булып чыкты (Исмаил Минаев). Әтисе белән таныш. Авыл элек шактый зур булган[1], эре-эре байлар, хәтта миллионерлар яшәгән, мәсәлән, Ширинскийлар. Авыл шуларның утары булганлыктан, «Ширин»нан «Шырынга»

---

*1964 елгы көндәлекнең ахыры. Башы журналның 9 нчы (2019) санында.

[1] Бу вариантта төшеп калган: «Авыл элек шактый зур булган (90 йорт), ә хәзер тузган. 30 гына йорт».

күчкән, ә болар исә мәгълүм Ширин мирза нәселе... Әммә хәзер авыл бик тузган. Бер өлеше генә калган.

Зиратка барып ташларны укып йөрдек. Борынгы ташлар бер дә юк, гел XIX йөз уртасыннан соңгылар. Мәгәр бу таштa зират шигырьләре бик күп.

Берничә йортка кереп, кульязмалар караган булдык – җүнле бернәрсә дә юк. Булганнары, начар саклануудан, тәмам череп беткәннәр...

Бригадир кайтмаса да, өенә кереп кундык. Әтисе бик кызык кеше икән: бөтен гомере повар булып узган, эшләмәгән рестораны, йөзмәгән пароходы, булмаган шәһәре калмаган. Күпне күргән, шактый урыслашкан, ләкин үзе фанатик!..

Үзара сөйләшкәндә халыкның теле бик сәер иде: бөтен сүзләрдә дә «к» авазларын йоталар. Сәер генә диалект: «Сез эм буласыз? Айдин илдеез? Ит моннан!» Әмма безнең белән чатнатып әдәбичә сөйләшәләр. Хорафалык та җитәрлек. Ләкин ул бик сәер кыяфәт алган: динсезлек белән укмашып үсә...

Бу авылның күп халкы төрле шәһәрләргә таралып беткән. Һәрбер зур шәһәргә диярлек... Күбесе сәүдә өлкәсендә эшли...[2]

5.08.64.

Татарбай (Торбаево) дигән авылга килдек. Шырыннан дүрт чакрым, 25-30 йорт. Бик тузган иске авыл. Ә йортлары! Зур, икешәр кат. Таш капкалар. Тимер ишекле келәтлеләр. Барсы да ишелеп төшәр хәлгә җиткән... Әйе, бу авылда элек бик хәлле кешеләр, зур байлар яшәгән.

Без төшкән Маһирә түтәй дә ярыйсы гына хәлле тормыш кичергән һәм белдекле генә гаиләдә үскән күренә. Әйтүенә караганда, аның ире гомер буе буфетчик булып ярты Рәсәйне таптаган.

Әбинең үзен тотышы да, тәкәллефле һәм әдәпле мөгамәләсе дә аның бик хәлле катламнан чыккан булуын күрсәтә. Үзе карт, өй җиһазлары үзеннән дә картрак. Ләкин алар да элек бик затлы, солтанатлы булганнар: камыш урындыклар, йомшак креслолар, сервант-шкафлар – барсы да патша заманыныкы... Әбинең савыт-сабасы да – бай сервизның калдыгы... Бу әби Әбрарга бигрәк тә ошады. Сокланып бетә алмый.

Авылны йөреп чыктык. Рәтле әйбер юк. Ләкин һәрбер иске өйдә йә ялгыз карчык, яисә сыңар бабай. Яшьләр бер дә юк, диярлек...

Зират та бик ташландык иде. Иске ташлар юк. Монда да зират поэзиясе үрнәкләре шактый. Менә Сөнчәлиевләрнең берсенең кабере (димәк, Сөнчәлиев фамилиясе шушы тирәләрдән чыккан...). Мәгънәсез генә бер шигырь.

6.08.64.

Җәяүләп кенә Яубаш (Болотце) авылына бардык. Татарбайдан 1,5 км. Көн болытлы, пыскак яңгыр. Картлар белән сөйләшәбез. Авылда элек 300-400 йорт булган. Ә хәзер 60-70 кенә. Монда да шул элекке зур биналарның, биек таш капкаларның, сарай-амбарларның шәүләләре. Һәр йортта ялгыз карт-коры. Биналар, архитектура авылга хас түгел. Һай, байлык чоры сизелеп торган хәерчелек бик ямьсез икән.

Халык төрле шәһәрләргә таралып беткән. Элек бөтен тирәне ялмап, барлык Рәсәй буенча юырткан Касыйм байларның бер оясы менә шулай сүтелеп-ишелеп утыра...

[2] Беренче вариантта болай язылган: «Халык бик хорафый: бернәрсәне аңламасалар да иске китап кыйпылчыкларына илаһи ихтирам белән карыйлар. Ә бер өлеше, киресенчә, бернәрсәгә дә «атаң-анаң» бармы, дип тормыйлар. Гомумән, Касыймдагы татарлар гаҗәп кызык һәм трагик процесс кичерә. Халыкның, элек яшәгән халыкның өлешеннән өлеше генә калган, башкалары төрле якларга китеп таралганнар. Мәсәлән, безнең хуҗабызның дүрт баласы хәзер Казанда тора. Наҗия исемле бер кызы Матбугат йортында ашханәнең буфетында эшли икән. Әмма шунысы характерлы: читкә китсәләр дә касыймлыларның күбесе сәүдә даирәсендә эшли...».

Кульъязмалар очрамый. Бер әбидән икенче бабайга күчәбез. Ташландык ишегаллары. Кайбер җирдә ялгыз-ярты картлар, йортларны бер читеннән сүтеп, утынга яга башлаганнар. «Әйбәт яна!» – диде бер бабай.

Кайберәүләрнең әйтүенә караганда, элек авылда укымышлы кешеләр шактый булган. Кульъязмалар да күп очраган. Ләкин картлар белән бергә алар да бетә торалар. Бик күпләрен илтеп кабергә күмгәннәр. Язмыш безгә дәлил дә күрсәтте. Кәрим абзый Төхфәтуллин дигән берәүгә кердек. Максатны белдерүгә, ул абзарга чыкты да, дыңгычлап тутырган зур капчык алып керде: «Белмим нинди китаплар икәнен, вакыт булганда зиратка илтеп күмәргә дип торадыр идем». Без актара башладык. 10-11 ярыйсы гына кульъязма чыкты. Менә кызыклы гына «Чупаннамә»...

Ә мондый тулы «капчыкларның» күпмесе күмелде икән?!.

Кичен Маһирә әбинең чормасын актарып, тузанга батып төштек. Бик тузган, һәр калаенда кырык тишек... Әби әйтә: «Йорт җирдә тормый, җилкәдә тора». Әйе, Касыймда «җилкә» калмаган.

7.08.64.

Бүген Касыймга кайтып, аннан ары Карлар (Ахматово) авылына барачакбыз. Без булган авылларны (беренә бара алмадык) «Дүрт сала» (Яубаш, Ширин, Татарбай, Биемсала) дип йөртәләр икән. Ә теге якны «Кара әймәк» дип кимсетеп атыйлар. Күрәсең, алар мужиграк булганнар. Бәлкем, элекке ханлык заманында «кара халык» булгандыр... Карап карыйк...

Колхоз машинасына утырып Касыймга килдек, анда тапкан кульъязмаларны Фәрхәнәз апаларга илтеп куеп, бакчада ял иттек һәм төштән соң Карлар (Ахматово) авылына килдек. 17-18 йорт. Бик иске. Йолкыш, халкы да әллә ничек әрсез, әйтергә ярса, надан һәм әдәпсез. Ярлылыкның да исе аңкып тора...

Фатирга Зәйнәп әби Альтбикова дигән шактый кире, шул ук вакытта бик беркатлы бер әбигә туктадык...

Урамга чыгып берничә кеше белән сөйләшкән идек. Артык бернәрсә дә маташмады.

Бу тирәдәге авыллар: Карлар (Ахматово, авыл советы, 15 татар хуҗалыгы), Мултан (Мунталово – 25 татар хуҗалыгы), Субак (Собакино – 12 татар хуҗалыгы), Түбән авылы (Шекино – 35 хуҗалык), Шакшан (Чыгашаново – 8), Тимгән (Тимгешево – 15 татар хуҗалыгы), Казаково (3-4 татар хуҗалыгы), Әлеш (Алишево – 3-4 татар хуҗалыгы) һ.б.

Без иртәгә берничә авылдан эшли башларбыз. Ләкин күп һәм әһәмиятле әйбер чыгасына ышанып булмас кебек, кем белсен, бәлки...

8.08.64.

Карлар авылының зиратына бардык. Бик ташландык, арчылмаган, эче черемә белән тулган...

Әлеш (Алишево) авылына килдек. 3-4 йортлы икән. Монда да шул карт-карчыклар гына. Элек 16 йорт булган. Бакый абзый дигән бер карт белән сөйләштек. Буфетчик булган, Николай IIне һ.б. патша-князь нәселләрен сыйлап йөргән. Ленинны да ресторанда ике мәртәбә ашаттым, дип сөйли, дөрес булса...

Мулты авылына юнәлдек. Юлда нарат урманына кереп, ял итеп яттык. Мулты карап торуга ярыйсы сыман гына (25 татар хуҗалыклы). Халык ярлы гына тора кебек. Берничә өйгә кердек – нәтиҗәсез... Зиратын карадык: авып төшкән иске ташлар, бик күпләре яшь (XIX гасырның икенче яртысы), күбесендә төркичә язулар...

Маһирә әби Бермелеева дигән бер әбигә кереп чәй эчтек. Китап-фәлән чыкмады. Алардан чыгып, Нәфисә дигән бер тол хатынга кердек. Бик ачык чырай белән

сөйләшеп утырды. Барлы-юклы китапларны чыгарып бирде. Бер Коръән алдык: бик матур язылган...

Шакшан (Чыгашаново) дигән авылга килдек. Абдулла абзый Янгуразов дигән кешегә кердек... Ул биредә туып үскән, яшь чагында повар булып эшләгән, хәзер карт. Мулла да булып маташа бугай; китап-фәлән чыкмады. Бу авыл бик соңгы вакытта күчерелеп китерелгән. Элек 18 йорт булган. Хәзер татарлардан 8 йорт калган...

Кичен киногa барган булдык.

9.08.64.

Касыйм шәһәренә кайтып урнаштык. Аллага шөкер, сасы истән, ярылган ярлылыктан котылдык. Иртәгә, мөгаен, ял итәрбез.

10.08.64.

Безне эзләп Иван Александрович Китайцев – Касыймдагы тарих белән шөгыльләнүче карт пенсионер, һәвәскәр тарихчы килде. Бик кызыклы гына мәгълүматлар бирде:

1. Революциягә хәтле Шаһгали каберен казып караганнар, аннан чыккан язулы чүпрәк Мәскәүдә тукыма институты музеенда саклана. Язулары сакланмаган.

2. Музейда Касыйм тарихына, ихтимал, җирнең экономик тарихына караган документлар бар.

3. Бик кызыклы, бай орнаментлы Коръән күчермәләре бар.

Музейның язмышы турында бик урынлы фикер йөртә, чын күңелдән кайгырта... Киңәшләре бик кызык. Безгә ихлас күңелдән кайсыбер материалларны алдыртып алырга киңәш бирә... Үзе һәр елны диярлек археологик казынуларга катнаша, кайчакларны үзе дә мөстәкыйль рәвештә һәвәскәр казынулар алып бара... Тарихка ихлас күңелдән гашыйк булган кеше... Яшенә (77дән артык) карамыйча тере, сәламәт, киң зур ак сакаллы, ачык йөзле бу карт күңелдә ихтирам уята!.. Бик күп белән кызыксынган карт... Сөйләшә-сөйләшә чәй эчеп утырдык. Себердә дә кунаклап кайткан...

Мәчетне япкан вакытта берничә ящик китаплар калган...

Карт хәзер ялгыз, берүзе генә тора икән... Караңгы кичкә хәтле сөйләшеп утырдык...

11-12.08.64.

Ял итеп, шәһәр һәм аның тирәләре белән таныштык. Вакыт-вакыты белән көчле генә яңгырлар булып алды. Касыйм тирәсендәге авылларның моңарчы без булганнарына кыскача нәтиҗә ясап була:

1. Бу авыллар экономик һәм культура ягыннан бик артта калганнар. Авылларда эшкә ярарлык халык бик аз, карт-коры (һәр икенче өй) һәм әзләп-әзләп хатын-кыз. Яшьләр бөтенләй диярлек юк (шәһәргә китеп беткәннәр, ә үсеп җиткәннәре китә торачак, ягъни киләчәккә өмет юк).

2. Мәдәният һәм милли горурлыкның бернәрсәсе дә калмаган: болар чын мәгънәсе белән татар да (хәтта Касыйм татарлары булса да) түгелләр, руслашып та җитмәгәннәр: «от своих отошли, к другим не пристали». Хәзергә шулай. Менә шул ягын исәпкә алганда халыкның рухындагы төшенкелек, мәгънәсез вә хәлсез йомыклыкны аңлап була. Шушы җирләрдә яшәп мөстәкыйль бер этник группа булып тора алачакларына үзләре дә ышанмыйлар һәм шуның өчен качып югалуны чамалап торалар... Элек йөзләп йорт булган авылларда хәзер бер-ике дистәдән артык йорт түгел... Аларында да рус катнаш. Бер деталь: русларның йортларында тормыш рухы, яшәеш сәләте бар

(рус авылларында да шулай). Бик күп татар авыллары бөтенләй юкка чыккан: халкы китеп таралган...

3. Касыймнан китүчеләре нигездә түбәндәге шәһәрләргә барып урнашканнар: Мәскәү, Ленинград, Казан, Ташкент... Авыллардагы һәрбер гаиләнең диярлек шул шәһәрләрдә уллары-кызлары яки якын туганнары торалар, ә кайберләренеке берничә шәһәрдә яшиләр...

4. Тел ягыннан, мондагы татарларның теле чыннан да бер аерым утрау булып тора. Калын һәм нечкә к, г-ләрнең йотылуын хәзергә аңлатуы читен. Вокализм исә кыпчак теленә, бигрәк тә кырым шивәсенә тарта. Лексика да шулай ук. Рус теленең тәэсире бик көчле. Һәм кешеләр рус телен бик әйбәт беләләр. Яшьләр өчен ул ана теле кебек... Әмма барыбер бу телне, бу культураны үзләренекедәй итеп сөеп бетермиләр... Ярылып яткан каршылыклык. Касыймлылардагы бу чирлекне бетерү өчен бик интенсив рәвештә татар авылларында рус культурасын яхшылап таратырга – мәгәр кәгазьдә генә түгел һәм халыкның социаль, экономик дәрәҗәсен күтәрергә кирәк. Ләкин, дөресен әйткәндә, руслашып беткәнче, бу халык төрле якка таралып бетә һәм алар урынына руслар килеп утырыр. Узар еллар, мәгълүматлар үзгәрер һәм тарихчылар язарлар: татарлар руслар тарафыннан йотылып беттеләр, дип! Ләкин бервакытта да аларның сөрелеп чыгуларын күз алдына китерә алмаслар... Чыннан әйткәндә, аларны беркем сөрми, ә үзләрен-үзләре сөрәләр, ягъни таралып, сибелеп бетәләр... Ә тарих фәне теорияләр ясап ята...

5. Этник группа буларак, мондагы халык элек тә бик таркау булган. Икенчедән, аларның болай бик тиз тузып бетүләренә элек-электән килгән иҗтимагый һәм экономик паразитлык сәбәптер: элек бөтен халкы белән Мәскәү патшасы акчасына яшәгән, аннары сәүдә артыннан, тиен эзеннән куып йөргән, тора-бара ресторанчы, буфетчы, официант, лакей булып йөргән. Кул көче белән материаль культура тудырып, чын экономикасының тотнаклы нигезен булдыру өчен бернинди омтылыш булмаган. Ә паразитлык тиешле нәтиҗәсен биргән инде: ата-анасы калмаган бу халыкның. Шулай кирәк!.. Бөтен ата-бабаң официант, лакей булып гомерен уздырган, синең мөселман теле бетте, дин бетте, дип зарланырга хакың юк инде. Әгәр җиң сызганып эшләгән булсаң, чын капиталны промышленностька җиккән булсаң, әлбәттә, бүгенге хәерчелеккә төшмәс идең...

13.08.64.

Бераз эшләштерергә дип музейга килдем... Директоры Суворова Лидия Никифоровна ялдан килгән икән; ачык кына сөйләшсә дә, аңгырарак кына кеше кебек...

1900, 31 майда Газизулла Лябичков тарафыннан нигезләнгән кызлар мәктәбе укытучысы Хәкимә Агиевага бирелгән еллык имтихан шәһадәтнамәсе... Хат бланкасына кулын куйган. Имзалар: назиры – Фәтихетдин Бәширов; мөгаллимә – Шәмсимөнәвәр Бәширова.

1921-1922 елларда Касыйм шәһәрендә татарлар тарафыннан оештырылган «Касыйм халык театры» куйган пьесаларның программалары. 8 данә. «Таһир-Зөһрә» ике көн барган.

Моңарчы очраган программаларның барысында да диярлек оештыручы, куючы бер кеше: К.Дәүләткилдиев. Декоратор да бер: И.И.Пережогин. (Бу Пережогин шул елларда рус драмасына җитәкчелек иткән.)

Театр «Чулпан» исемендә булган. Меценат булып Кастров дигән бай ярдәмләгән...

1919 елдан татар театры актив эшли башлаган. Рус халык театры революциядән

соң 1918 елда җанланып китә. Һәвәскәр рус сәнгать түгәрәге шушы гасырның башыннан башлана.

Татар театрының нигезен салучы Дәүләткилдиев Горькийның «На дне»сында «татарин» ролен уйнаган һәм Мәскәү, Петербургтан килгән кунакларны да шак калдырган....

Рус һәм татар халык театрлары бик дуслыкта, күмәкләшеп, туганлашып эшлиләр. И.И.Пережогин, бик олылап, татар артистларын, бигрәк тә режиссерны искә ала... Әмма картның фикере бераз бутала төшкән... Шулай да бер кызык детальне искә төшерә: «Театр өчен сәхнәгә чыгарган ризыкларны, пәрдә төшүгә, декораторлар талап алалар иде, икенче пәрдә өчен өстәмә куярлык әйбер калмый иде. Бик ачлык еллары иде бит. Шулай да бөтен коллектив бик күңелле эшли иде...»

Театр «Татар тавы» дигән тау өстендә «Малая глухая» урамында булган...

14.08.64.

Әхмәт ага Ширинский дигән олы яшьтәге картка кердем. Берьялгызы тора икән. Революциягә хәтле зур кинотеатр хуҗасы булган. Хәзер бик карт. Революциягә хәтле Камил Мотыгый-Төхфәтуллин үзенең труппасы белән 1916 елда Касыймга килеп концертлар куя. Халык бик күп була. Ширинскийлар театрында була. Революциядән соң «Чулпан» театры «Зәңгәр шәл» әсәрен куя, карт үзе барып карый. Әмма бу карт та күп нәрсәне хәтерләми, фикерләре чуала төшкән... Яшь чагында бу да буфетчы булган Харбинда. Ашыгып, гостиницага кайттым.

Музейга килдек. Программаларны карадык. Берничә татар программасы рус телендә басылган.

Фәрханәз апа сөйли: «Иң актив эшләүче, үзәк оештыручы Котлымөхәммәт Дәүләткилдиев, Агиевлар, Виргазова, Булатовлар».

«Таһир-Зөһрә» – уңышлы, 4-5 мәртәбә; «Галиябану» – бик күп кабатлана; «Зәңгәр шәл» – 2-3 мәртәбә; «Хаҗи әфәнде» – кабатлана.

Революциягә хәтле иң беренче мәртәбә балалар өчен («Беренче чәчәкләр») Сәгъдия Булатова (укытучы) куя, Кастровлар йортында. Бу ханым Касыймда хатын-кызлардан иң беренче буларак партиягә кергән кеше. Әмма революциягә хәтле театр куяр өчен мөмкинлек бик аз, авыр була... Революциядән соң 18 нче елдан башлап татар яшьләре Котлымөхәммәт Дәүләткилдиев тәэсирендә оеша. Аны, яратып, «Котыш абзый» дип йөрткәннәр. Фәрханәз апа Бәширова данлы суфлер була (25 елга якын).

Революциягә хәтле дә яшьләр оешмасы була: «Берек», «Ялкын». Болар китап уку, мәгърифәт тарату буенча актив эш алып баралар... Концертлар, күңелле кичәләр гаҗәеп еш була. Бу культура эше Икенче дөнья сугышы башланыр алдыннан туктала һәм сүнеп кала.

«Чулпан» театрының эшләрен сугышка хәтле педагогик училищеның студентлары һәм укытучылары дәвам иттерәләр. Мәсәлән, 1936 елда «Зәңгәр шәл» куела...

15.08.64.

Көн яңгырлы иде. Төшкә хәтле өйдә яттык. Сәгать 3ләрдә Кәрим Бахчиев дигән кешегә бардык. 3 сандык иске китаплар һәм кулъязмалар бар икән. Бу нөсхәләр аларга мәдрәсәдән калган. Шактый вакыт карап утырдык; 110-120 кулъязманы аерып куйдык. Арасында шактый борынгылары да бар. Гарәпчәләр. Төркиләрдән дә искеләре юк түгел. Мал безнең өчен бик шәп, мәгәр хуҗалары акча өмет итәләр бугай... Ә бездә акча юк. Хәйләләп кенә шомартып булса иде. И, хәерчелек!

16.08.64.

Көн бик әшәке...

Ә Шамил һаман юк, менә дүртенче көн көтәбез. Һәр көне бер ел кебек. Мондагы туганнары алдында да оятлы булып беттек.... Һай, бу вәгъдәсендә тормаган кешене!.. Ичмасам, бер-ике җөмлә язып, кайчан киләсен яки килмәсен әйтер иде!..

Саҗидә апа Абдюкова дигән апага бардык. Ярыйсы гына берничә кулъязма алдык. Башка китаплары да шактый икән... Барысын да алып булмый шул...

Юлдан Мәхүзә апа Итакаеваларга кереп чыктык, иртәгә килергә кушты...

Ә көн бик күңелсез. Салкын... Акча да бетеп килә... Ә Шамил юк та юк... Ничәнче көн инде рәхәтләнеп тәмәке тартмадык... Әбрар китәргә җыена. Димәк, мин тагын берничә көнгә калачакмын...

17.08.64.

Көн бүген дә әшәке... Болыт. Караңгы... Ә Шамил һаман юк...

Мәхмүдә апа Итакаеваларда булдык. Кичен килергә вәгъдәләштек.

Зиратка кердек. Сафа абзыйдан (мөҗавир) берничә кызыклы гына кулъязма алдык... Мөхәммәт Ширинскийга керергә!

Кәрим Бахчиевларга кердек. Кулъязмалар арасында бик әйбәтләре, бик борынгылары бар. Барсын да буш бирергә булдылар... Бер шамаил дә.

Әмма бүген көн бик уңышлы тәмамланды; Шамил дә килде. Бахчиев Кәрим абыйларның бай көтепханәсен эләктердек. Безнең бик тәкъва һәм эш белгән кыяфәтемез уңай тәэсир ясады бугай... Тәмәке дә булды. Акчага да көч төшмәде... Иртәгә эшләрне йомгаклыйбыз инде!..

18.08.64.

Бүген иң элек ящиклар алдык. Кәрим абзый Бахчиевлардан китапларын ташыдык. 2 ящик китап булды. Багаж белән пароходка салып җибәрдек. Эшләр шулай тәмамлана киләләр. Ял иттек, Фәрхәнәз апалар белән озак кына сөйләшеп утырдык.

Мунчага барып бөтен керләрне, «гөнаһ-шомлылыклар»ны юдык. Иртәгә очабыз...

19.08.64.

Самолет белән Муромга очтык. 30 минут. Сәгать 1дә җиттек. Кичке сәгать 6да билет алып, поездда Казан тарафына юнәлдек. Вагонда халык бик күп иде...

20.08.64.

Иртәнге сәгать 4. 40 минутта Казанга җиттек. Шулай итеп, II археографик экспедициянең кыр эшләре тәмам булды. Киләсе елны тагын Касыйм шәһәренә бер экспедиция оештырырга кирәк....

P.S. Әбрар Кәримуллин белән эшләве бер яктан күңелле һәм җиңел: кеше белән сөйләшә белә, һәрнәрсәдән хәбәрдар, шул ук вакытта авыр: торып-торып кәҗәләнеп ала, тәти кызлар кебек сыкранып, зарлана башлый.

Көндәлекләрне басмага тарих фәннәре докторы
***Диләрә Госманова** әзерләде.* ■

ТҮРК ТАРИХЫНА БЕР КАРАШ*

Нәкыйп Каштанов

Болгарларның килеп чыгышы турындагы бәхәсләрнең әлегәчә тынганы юк. Халык буларак алар беренче мәртәбә 354 елда Көнбатыш Рум империясендә төзелгән «Хронограф» хезмәтендә һәм V гасырга караган бер кулъязмада *bulgares* рәвешендә телгә алына. Дөрес, бу чыганаклар әлеге атаманы *зихлар,* ягъни көнбатыш Кавказның *адыг* этник төркеменә карата куллана. Әмма адыгларның этногенезы хәзергәчә ачыкланмаган, ягъни аларның һун яисә болгар кабиләләреннән килеп чыгуы да ихтимал.

Кытайларның *уйгыр* халкын төрлечә атавын игътибарга алыйк. Арада *вейх* варианты да бар. Бу исә, яңгырашы буенча, *зих* сүзенә охшаш. Өстәвенә, борынгы төрки топонимнар арасында, тәгаенрәк әйтсәк, Мәхмүт Кашгарый туган якларда, *Adhig* җирлеге очрый. Бу – *азык* (үлән исеменнән) яисә, сөзәк ярны истә тотып, *ачык* (мишәр диалектында – *ацык*) кәлимәсеннән ясалырга мөмкин. Зихлар болгарларга тугандаш *тугыз угыз* кабиләсе дә була ала.

Галим А.Х.Халиков искәрткәнчә, 350 нче елларда *угыр-алан* кабиләләре һуннар тарафыннан җиңелә һәм Кавказ буйларына күченә. Андагы халыклар арасында IV-V гасырларда *болгар* атамасы күренә башлый.

Болгар сүзенең мәгънәсен ачыкларга тырышкан егермеләп фараз билгеле.

И.Д.Шишманов, Ю.Немет, М.З.Зәкиев хезмәтләре, минемчә, аеруча игътибарга лаек. Аларча, болгар – *фетнәче, баш күтәрүче, бөек угыр* мәгънәләрен белдерергә мөмкин. Кайбер галимнәр иран-фарсы телендәге *bulgar* сүзенә басым ясый: *bul (bala)* – зур, бөек + *gar* – кул, өлеш, урда.

Мин кытайларның *та-та* иероглифын Мәскәү дәүләт университеты аспиранты

---
* Хезмәттән бер өзек.

Элина Карнашева ярдәмендә өйрәнергә, аңларга омтылыш ясадым. Кытай телендә *-р* авазы юк. Тулаем ул, әлбәттә, *та-ат-эр* буларак яңгырар иде. Бу турыда калмык галиме Әренҗән Карадауан да искәртә.

Та-та иероглифын өлешләргә таркатсаң, *кун эшкәртүче оста* мәгънәсе килеп чыга. Күн эшкәртүдә болгарларга тиңнәр булмаган. Шуңа өстәп, ул чорның иң яхшы күнен *болгари* дип атауларын да искә төшерик. Димәк, *татар* һәм *болгар* атамалары аерым бер һөнәр иярәренең исеменнән ясалырга да мөмкин, ягъни Бөек күчеш чорында *күнчеләр (татарлар)*, Кавказ итәгенә килеп урнашкач, *болгарларга* әверелгәннәр.

Бер уңайдан *кыпчак* кабиләсен дә хәтердә яңартыйк. Кыпчаклар Идел Болгарстаны чикләрендә XI гасырда *коман* исеме белән барлыкка килә. Бу атаманың да нигезендә үзгәртелгән *кун* сүзе барлыгын күрәбез.

Шиһабетдин Мәрҗани хезмәтләрендә галим Әхтәри Мостафа бине Шәмсетдин әл-Акхисари телгә алына. Аның сүзлегендә *хыфжак (кыпчак?) – татар биге* дигәнне аңлата. Шунда ук без янә *кун* сүзе белән очрашабыз. Монда ул *затлы кеше* мәгънәсен белдерә.

Димәк, *болгарлар* да, *кыпчаклар* да – *татарлар* булып чыга? Бер үк халык төрлечә аталган гына?!

Шәмсетдин әл-Димашкый исемле үзгә галим кыпчакларның һәммәсе дә төркиләр, дип язып калдырган. Алар һинд-европалы *ху* кабиләләре белән кушылган. *Һуннар* дәүләте җимерелгәч, 439 елда *ашина* кабиләсеннән 500 гаилә *җуҗаньнар* янына күченә һәм Алтай тавы тармакларында урнаша. *Ашина* кабиләсенең идарә итүче катламы *түрк* дип атала башлый. Алар, тимер эшкәртү эшен үзләштереп, тиз арада җуҗаньнардан мөстәкыйльлеккә ирешә.

Галим С.Г.Кляшторный фикеренчә, *түрк-ашина* кабиләләр берләшмәсенең төп өлеше төркиләрдән һәм *иран-фарсы* яисә *тохар* телләренең берсендә сөйләшкән җирле *турфан* халкыннан оеша. Аннары вак Алтай кабиләләре аларга кушыла.

Тора-бара, 460 елдан соң, көньяк Алтай итәгендә *Хәсәншад һәм* ябгу *Туу* белән *Бумын* җитәкчелегендәге *түркләр* Җуҗань дәүләтен тар-мар итә һәм бу җирләрдә куәтле *Түрк каганатын* (*каһанлыгын)* төзи.

С.Г.Кляшторный раслаганча, *ашина* – әлеге ыругка нигез салган зат әнисенең нәсел исеме. Кытай галимнәре исә ашинаның ерак бабалары *сак* кабиләсе булган, дип фаразлый. Мөгаен, бу фаразда хаклык бардыр, чөнки татар халкында бүгенгәчә «Сак-Сок» бәете популяр, аны яттан сөйлиләр, көйлиләр, китапларда бастыралар.

Түрк төшенчәсенең килеп чыгышын *согдый (сүгъдик)* теленә бәйләп күрсәтәләр. Мәгълүм *kök türk* сүзтезмәсендәге «күк» өлеше исә фарсы-иран теленә барып ялгана һәм «зәңгәр» мәгънәсен белдерә. Беренче түрк (төрки) каһаннарның исеме дә, түрк дөньясындагы бик күп титулларның этимологиясе дә шул телгә барып тоташа.

Далада исә, билгеле ки, йә бер ыруг, йә икенчесе өстен чыга. Алар үз конфедерациясен (берлеген) төзи. Тарихның борылыш ясаган бер чорында *уйгырлар* шактый ныгый һәм *тугыз угызларны* буйсындыруга ирешә. Яңа дәүләт *Уйгыр (каһанлыгы)* исемен ала (744-840). Бу каһанлык Урта Азия цивилизациясен коруда хәлиткеч роль уйный.

Кыргызлар 840 елда Уйгыр каһанлыгын тар-мар итә. Шунысы кызык: кыргызларны бу эшкә, галим В.В.Малявин фикеренчә, *(г)адиз* кабиләсенең җитәкчеләреннән берсе *Кулугбаба* котырта. Каһанлык җимерелгәннән соң, тугыз угызлар Төньяк Монголстаннан төрле тарафларга (көньякка, көнбатышка, Бөек Кытай диварына таба, Шәркый Төркестанга) качарга мәҗбүр була. Шәркый Төркестанда уйгырлар бер-бер артлы берничә дәүләт кора. Арада иң куәтлесе – *Турфан иле*. Уйгырлар, *карлук*

кабиләсе белән берлектә, *Караханидлар дәүләтен* төзүдә дә катнаша. Тугыз угыз ыруглары, үз урыннарында калып, Себер һәм Алтай халыкларын формалаштыруга өлеш кертә.

Дала цивилизациясе тарихын өйрәнергә, аңларга теләүчеләр шактый.

Хактан да, көнчыгыш дәрьялардан башлап көнбатыш тауларга кадәр, шулай ук Төньяк киңлектән башлап Тын океанга һәм Африкага кадәр җәйрәп яткан җирләрнең хуҗалары кем соң? Бу турыда шактый галим әлегәчә баш вата.

Тикшеренүләр угызларның *төрки* кабилә булуын раслый. Орхон-Енисей ташъязмалары борынгы угыз телендә язылган. Моны В.В.Радлов, В.В.Бартольд, О.И.Прицак кебек күренекле галимнәр дә раслый. Мөгаен, аларның хезмәтләрендә кулланган *угыз* – этнографик, *түрк (төрки)* сәяси төшенчәне белдергәндер. Угызлар – борынгы гайрәтле, көчле кабиләләр берлеге булып, соңыннан бик күп төрки халыкларга бүленә: *тугыз угыз, кыргыз, сир, болгар* һ.б. Мәгълүм *Угыз хан* легендаларда мифик җан иясе рәвешендә сурәтләнә: *үгез* (угыз-үгез тәңгәллеген карагыз) аяклы, *бүре* билле, *кеш* иңле, *аю* күкрәкле... Бу сурәт, мөгаен, аның төрле җанварлар кебек көчле булуына ишарәдән тугандыр.

Угызлар VI гасырга кадәр Тянь-Шань тауларының көнчыгышында яши, аннары Ыссык күл буена күченә, VII гасырдан исә акрынлап кына Сыр-Дәрьяга, Каспийга һәм Аралга, Төньяк Кавказга килеп җитә. VIII гасыр урталарына кадәр аларның күп өлеше *Җидесу* җирлегендә гомер кичерә. Көнбатыш Түрк каһанлыгы җимерелеп, Җидесуны *карлук* ыругы яулап алганнан соң, угыз кабиләләре янә үз урыннарын калдыра. IX гасыр ахырында Арал ярында яңа угыз иле оеша. Ләкин ул тиз арада Хәзәр каһанлыгы составына керә.

Ыруг юлбашчыларның берсе булган Сәлҗүк, угызларның мондый хурлыклы хәленә күнмичә, фетнә күтәрә, әмма аны тар-мар итәләр. Нәтиҗәдә, аңа Сыр-Дәрьяның түбәнге өлешенә качарга туры килә. Анда ул Ислам диненә күчә һәм караханидларга буйсына. Вакыт аның искиткеч сәясәтче булуын дәлилли: XI гасыр башына Җир йөзендә бөек *Сәлҗүкләр империясе* хасил була. Бу дәүләт Урта һәм Көнбатыш Азия халыклары тарихында тирән эз калдыра.

Угызлар ике зур төркемнән тора: *бузуклар* (тәхеткә дәгъва белдерергә хокуклы төркем) һәм *өчуклар* (чиктәге кабиләләр).

Бәҗәнәкләр, үзләр (гузлар һ.б.) Көнчыгыш Европада IX-X гасырларда күренә башлый һәм угызларның *төньяк* һәм *көнбатыш канатын* хасил итә. Алар, *болгарлар* белән берләшеп, *угыз-болгар* берлеген булдыра. Соңрак аларга *кыпчаклар* да кушыла. Бәҗәнәкләр исә ары китә. *Сәлҗук-угызларның* көньяк-көнчыгыш өлеше көнбатышка көньяк аша юл тота, Иранны, Кече Азияне кичә. Бу якларда алар әүвәл Сәлҗүкләр берлеге төзи, аннары *Госманлы империясенә* һәм *Азәрбайҗанга* нигез сала. Сыр-Дәрья һәм Каспий угызлары да бүгенгәчә исән-имин. Без аларны *төрекмәннәр*, *үзбәкләр* дип атыйбыз.

Авторның «Татары – загадочный народ»
(Казань: Издательство «Ихлас», 2018. – 112 с.) китабына нигезләнеп,
***Миләүшә Талипова** әзерләде.* ■

Безнең мирас №10 октябрь 2019

«Курчак уйнар идем менә»[1]

Мирхәйдәр Фәйзи

1906 нчы ел

Бу ел, әллә нәрсәләргә генә алданып, Корбан бәйрәменә кайтмадым. Бу кайтмау мине зур казага сукты. Элек бер, тартмасына «Сигара» дип язылган, бармак кебек итеп ясалган шикалад алып ашап, бик яраткан идем. Бу елда, бәйрәмнән төшкән акчамның утыз тиенен фида итеп, шул канфитны алырга уйладым. Магазинга барып сигар дип сорап алып кайтып тартманы ачсам, бу юлы алдадылар. Әллә нинди кара кәгазьгә төргән чүпләр чыкты. Җылардай булып кибеткә бардым. Урысча белмим, аңлата алмыйм. Акчамны кире даулыйм. Бу «Сигар» түгел, дим. Алар мине сигар дип ышандырмакчы булалар. Акчамны бирмиләр. «Сигар»ның тәмле шикалад булуын белми, дип уйлыйлар, күрәсең. Шулай иттереп, сигар ашыйм, дип, 30 тиеннән колак кактым. Теге чүпләрне, берәүгә дә белдерми генә, пичкә ташладым. Сигар вакыйгасы шуның белән бетте.

Бу ел мин «Кафия»не чыгып, «Мулла җами» хан булган хәлдә[2] язны җиткереп утарга кайттым. Бер ай гына Самаев учительгә йөреп, урысчаны да маташтырдым.

Июнь башларында булырга кирәк, әти, әни, Өммегөлсем апай, Шакирә апай, Кәримәләр белән бер тройка, бер пар белән Казан ягына сәяхәткә чыктык. Кучерларның берсе тегермән Гатиятулла иде. Юлда ике атыбыз үлеп, мәшәкать чигеп беттек. Никушлыда Таһирә абыстайларда кунак булып, аннан Оренбурга киттек.

Мәхмүтгәрәй абзыйларда азрак кунак булып ял иттек. Аннан Казан аша Малмыжга бардык, Шодага бардык, Түнтәргә бардык. Әти белән мин генә Чистайга – Шахмайга барып кайттык. Күп-күп кадерле хатирәләр калдырып, кайтышлый тагы Чистайга кереп, Гобәйдә абыстайларны күреп чыгып, Оренбурга кайттык.

Малмыжның Сәмигулла Салихов белән аның Казан кызы булган хатыны Зөһрә ханым да Казанга барышлый безнең белән бер пароходта килделәр. Кич җиткәч, пароходның палубасында йөргәндә, Зөһрә ханым каюталарының тәрәзәсеннән карап утыра икән. Шул җирдә мине туктатып, Оренбурда мәдрәсәи «Хөсәения»дә калуга димләп, күп сүзләр сөйләде. Аның матур итеп ямьле пароход өстендә сөйләгән сүзләре күңелемдә башка төрле тойгылар тудырды. Вә, этиләрдән калып, «Хөсәения»гә укырга керүемә сәбәп булды. Яшә, Зөһрә ханым!

Әниләрдән аерылып җырак җирдә торып калу бик авыр иде. Ике көн буе җыладым. Мәхмүтгәрәй абзыйларның йортлары зур, шәп; тормыш байларча. Бар да мөкәммәл. Фәрихә җиңги ачык күңелле хатын. Безнең белән ул шаярып балаларча уйный, көлә. Шунлыктан, тиз ияләнеп киттем. «Хөсәения»нең рөшди *(урта. – Ред.)* беренче сыйныфына кабул ителеп укый башладым. Азрак укыгач та, яңа салынган өч ятажлы бинага күчтек. Яңа йортта башлап уку шәрәфе безгә тиде. Матур, рухлы; хәлфәләр дә зобани *(газап фәрештәсе. – Ред.)* төсле түгел; шәкертләр дә күңелле. Бу яңа төрле хәят мине бик тиз җәлеп итте. Иске ысулның зур дошманы булып киттем. Башта яңа

[1] Текст М.Фәйзинең КФУда саклана торган көндәлекләреннән кыскартып бирелә. Алдагы өлеше («Күпме яшь күкрәкне изге дип издермәдем») журналның 2019 елгы сентябрь (№9) санында басылды.
[2] Кадими мәдрәсәләрдә укыла торган китаплар. – *Ред.*



уйлар, яңа хыяллар хөкем сөрә башлады. Хәлфәләрне тәнкыйтьләүче груһлар рәтенә керәм. «Чүкеч» журналына язгалап куям. Газеталар чыгарып хыялланам.

Табиган җуашмын, тынмын. Дәресләремне дә урта дәрәҗәдә генә алып барам. Күңелем, хыялларым күпләргә үрелә: мөхәррир булу, шагыйрь булу, артист булу, музыкант булу кебек уйлар белән җенләнәм. Шул юлда тәҗрибәләр ясыйм.

1907 нче ел

Өммегөлсем апайны Оренбурдагы Фәрихә җиңгинең энесе Габдулла кода Габидовка ярәшү мөнәсәбәте белән Орскига баручы кодалар белән өйгә кайттым. Малмыждан җизниләр, Сәетгәрәй абзыйлар да килде. Май 20сендә туй үткәрелде. Үткән кыш әтиләр Орскига күчеп килгәннәр иде. Туй яңа салынып бетеп килгән өебездә булды. Бу, туйның зур хатирәләреннән булып, кодалар алып килгән бадам

чикләвегенең *(миндаль. – Ред.)* төшеннән ясалган чәк-чәк белән үзебезнекеләр тарафыннан пестә чикләвеге *(фисташка. – Ред.)* төшеннән ясалган чәк-чәкләр күңелемдә урын алып калганнар.

Җәй Орскида үтте. Тегермәнебезгә барып яттым. Гөберле суы буенда бик матур җирдә утырган 3 ташлы тегермән дә минем, минем генә түгел, һәммәбезнең дә бик газиз кыйблабыз. 15 елдан бирле безнең кулда торып, әти тарафыннан утыртылган тирәкләр үзенең дә бай күренеше белән җаннарга ямь бирә. Балык күп. Күңелле, рәхәт. Мөхәммәтгәрәй абзыйлар анда торалар. Маһикамал җиңги дә күңелле хатын. Кечкенәдән үк бу тегермәндә минем күп сөекле көннәрем узды.

Утарга бардым. Әхмәтгәрәй абзый һаман байдан чыкканы юк. Кибеттә тора. Тормышлары – үзебезнең өйдә. Күңелем михрабы булган бу утарда да байтак көн уздырдым. Оренбур шәкерте булып, туганнар арасында бәйрәм итеп йөрдем.

Көз тагы Оренбурга киттем. Үзем үссәм дә җылап китүләрем калмады. Актык күрүләрем булса, әнием үлеп китсә кебек уйлар түземемне югалта да, яшькә гарык булам. Йә, Раббым, әни үлсә? Уйлап караганда, куркыныч. Үлем күрми тигез торып килү, ул хәлне күтәрүе гайре кабил бер эш итеп күрсәтәдер иде. Табган *(холкым. – Ред.)* да йомшак һәм анага мәрбут *(бәйләнгән. – Ред.)* идем. Бу ел мин рөшди өчкә сикердем. Шәплегем аркасында түгел, Хөсәеновларның әллә ни кыландырып буташтыру саясендә шулай булды. Урысчаны бөтенләй зәгыйфь алып барам. Күп уйнамыйм да, тырышам да, күкрәгем дә авырта; шулай да дәресләрем алга акрын тәгәри. Әтинең мулла итү уе белән Магазиның сасы, низамсыз мәдрәсәсендә этләвем аркасында күкрәгем зәгыйфьләнеп калганлыгын бик яхшы сиздем. Ул мине борчый, саргайта. Хәлфәләремнән Ибраһим Бикчәнтәев моны күп тырышудан дип уйлап, мөдирияткә чакырып, һавада күп йөрергә, күбрәк уйнарга киңәш биреп инсаниятлек тә итте.

Җиңгиләрдәге тормыш тигез бара. Зарланырлык эш юк. Көн дә кич диярлек Фәрихә җиңги белән, һәйбәт ат, санкаларга утырып, өлкән урамга йөрергә чыгабыз. Өйдә театр уйнап маташабыз. Күз бәйләш, качышларга кадәр үтәлә. Боларның һәркайсының башында җиңги үзе тора. Ашау-эчү ягы тагы Оренбурча.

Кыш уртасында доктор мине укудан тәмам тыйды. Чахуткамыдыр дип куркып йөридер идем, порок сердца булып чыкты. Гомергә килүе игълан ителгән бу авыру аркасында ит ашау, чәй эчү, мунча керү, су керү, җәяү күп йөрү, тауга менү, атка менү, күп уку, язулардан манигъ ителдем *(тыелдым. – Ред.)*. Зур үкенеч белән укудан аерылдым. Надан көе калдым.

Ике кышта Хәбибрахман Зәбири, Габдулла Фәхри, Госман Җәлил, Фәйзулла Мөхәммәт, Ибраһим Бикчәнтәев, Габдерәхим Дәминов, Габдулла Салихи, Мөхәммәт Холуси, Сабур Габдерәшитовлардан дәрес алып, «Хөсәения»дә укуымны тәмам иттем.

1908 нче ел

Укудан туктасам да кышны Оренбурда дәваланып үткәрдем. Апай да монда. Кодаларга барып, җиңги белән өлкән урамда кататься итеп, төрле уеннар уйнап, күңелемә ямь биргән язуларым белән маташып, җәйне җиткердем. Вә Шакирә апай белән Зыя җизнине китергән үзебезнең атлар белән Орскига кайттым. Зыя хәлфә бу кыш безгә җизни булып әверелеп, илләренә кунакка кайтадыр иде.

Җәйне Орскида, тегермәндә, утарда йөреп үткәрдем. Доктор кушканча гамәл иттем. Ит тә ашамыйм, су гына эчәм, даруланам.

Утарга Маһикамал апай туена барып, бераз ирмәкләндем. Оренбурдан апай да килде. Шакирә апайлар да кайтты. Күңелле булды.

Кышта Орскида булдым. Утардан Зыя җизниләрнең чакыруы сәбәпле, анда барып кунак булдым. Күңелле, яхшы булды бу. Зыя җизнинең укыткан җиренә барып, балалар арасында көн үткәрәм. Җизнигә булышмак иттем. Зуррак балалар белән уйныйм. Коньки шуабыз. Ирнияз улы Йосыф, тегермән Хәкимулла, скрипкачы Нәби, Сәмигулла, Шәрифулла, Җүнәй Салихлар белән күңелле хатирәләр калдырдым.

1909 нчы ел

Утарда ай ярымдай тордым. Зыя җизнидән төрек теле өйрәндем. Бергәләп төрекчә романнар укыйбыз. Ашларының һәйбәт булуы белән, мөмтаз *(уңган. – Ред.)* Сабирә җиңгинең тәрбиясе белән хатирәләр тагы төгәлләнде. Мин аларда торганда Шакирә апайдан Җәүдәт туды. Аның туена каладан әти белән әни килеп киттеләр. Алардан соң мин дә калага кайттым.

Орскида җүнәтеп кешегә катышмый, тиңнәрем белән дуслашмый, кыш һәм җәйне үткәрдем. Уку һәм язу белән ирмәк табам. Рус спекталендә күргән «Два Иван Петровича» исемле комедиягә тәкълид итеп *(ияреп. – Ред.)* «Ике Хәсән» исемле бер нәрсә оештырдым. Шулар белән көнем уза. Саусызлык сәбәпле, һич эшкә катышмыйм. Табигатем буенча да хозяйственный эшкә мәелем *(теләгем. – Ред.)* юк. Бер дә аның белән җуана алмыйм. Атлар, юргалар белән дә ирмәкләнмим. Аучылык та кызыктырмый. Әгәр тирәдәгеләрем көлмәсә, курчак уйнар идем менә.

1910 нчы ел

Тарихка алырлык бер кыйммәтен тапмыйм. Гомумән, күңелсез үткән бер елым.

1911 нче ел

Кала тормышы рухыма муафыйк түгел. Авыл тормышына ашкынып, боегып яшим. Орскига мәхәббәтем юк. Бу көнгә кадәр җүнәтеп кешегә аралашмый тордым. Бу ел гына бәгъзе бер егетләр белән мөнәсәбәт башладым.

Шигырьләр язган булам. «Идел» газетасында, «Акмулла», «Ялт-Йолт»та вә башка газеталарда шигырьләрем басылгалады. «Чәчәкләр арасында» исемле бер балалар пьесасы тәрҗемә сымак итеп, «Сабах» көтепханәсе аша бастырдым.

Июнь 1ендә Габдуллаҗан Мангутов, Хәмитҗан Әдһәмов, Әхмәтгали Богдалов, Баттал Шаһидуллин, Габдулла Хәсәнов, Мәгъсум Шәмсетдинов, Мөхәммәтҗан Сәлимҗанов, Хәбибулла Садыйков, Ибраһим Ваһапов, Хуҗа Гобәйдуллиннар белән Яркаенга кырга чыктык. Бер көн кунып, уеннар, эчемлекләр белән дуйт иттердек. Яшьлекне гәүдәләндергән бу чыгыш күңелләрдә матур хисләр тудырды. Былтыр да беркадәр яшьләр белән Хөснулла тегерменәнә кырга чыгып, матур хатирәләр калдырылган иде. Бу елгы бәйрәмнәр дә, иптәшләр белән мәҗлесләргә чакырышып, күңелле генә үтте. Орски яшьләренә нык кына катышып киттем. Габдуллаҗан Мангутов белән дә дусландым.

Кыштан ук Орскида татарча театр ясау уе белән репетициягә тотындык. Бер көн беребезнең, бер көн беребезнең өенә барып репетиция ясыйбыз. Соңынтын өй иясе сыйлый. Бу йөреш үзе бер ямь бирә.

Театр уйнау уе белән ялгыз җенләнеп йөргән мин, Хуҗа Гобәйдуллин, Габдулла Хәсәнов, Исмәгыйль Мозаффаров исемле егетләрнең дә шул хыялда йөрүен ишеткәч тә, бик тиз барып табыштым, таныштым, дусландым. Башка иптәшләр дә табып, түгәрәкне зурайттык. Һәм, бер программа төзеп, күңелле генә иттереп яши

дә башладык. Төрле манигъләр *(тыюлар. – Ред.)*, аталар тарафыннан корылган киртәләр сәбәпле, кыш театрны ясарга муаффәкъ булмасак *(ирешә алмасак. – Ред.)* та, түгәрәкне яшәттек.

Җәй көне Шодадан Сәетгәрәй абзый җиңги белән килеп кунак булып китте.

Былтыр Мортаза абый берәү белән компания булып мануфактура кибете ачкан иде. Ачылган көннән алып, кибет хезмәтенә керештем. Кассада утырам. Көнем кибеттә уза.

Мортаза абый 90 сумга бер тоташ никель велосипед алып бирде. Бу миңа бик кадерле бүләк булды. Кайда барсам да, велосипед белән генә йөри торган булдым. Габдуллаҗан белән якшәмбе көннәр Орски тирәсенә сәяхәтләр ясыйбыз. Көннәр ямьле уза. Бу вакыт миңа 19 яшь иде.

«Сәйяр» труппасы килеп, өч спектакль куеп китте. Оренбур губернаторыннан җәмгыяте хәйрия файдасына куярга рөхсәт алдык. Кызлар катышуны хыялга да китергән юк. Үзебез хатыннар күлмәге киябез. Мин дә кызлар булып уйныйм. Әнидән һичбер сүз юк. Әмма әти белсә, эш начар. Эшне курка-курка алып барабыз.

Август 9ында спектальне үткәреп җибәрдек. Тигез генә чыкты. Орски тарихында татарча театрны башлап уйнаучы «Сәйяр» труппасы булса да, сәхнәдән иң беренче сүзне әйтү миңа насыйп булды. «Оят күз яше» драмасында, Маһи булып, иң тәү сәхнәгә кердем: «Әйдә, әйдә, Нәүбәһар абыстай!» – дип, спектакльнең «бисмилла»сын әйттем.

Үзебезнең спектакльдә «Югалган хатын» белән «Түләшү» куелды. Бу беренче спектакльгә катнашучы егетләр: Хәйдәр, Фаиз, Хуҗа Гобәйдуллин, Габдулла Хәсәнов, Исмәгыйль Мозаффаров, Гариф Галиәкбәров, Габдулла Әмиров, Хәбибулла Садыйков, Гыйззәтулла Надиров, Мөхәммәтҗан Сәлимҗанов, Габдулла Юлдашев, Габдулла Җаппаров, Баттал Шаһидуллин, Гайнетдин Сәгыйтьдинов – барысы унөч кеше. Хасил иткән акчабызны җәмгыяте хәйрия, театр акчасы хәрам, дип, алмады. Бәхетсез акча ике арада йөри-йөри әллә кая китте.

Сентябрь 12сендә «Бүләк өчен», «Кияү эзләү», «Кызлар шулай кызык итәләр»не; декабрь 10сында «Яшь хатын»ны уйнадык. Эш юлга куелды. Матур гына хәрәкәт итәбез. Рухландык. Матур мәҗлесләр ясыйбыз, ду киләбез.

Кибеттә, касса артында утырган хәлдә, «Яшьләр алдатмыйлар» исемле пьесаны яздым. Габдулла Әмиров белән бергә «Бизәнү»не яздык.

1912 нче ел

Туганнарның тигезлеге, иркен тормышы, иптәшләр, дусларның күплеге белән, тормышлар күңелле уза. Орскига өйрәнеп, авылга ашкынган күңелне беркадәр бастым.

Бу ел буенча дүрт мәртәбә спектакль уйнадык. Кызлар катыштыру хакындагы һәрбер тәшәббесебез нәтиҗәсез калды.

Ямьле язның йөрәкләрне җилкендерүенә бирелеп, дуслар белән урамнарда шатланып йөрибез. Чәйләргә барабыз. Фруктовый магазин тирәләрендә алмалар ашый-ашый сәйран итәбез. Төрле кыланышлар белән яшьлек күгенә бизәкләр тезәбез. Җәдәч аерышу модага кереп китте. Әхмәтгали Богдановны ике рәт отып, бер алтын йөзек, бер флакон ислемай алдым. Габдуллаҗан Мангутовтан отылып, бер алтын брелок бирдем. Хәмитҗан Әдһәмовтан отылып, алтын йөзек бирдем. Бу яз күңелдә ямьле урын алып калды.

Май. Габдуллаҗаннарның чакыруы буенча мин, Хәмитҗан Әдһәмов, Әхмәтгали

Богданов, Габдуллаҗан, Хәлим кичтән Тирән Үзәк ягына кырга чыгып кундык. Иртәгесен кич кенә кайттык. Күренеш матур, сыйлар мул, фруктлар өелеп ята, ашлар тәмле, иптәшләр сөекле. Яшьлек көннәрен аллар-гөлләр белән күмдек.

Кайтуыбызга Гыйбад Алиевнең кияү егетенә чакырулы идек. Анда барылды.

Май 17сендә фәкать сәяхәт өчен Казанга карап юлга чыктым. Актүбәдә поездга утырып, Оренбурга керми туры Самарага бардым.

20сендә «Гоголь» исемле пароходның беренче классына билет алып, Казанга киттем. Идел өсте матур. Пароход күңелле. Первый классның салонында котлетлар ашап, ямьләргә йөзеп бардым. Ах, пароходта йөрү күңелле дә соң, валлаһи. Матур каютның тәрәзәсеннән тирәне тамаша итеп бару, палубада чәй эчеп рәхәтләнү – үзе бер гомер.

21ендә Казанга җитеп, «Болгар» номерына төштем. Тугыз көн Казанда тордым. Электән танышлардан Х.Зәбири, Шәрәфетдин Шәһидуллин, Гыйльман Гобәйдуллиннарны күрдем. Шәрәфетдин абзый ашка чакырды. Шиһап Әхмәров, Ягъкуб Хәлили, Насыйр Исхаковлар белән таныштым. Насыйр номерыма берничә рәт килде.

«Сабах»тан «Чәчәкләр арасында»м өчен 15 сум авторский алдым.

«Минем шигырьләрем» исемле мәҗмугамны борәдарән Кәримовлар, гомерлеккә, дип, дүрт сумга алдылар. Шәрифҗан исемле бер карт бүресе алдады. Гомерлеккә икәнен кул куйгач белеп, тыпырчынып карасам да, кул куйдың, эшең бетте, дип китеп тә калды.

Бер кич номерыма Харис абзый Фәйзи кереп утырды.

Казанның зур урамнарын трамвай белән әйләнеп чыктым. Ике көн буе шәһәр музеен карадым. Бер мәртәбә Панаев бакчасына бардым. Театрга кердем. Бакчаларда йөрдем. Фатыйх Әмирханның башын, Тукайның басып йөргән эзләрен күрдем.

Кайтышлый Оренбурда туктадым. Фәрихә җиңгиләр Орскига киткән иде. Дөнья чаклы зур өйдә берүзем йөрдем. Оренбурда дүрт көн торып, Актүбә аша Орскига кайттым.

Июнь азакларында юрист Шакир Мөхәммәдьяров белән икебез дә велосипедта Җүнәйгә бардык. Тегермәннән Җүнәй буена җиләккә безнекеләр (җиңгиләр, апайлар) очрап, туктатып, җиләкләрен ашадык. Алар тегермәнгә китте, без, Җүнәйгә барып, Шакир әфәнделәрнең фатирына төштек. Ул вакытта Шакир әфәнде, «Хөсәения» мөгаллимнәреннән Сөнгатулла Бикбулатов, Салих әфәнделәр Җүнәйдә кымыз эчеп яталар иде. Безнең җылкылар савылып, кымызны бездән алалар иде.

Мин Җүнәйдә кундым. Төн буе карта уйнадык. Кунак булдым. Шул көннүк тегермәнгә китәм, дисәм дә, җибәрмәделәр. С.Бикбулатовның йомшак кына мөгамәләсен сөеп, яннарында кунасы иттем.

Иртәгесен тегермәнгә бардым. Фәрихә җиңгиләр, Өммегөлсем апайлар да анда. Күңелле җирдә туганнар белән гөрләшеп йөрдек. Фәрихә җиңги һәрвакыттагы кебек шаяра, уйный, гармун уйный, матур җырлый. Кызык.

Ике көннән соң алар – атта, мин велосипедта Орскига кайттык. Аларны ташлап калдырып, әллә ни гомер алда кайтып җиттем.

*Текстны басмага **Рәйсә Шәрәфиева** әзерләде.* ■

МАРСЕЛЬ ӘХМӘТҖАНОВКА 80 ЯШЬ

Шәҗәрә капкасын ачучы...

Фәүзия Бәйрәмова

Тарихи хезмәтләр язганда, өстәлемдә даими рәвештә ике авторның китаплары тора: алар – Ризаэддин Фәхреддин һәм Марсель Әхмәтҗанов, берсе – дин, икенчесе – фән галиме. Ризаэддин хәзрәтнең «Асар»ын һәм Марсель абыйның шәҗәрәләр китабын ачып карамыйча, язасы хезмәтемә тотынмыйм, чөнки бу олуг галимнәрнең ни әйткәннәре минем өчен бик мөһим. Бигрәк тә төбәк тарихын һәм шәхесләр язмышын ачыклаганда, аларның хезмәтләре алыштыргысыз. Бу ике галимнең дә башкарган хезмәтләре, рухи мирасы гаять зур, гыйлемнәре һәм тырышлыклары таң калырлык, тоткан юллары тайпылышсыз. Ризаэддин Фәхреддин дә, Марсель Әхмәтҗанов та, тарихыбызга һәм шәхесләргә бәя биргәндә, милләт мәнфәгатен беренче урынга чыгаралар.

Филология фәннәре докторы Марсель Ибраһим улы Әхмәтҗановны мин: «Милләткә шәҗәрәләр капкасын ачучы», – дип атар идем. Дөрес, аңа кадәр дә татар шәҗәрәләрен өйрәнүчеләр булды, фәннең бу тармагына Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэддин Фәхреддин, Сәет Вахиди, Миркасыйм Госманов һәм башкалар зур өлеш керттеләр. Аларның лаеклы дәвамчысы буларак, Марсель Әхмәтҗанов татар шәҗәрәләрен дәүләти күзлектән чыгып өйрәнде, аның хезмәтләре тирән милли идеология белән сугарылган иде. Шул ук вакытта галимнең хезмәтләре гади халыкка да аңлаешлы һәм якын.

Ул татарлар яшәгән барлык төбәкләрдә – Идел-Уралда, Тубыл һәм Иртыш буйларында, Нократ һәм Чулманда – милләтебезнең тарихи ватанында дәрвиш кебек йөреп, борынгы кулъязмаларны туплады, тезләнеп, җиргә сеңгән кабер ташларын өйрәнде, архивларда, китапханәләрдә, музейларда эшләде. Шулай итеп, Марсель Әхмәтҗанов йөзләрчә затлы татар нәселенең шәҗәрәсен төзеде, алар арасында ханнар һәм солтаннар, хакимнәр һәм тарханнар, мөфтиләр һәм имамнар, милләтебезнең танылган шәхесләре дә бар. Бигрәк тә халкыбызда киң таралыш алган, котыптан кыпчак далаларына кадәр таралган Кара бәк шәҗәрәсе, Бикчура хан һәм Ишмән шәҗәрәләре, Майкы би һәм Гирәет би шәҗәрәләре күпләргә үзләренең кемлеген ачыкларга ярдәм итте. Марсель Әхмәтҗановның төрле елларда кат-кат басылган «Татар шәҗәрәләре» китабын бүген дә күпләр яратып укый һәм файдалана.

Мин үзем дә төньяк төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребез турында язганда, Марсель Әхмәтҗановның хезмәтләрен күп файдаландым. 2002 елда Удмуртиядә булып, бирегә төньяктагы Нухрат-Каринодан күченгән татарлар тарихын өйрәнә башладым һәм, әлбәттә, Кара бәк (бик) шәҗәрәсенә килеп чыктым. Ул чагында данлыклы Кара бәк нәселе турында «Татар халык иҗаты» китабында «Нократ» риваяте һәм Марсель абыйның «Татар шәҗәрәләре» китабында аның нәсел шәҗәрәсе бар иде. Бу теманы озак өйрәнүләрдән соң, мин «Кар Иле татарлары» дип аталган күләмле тарихи очерк яздым. Анда галимнең бу темага хезмәте турында болай дип әйткәнмен: *«Галим Марсель Әхмәтҗанов та үзенең хезмәтләрендә Кара бик шәҗәрәсенә, ягъни Кар Иле татарлары тарихына киң туктала, бу нәселнең 28 буын исемнәрен бирә. Галим Кара бик шәҗәрәсенең ике дистәдән артык варианты барлыгын әйтә, әмма ул да төп игътибарын Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорына бирә, ягъни Кар Иле татарлары тарихын XIV гасырдан тасвирлый башлый. Ә инде шәҗәрәдәге Сократ хакимнәргә ишарәне ул борынгылык белән мавыгу итеп карый»*. (Бәйрәмова Ф.

Пермь краеның Чәрдән каласы музеенда Ибраһим ханның сугыш киемнәре һәм кораллары

Таралып яткан татар иле. – Казан, 2003. – Б.106.)

Төньяк төбәкләрдә яшәүче татарлар тарихын өйрәнүне алга таба да дәвам иттем, бу эшчәнлегем Кара бәк шәҗәрәсе һәм Марсель абый хезмәтләре белән янәшә барды. 2009 елда Пермь краеның Чәрдән-Чердынь каласында булдым һәм соңрак «Чәрдән ханлыгы» дип аталган күләмле тарихи очерк яздым. Тарихта болгар чорларыннан билгеле булган, соңрак Алтын Урда һәм Казан ханлыгы составларына кергән, заманында башкала-үзәк булып та торган, урыслар белән дистәләрчә сугыш-орыш кичергән Чәрдән хәзер таралып-бетеп бара торган бер авылны хәтерләтә. Бүгенге көндә бер генә татар яшәмәсә дә, анда милләтебезнең тарихы бар, музейларында татар ханнарының бисмиллалы сугыш киемнәре һәм кораллары саклана, барлык чиркәүләре дә кыйблага карап тора, чөнки алар борынгы мәчетләр өстенә салынган. Мин бары тик биредә генә Сөембикә манарасына охшатып, кызыл кирпечтән төзелгән җиде баскычлы (яруслы) чиркәүне һәм Мәрҗани мәчете кебек яшел гөмбәзле монастырьларны күрдем...

Ул якларга сәфәр чыгар алдыннан Марсель абый миңа: *«Соликамски яки Чырдын музеенда Ибраһим ханның сугыш киемнәре булырга тиеш, шуларны карап-барлап кайт әле»,* – дигән иде. Таптым бит мин аларны! Чәрдәннең төбәкне өйрәнү музеенда саклана ул сугыш киемнәре – тимер боҗралардан үрелгән көбә, маңгаена Коръән аятьләре язылган тимер очлым (шлем), Коръән аятьләре язылган калкан һәм кылыч, түтәсенә бисмилла язылган айбалта һәм тимер терсәкчә... Карап торырга ук дәһшәтле, карап торырга ук мәгърур, карап торырга ук безнеке икәне күренеп тора! Әмма аның астына бик кыска гына итеп: *«Снаряжение воина. Железо. XV-XVII вв. Поступила из собрания В.Н.Алина в 1918 г.»,* – дип язылган. Музей хезмәткәрләре бу сугыш киемнәрен: «Сөембикә-ханбикә заманыннан калган булырга тиеш», – диделәр! Ягъни Казан ханлыгы чоры, барыбер безнеке! Хәтеремә тагы Марсель абыйның сүзләре төшә: *«Чырдынны Казан ханы Ибраһим кордырган булса кирәк»*, – дигән иде ул.

Мин бу сугыш киемнәрен дә, музейдагы башка экспонатларны да, Чәрдәннең үзен дә атна буе шунда яшәп өйрәндем, бу турыда яздым, Казанга кайтып сөйләдем. «Чәрдән ханлыгы» дип аталган әлеге күләмле хезмәтем татар һәм рус телләрендә китапларымда да дөнья күрде, аны язган вакытта мин Марсель Әхмәтҗанов хезмәтләрен дә җентекләп өйрәндем һәм файдаландым. Ул үзенең «Нугай Урдасы» дип аталган китабының «Пермь өлкәсе татарлары шәҗәрәләре» дигән бүлегендә: *«Җавыш би шәҗәрәсе»нә таянып, «Чырдын – Пермь ягының административ үзәге булганга охшый*, – дип яза. – *Аның аркылы бу як татарлары Мәскәү белән бәйләнешкә кергәннәр. Димәк, Чырдын Кама буенда Казан ханлыгының административ үзәге*

булып торган, соңыннан, күрәсең, анда Мәскәү воеводасы утыртылган». (Әхмәтҗанов М.. Нугай Урдасы. – Казан, 2002. – Б.264.)

Марсель Әхмәтҗанов Чәрдәнгә Болгар һәм Казан кешеләренең турыдан-туры тәэсире турында да яза: *«Җавыш бинең улы Инсан Болгар шәһәреннән Чырдынга килеп урнаша, шунда яши,* – дип, шәҗәрәне бәян итә ул. – *Иван Васильевич Казанны Болгар олысы ханы кулыннан алгач, аңа буйсынып, ясак түли башлый».* (Күрсәтелгән хезмәт. – Б.264.) Галим, шәҗәрәләргә таянып, бу якларга татарларның «XIV гасырдан да соң килмәүләрен» әйтә, ягъни Алтын Урда һәм Казан ханлыклары чорында Чәрдәннең татарлар кулында булганлыгын исбатлый: *«Пермь ягындагы татарларның административ үзәге булып, Чырдын каласы саналган. Ул 1472 елда беренче мәртәбә тарихта искә алына. Аны Казан ханы Ибраһим кордырган булса кирәк»,* – дип яза ул. (Күрсәтелгән хезмәт. – Б.266.)

«Чәрдәннең биш тапкыр урынын алыштырганын искә алсак, аның берсен Ибраһим хан кордырган булырга да бик мөмкин, бу инде 1467-1479 еллар арасы, дигән сүз», – дип яздым мин бу турыда. (Фәүзия Бәйрәмова. Ачылмаган татар тарихы. – Казан, 2011. – Б.252.) Ни гаҗәп, биредә дә Кара бәк эзләре бар, әмма ул инде урыс риваять-преданиеләрендә җирән сакаллы, сары бөдрә чәчлы урыс батырына әйләнгән! Ул Чәрдәннән ерак булмаган Искор дигән җирдә идарә иткән, исеме дә Кор икән. Имеш, ул җирле вогул-юграларга каршы сугыш белән барган, имеш, ул татарларга каршы да көрәшкән! Чулман-Җаекка гына түгел, Обь, Тубыл, Иртышларга хәтле барып җиткән! Арттырып җибәргәннәрен сизеп, биредә аны татарларга каршы көрәшкән фин-угыр кабиләсе вәкиле дә итеп күрсәтергә тырышалар. *«...Местным населением это место называлось княжим местом, что связано с именем легендарного царя Кора, оказавшего сопротивление татарам»,* – дип тә яза алар. (Чердынь. Путеводитель. – Петербург, 2009. – С.90.)

Марсель Әхмәтҗанов китапларына кертелгән Кара бәк шәҗәрәсенең Сәет Вахиди нөсхәсендә, Нух галәйһиссәламнең бишенче-җиденче буыннарында, Кор исемендәге шәхесләр дә бар: *«Хәзрәти Нух галәйһиссәлам, Йәфәс, Булмас түрә, Чин хан, Коры хан, Бай тархан, Корлу хан, Карагыл хан».* (Марсель Әхмәтҗанов. Татар шәҗәрәләре. – Казан, 1995, 20 б.) Ягъни төньяк Уралда урыслар үзләренеке дип йөргән җирән сакаллы «царь Кор» татар җиһангиры Коры-Корлу хан булырга бик мөмкин, чөнки ул заманнарда Уралда урысларның эзе дә булмаган!

Галим Кара бәк нәселенең бик ишле һәм гайрәтле булуын, аларның Кырым-Кавказлардан башланган затлы нәселләре Идел-Урал һәм Нократ буйларында таралып яшәвен әйтә: *«Канбар, Кара бик нәселләре Сакмар суы буйларыннан Нократтагы Карино авылына һәм Чувашстан чигеннән Уфага кадәр булган киң мәйданда яшиләр. Аларның саны йөзләрчә мең кешегә җитә. Шунлыктан, Кара бик нәселенең Идел-Урал буе татарлары этник тарихында урыны зур».* (Күрсәтелгән хезмәт. – Б.26.)

Шушы шәҗәрә буенча мин дә, ниһаять, «Нократтагы Карино авылына» барып чыктым, бу хәл 2014 елның сентябрендә булды. Үзләренең нәсел башларын Сократ хакимнән башлап җибәргән, Искәндәр шаһ белән икесенең бу якларга «мәңгелек суы эстәргә» килгәнен истәлекләрдә язып калдырган бу татар-мишәрләр белән күптән кызыксына идем. Казан белән котып арасына урнашкан, карта-энциклопедияләргә «иң төньяктагы татар авылы» дип кертелгән бу борынгы сала узган гасырларда кала ролен үтәгән, татарларның дини һәм милли үзәге булган. Әлеге авылның ике исеме бар – Нухрат һәм Карино. Кара бәк шәҗәрәсендә бу авылга нигез 1210 елда салынган, дип күрсәтелгән, риваятьләрендә – Нух пәйгамбәр заманыннан булуы әйтелгән...

Рәсми чыганакларда ул 1250 еллардан күренә башлый, 1361-1489 елларда фәндә «Каринское княжество» дип аталган мөстәкыйль ил-дәүләтләре дә булган. Күп кенә фәнни чыганакларда бу татарларны «Арские князья» – «Ар бәкләре» дип тә атыйлар.

Әле узган гасырларда гына да Нухрат-Карино авылында 8 мәчет һәм мәдрәсә булган, бу авылның байлары ярты дөнья белән сәүдә иткән, Касыймовлар, Дәүләтъяровлар, Арслановлар булып, ярты дөньяга таралган... Хәер, мин болар турында «Кар Илендә татарлар...» дип аталган күләмле тарихи очеркымда яздым, ул 2016 елны Казанда басылып чыккан «Милләт тарихы» дип аталган китабымда дөнья күрде. Бу хезмәтне язганда, теманы өйрәнгәндә мин Кара бәк шәҗәрәсенә, галим Марсель Әхмәтҗановның әлеге хакта язганнарына зур игътибар бирдем. Ул да Кара бәк шәҗәрәсенең нократ татары Гыйльман Касыймов тарафыннан төзелгән нөсхәсенә игътибар иткән һәм аны үзенең китабына да керткән.

Марсель Әхмәтҗанов туплаган шәҗәрәләр буенча баруымны башка хезмәтләремдә дә дәвам иттем. Әйтик, күренекле язучы Чыңгыз Айтматовның татар анасы Нәгыймә Айтматова турында материал туплаганда, Ишмән шәҗәрәсен ныклап өйрәндем. Бу шәҗәрә Марсель абый китапларына да кертелгән, Кукмараның төбәк тарихын өйрәнү музеенда да саклана. Аны ревизия материаллары белән чагыштыру өчен, мин Киров шәһәре дәүләт архивыннан Мәчкәрә авылы буенча 1852, 1858 елгы документларны да барып алдым. Марсель Әхмәтҗанов Мәчкәрә авылына нигез салучы бу затлы нәселнең Шәһре Болгардан күчү версиясен дә, аларның Хан Кирмәннән килү мөмкинлеген дә кире какмый: *«Икенче версия буенча, нәсел Шәһре Болгардан килгән булып чыга, дип яза ул. Әлбәттә, бу легенда беренче версиягә каршы килми, аны куәтли генә, чөнки Хан Кирмәннән килүчеләр өчен, бу яклар Болгар вилаяте буларак танылган була. Гомумән, Мәчкәрәгә нигез салучыларның Хан Кирмәннән чыккан татарлар булуын шәҗәрәнең ике варианты да раслый. Алар бирегә XVII гасырның урталарында килгән булырга тиеш. ... Гомумән алганда, Касыйм татарлары, бу шәһәрдә чукындыру сәясәте көчәйгәч, Урта Идел һәм Оренбург якларына күпләп күчеп утырганнар».* (Әхмәтҗанов М. Татар шәҗәрәләре. – Казан, 2012. – Б.182-183.)

Боларның барысын да ныклап өйрәнгәннән соң, мин Чыңгыз Айтматовның татар бабалары чыккан Ишмән нәселенең Кара бәк шәҗәрәсенә барып тоташуын да ачыкладым: *«Шәҗәрә төзүчеләр Ишмән нәселенең Шәһре Болгар якларыннан булуын язып калдырганнар, шул ук вакытта аларның Ханкирмәннән (Касыйм каласы), төньяктан килүләренә дә ишарәләр бар. Ишмән нәселенең данлыклы Кара бәк, Карахан нәселе белән дә бәйлелеге күренә. Кара бик нәселенең берничә варианты бар, ул Татарстанда, бигрәк тә, төньяк районнарда шактый таралган. Белгәнебезчә, Кукмара районы республикабызның төньягына урнашкан, ә Мәчкәрә авылы бу районның да иң төньяк читендә, Киров өлкәсе чигендә. Кара бик шәҗәрәсенең галим Сәет Вахиди тапкан нөсхәсендә Ишмән исеме дә бар, ул инде теге заманнар өчен соңгы буыннарның соңгысы булып тора, шәҗәрә Туктар Ибраев тарафыннан 1851 елда төзелгән».* (Бәйрәмова Ф. Ана. – Казан, 2015. – Б.13-14.)

Дөньякүләм танылган язучы Чыңгыз Айтматовның канында Кара бәк нәселенең гайрәте, рухы, моңы вә таланты булу бер дә гаҗәп түгел, чөнки безнең якларга «мәңгелек суы» эзләп килгән, үзләренең барлыклары белән «тере суга» әйләнгән терекөмештәй татарлар бит алар! Рус философы Иван Ильин татарларны «Блуждающий Атом» дип атаган, ягъни адашкан, дөнья буйлап үз-үзен эзләп йөргән Атом... Һәм ул, һичшиксез, җиһанда үз урынын табачак – моңа тарих шаһит!

Галим Марсель Әхмәтҗанов хезмәтләренә, бигрәк тә аның Кара бәк шәҗәрәсенә күпләр мөрәҗәгать итә. Тарих фәннәре докторы Радик Салиховның «Служилая Ура:

Казан ханы Ибраһим кордырган Чәрдән каласы. Фотода мәкаләнең авторы Фәүзия Бәйрәмова

рождение татарского капитализма» китабында да аңа шактый урын бирелгән. Китап авторы, галимнәр Дамир Исхаков һәм Марсель Әхмәтҗанов хезмәтләренә таянып, безнең якларга килеп чыккан Кара бәк нәселенә зур бәя бирә, аның варисларын ил һәм милләтнең асыл нигезен тәшкил итүчеләр, дип атый: *«Подчеркивая выдающуюся миссию рода Кара бека в золотоордынском государстве, М.И.Ахметзянов ассоциирует личность этого яркого деятеля с Габдуллой ханом, чингизидом, правившем в Азаке (Азове) в 1360 г. При поддержке знаменитого мирзы Мамая, Габдулла хан дважды восходил на трон в Сарай аль-Джадиде. ... М.И.Ахметзянов считает, что сын Кара бека – Гали бек правил Казанью в первой половине XIV в. и был убит в 1445 г. Махмутеком. Представители рода Кара бека и после этого события оставались влиятельной силой Казанского ханства, сформировав группу так нызываемых «Арских князей», обладавших определенной независимостью и серьезными военными ресурсами. Именно их потомки населяли большинство исторических деревень Заказанья, а в дальнейшем расселились на обширной территории от Волги до Урала»*. (Салихов Р. Служилая Ура: рождение татарского капитализма. – Казань, 2015. – С.7-8.)

Марсель Әхмәтҗанов хезмәтләренә таянып, автор Түбән Оры авылына үз нәселенең башы булган Хуҗасәетовларның Нухраттан 1616 елларда ук килеп урнашуларын, аңа кадәр биредә Манаш тарханнар нәселе яшәгәнлеген яза. Марсель Әхмәтҗановның нократ татарлары буенча да шәҗәрәләре барлыгын әйтеп үтәргә кирәк һәм Радик Салихов та аларга мөрәҗәгать иткән. Әйе, әйткәнемчә, кайсы төбәк, кайсы нәсел турында язсаң да, Марсель абыйның китапларын ачып карыйсың һәм гыйлем дәрьясына чумасың... Нинди зур шәхесләр, нинди тетрәндергеч язмышлар, җиһанны иңләгән татар тарихы! Һәм кыйтгаларны, чорларны тоташтыручы нәсел шәҗәрәләре, шуларны милләткә кайтаручы акыл иясе – татар галиме... Марсель Ибраһим улы Әхмәтҗанов милләте өчен инде «тере су»ны тапкан, ул – аның хезмәтләре, мәңгелек гыйлем. Милләт яшәгәндә, бу гыйлем яшәячәк, иншәАллаһ! ■

Безнең мирас №10 октябрь 2019

Туган ил каян башлана?

Эльмира Шәрифуллина

Фирая һәм Зөлфәт Маликовлар белән озак еллар Татарстан урамындагы 7 нче йортта ут күршеләр булып яшәдек. Аралашып, бер-беребезнең терәге булып. Ике гаиләнең дә түгәрәк, барыбызның да исән-сау, тормышларыбызның гөр килеп торган чагы. Килгән кунакларны, өлкән яшьтәге әти-әниләребезне әле аларда, әле бездә табынга чакырабыз, каядыр китсәк, хатлар язышабыз. Фаилнең дә, Зөлфәтнең дә, кайчагында минем дә яңа әсәрләребезне бергәләп укыйбыз, шатланабыз, көләбез, киңәшләребезне әйтәбез, бер-беребезнең уңышлары өчен куанабыз. Аралашуыбыз, ярдәмләшеп яшәвебез алга таба да дәвам итте. Мәсәлән, менә бу кечкенә генә кәгазь кисәгендәге язма да шуның бер дәлиле булып тора.

«Эльмира дускай!

Шигъри пьедесталга менүең белән чын күңелдән котлыйм үзеңне!

Митингта гаҗәеп матур итеп, зур темперамент белән, нәкъ артистлар кебек (хәтта артистлардан да остарак) укыган шигыреңне бик рәхәтләнеп һәм шундый да куанып радиодан тыңладым. Молодец!

Так держать!

Сәлам белән: **Фирая (**26 нчы апрель, 1990. – *Э.Ш.*)».

Сүз – Тукай бәйрәмендә укыган шигырь турында. Ул шигырь, «Татарстан яшьләре» газетасының 29 ноябрь санында, иллюстрацияләр белән бизәлеп, газетаның ярты битен тутырып басылып та чыкты:

ЧИРАТТА ТОРГАНДА УЙЛАНУЛАР

Кешелегең күпме саклау мөмкин,
Фәкыйрьлегең җиткәч соң чиккә.
Паспорт тотып чиратларга бастым,
Талонымны суздым май, иткә.
Монысына менә – шикәр комы,
Карабодай – сирәк булса да.
Шатлык түгел бүген бала табу –
Үз «талоны» белән туса да.
Мин – чиратта,
Әлгаязебиллаһ,
Кер сабыны өчен, бер кисәк.
Туксан көнгә бары бер кисәк бит,
Күбек булып оча, «өф», дисәк.
Чиратларда көн үтерер өчен
Тудыкмыни якты дөньяга?
Тамак ягын уйлап,
Алдап-йолдап,
Горурлыкны таптап ел ага.
Чәчәк аткан Совет иле, дидек,
Караклыкка батып туктадык.
Эндәшмәде, түзде безнең халык,
Түзгән саен ныграк тукмалдык.
Куылды да, атылды да,
Асылдылар күпме асыллар.
Нәселе белән шәһит китте җаннар,
Канга батты хәтта гасырлар...
Эшчән халкым,
Мәгърифәтле халкым,
Эшләдең дә бары эшләдең;
Кыерчыгыңны да кырыеннан
Кыенсынып кына тешләдең.
Бирә-бирә бөлгенлеккә төштең,
Туктарлар, дип, туеп сикергәч.
...Кадереңне күпме саклау мөмкин,
Асылыңнан бәяң ким йөргәч?!
Бар да яхшы, бар да кызыл иде –
Галстугым, паспорт тышым да.
Кызыл сүз сөйләдек,
Килде вакыт –
Эчемдәге бүген тышымда.
...Чү!
Йөрәгем кыса –
Даруым юк
Сихәтләргә хәтта ярамны...
Талон тотып тагын чират бастым,
Туйдырырга кирәк баламны.

Сезгә тәкъдим ителгән бу мәкалә парлы, бәхетле елларыбызда язылган иде. Йөри-йөри башта беренче бите югалды. Аннан кайгылар эзәрлекли башлады. Шул сәбәпле, язма матбугатта вакытында басылмый калды. Ниһаять, һәрбер әдәби мирасны күз карасы кебек саклауга юнәлеш алган «Безнең мирас» журналы «туды». Бу мәкаләгә дә яшел юл өмет итеп, язмамны аларга юллыйм.

Бер тауда биш чишмә

Челтерәп аккан чишмә тавышына уянып китте Фирая. Улактан-улакка күчеп, җырлый-җырлый чишмә ага, имеш. Тавышы шундый моңлы, нәфис. Үзендә җем-җем итеп кояш нурлары уйный. Кара, нинди матур. Моңа кадәр ничек күрмәде икән ул аны? Җырларда җырланган Фазыл чишмәсе ләбаса!..

Чү, ерак та түгел, тагын берсе челтери. Аның янәшәсендә тагын берәү, тагын... Ничәү соң бу челтерәп агучы моңлы чишмәкәйләр? Ә менә монда, ташлардан-ташларга күчеп, тагы да зуррагы, тагы да гайрәтлерәге, тагы да мулрак сулысы ага түгелме? Әллә «яратам, һаман яратам», дип челтери? Соң, алайса, монысы Зөлфәт чишмәсе була инде...

Кызык, бер тауда биш чишмә, имеш. Юк, таудан түгел, ничектер Фираяның күкрәгеннән ургылып чыга сыман алар. Чыгалар да, бөтен тирә-юньгә моң таратып, җырлый-җырлый агалар: Зөлфәт чишмәсе, Азамат чишмәсе, Илһам чишмәсе, Фазыл чишмәсе һәм иң нәние – Кадрия чишмәсе!

Туган ил каян башлана?

Иртәнге кояш нурларында иркәләнеп ятучы улларына һәм кызына күз салды Фирая. «Челтерәп агучы чишмәләрем минем», – дип уйлады ул эченнән. Шифалы сулары белән тәнгә сихәт биреп, моңлы тавышлары белән халык күңелен иркәләгән чишмәдәй, сез дә кешеләргә бәхет һәм шатлык китерсәгез иде. Киң күңелле, ярдәмчел, кешелекле булып үссәгез иде!

Кешелекле булу. Олы, кыйммәтле сыйфат бу. Әмма ул тойгыны балалар күңеленә яшьли салырга, файдалы орлыкларны мөмкин кадәр иртәрәк чәчәргә кирәк. Сабыйга һәрдаим уңай тәэсир ясау өчен, беренче чиратта, үз холкыңның, гореф-гадәтеңнең камил булуы шарт, билгеле. Чөнки балада – ишетеп мигә сеңдерүгә караганда, күреп хәтердә калдыру сәләте көчлерәк. Мәктәп программасыннан гына гыйбрәт алыйк. Тәҗрибәле педагог авыр теманы һәрвакыт күргәзмә материал белән аңлатырга тырыша. Ун тапкыр ишеткәнче, бер тапкыр күреп калсын. Димәк, гаиләдә нинди гадәтләрне күбрәк күрсәтсәң, шул сыйфатларның чагылышын күбрәк табачакбыз. Бу җәһәттән чыгып караганда, Фираяның холык-фигыле – кешелеклелек сыйфатларының тулы бер комплексын тәшкил итүче табигать. Бу аның һәр эшендә, кеше белән мөгамәләсендә чагыла, көндәлек тормышын бизи. Нәтиҗәдә, әлеге мәрхәмәтлелек, сизелмичә генә, балалары күңеленә күчә, сеңә бара.

– Бервакыт, – дип искә төшерә Фирая, – өшүдән куллары, колаклары боз кебек булган, елаудан күзләре кызарган Фазылым кайтып керде. Керде дә, бүрегенә салып куенына тыккан песи баласын чыгарды.

– Ике сәгатьтән артык әтисе белән әнисен эзләдек, беркайдан да таба алмадык, – ди ул, сулкылдап. – Ә Илһам абыем һаман эзли калды.

– Песиләрнең әтиләре булмый, улым, – диде Фирая, гадәтенчә, сүзләренә җорлык кушып. – Такташ бабагызның шигырен оныттыгызмыни?..

Шулчак моңа бик тә тәңгәл икенче бер вакыйга яңара. Пушок исемле мәчеләре алтынчы каттан җиргә егылып төшкәч, Фираяның ашыгыч ярдәм күрсәтү өчен өйгә ветврач чакыртуы, аннан шул мәчене сабый баладай төреп, атналар буе табибка, укол ясатырга йөртүе искә төшә. Дүрт бала анасының барысына да вакыты, игътибары ничек җитә?! Тирә-юньдәге ялгыз, гарип кешеләргә ярдәм итәргә дә, балаларын чиста киендереп мәктәпкә озатырга да, җәмәгать эшләре белән каядыр барырга да өлгерә ул. Күңелдә гап-гади бер сорау туа. Туган ил каян башлана? Бәлки, нәкъ менә шушындый бәләкәй генә мисаллардан – табигатьне, кешеләрне, хайваннарны яратудандыр? Ә, бәлки, әнә шундый киң күңелле, ачык йөзле, матур холыклы кешеләр яшәгән төбәктәндер...

Күңел күзе

Бишенче класста укыган чагы була Фираяның. Беркөнне кечкенә буйлы, ябык гәүдәле кыз бала ияртеп кайта бу. Өстен салырга булыша, кулларын юдырып, өстәл янына утырта. Һәм әнисе Мәфрүзә апаны күрше бүлмәгә дәшеп, әлеге кызның ятим булуын әйтә. «Хәер, әнисе исән бугай да, әмма...», – ди ул, күз яшьләрен тыя алмыйча...

– Соңыннан, шул ана тиешле кешенең фотокарточкасын тотып, шәһәр буйлап эзләп йөргән белдем мин Фираяның, – дип сөйли Мәфрүзә апа.

Күз алдына китерегез: Казан тикле Казаннан һәркемнең ишеген ачтырып, баласын ташлап киткән ананы эзлә, имеш?!.

Юк, таба алмаган ул мәрхәмәтсез ананы. Әмма күңелендә сулкылдап бер яра калган. Әгәр тудырган әнисе үз баласын үзе бакса, Фираяның яшьтәше өстәл янында әнә шулай

кыенсынып, әнә шулай тартынып утырыр идемени? Фирая күзенә шулай кызганыч булып күренер идемени ул?

Аларның бөтенләй башка. Тапкан әнисе тәрбияләмәсә дә баккан әнисенең яхшылыгын, кешелеклелеге, йомшаклыгын сөйләп бетерә алмый Фирая. Әтисенең әнисе белән Мәфрүзә әнисе арасында да бик күп уртаклыклар күрә ул. «Килен каенана туфрагыннан яралган», – ди бит халык. Бәлки, шулайдыр. Арча районының бөтен Сикертән авылы халкы сагынып сөйли Фираяның Оркыя әбисен. Олы җанлы, киң күңелле булып исләрендә калган ул авылдашларының. Сигез бала үстерүе, бер кабымлык ризыгы булса, аны да күршеләре белән уртаклашуы, узган-барганга җылы түреннән урын бирүе турында мәрхүмә булгач та сокланып искә алалар.

– Хәзер әнә нәкъ шул сыйфатларны дүртенче буында – Фирая балаларында күрәм, – ди Мәфрүзә апа, каенанасын олы ихтирам хисе белән телгә алып.

– Җәй көннәрендә җыелышып бакчага барабыз. Балалар, берсеннән-берсе күреп, чүп утый, агач төпләрен йомшарта. Кечкенә Кадриясенә кадәр эшне җиренә җиткереп башкарырга тырыша. Нәни чиләкләре белән ташып, чәчәкләргә су сибә.

Чәчәкләр, дигәннән, бакчадагы гөлләрне бервакытта да кисеп яки өзеп алмый алар. Өстәлгә утырту өчен, инде кемдер тарафыннан җыелган чәчәкләрне генә сатып алалар.

Гөл һәм бала. Бала һәм гөл. Табигатьне, тирә-юнебезне бизәп торган гөл-чәчәкләрне өзәргә кулы бармаган балага: матурлыкны ярат, аңа карап соклана бел, дигән нотык укуның, әхлак нормаларын коры сүз белән аңына сеңдерергә тырышуның кирәге бармы? Юк, билгеле. Бу гадәтләрне күреп үскән, әлеге матурлыкны күңел күзе аша күптән канына сеңдергән ләбаса ул!

Әлли-бәлли бәбкәсе

Тарих теллләрдән-телләргә күчеп сөйләнүче бик күп гүзәл хатын-кыз образларын белә. Шулар арасында декабрист хатыннары да бар. Бу сүзне әйтүгә, көчле рухлы, саф мәхәббәтле, ирләренә тугрылыклы ханымнар күз алдына килә. Ирләре белән горурлана белүче, алар тормышы белән яшәүчеләр.

Безнең ирләр – революционерлар түгел, билгеле. Ләкин, ни өчендер, бу темага сүз чыгуга, декабрист хатыннары белән рәттән, лаеклы рәвештә, язучы хатыннары күз алдына килеп баса.

Язучы хатыны!

Гадәти ир хатыны булу гына түгел бу. Язучы хатыны булу – аларны балаларча хасиятләп тәрбияли белү, шактый катлаулы холык-фигыльләренә түзеп, сабырлык саклау, аны илһамландырып яшәү бәрабәренә үз җаныңны күп ләззәтле минутлардан мәхрүм итү дигән сүз ул. Шул чагында гына язучының иҗат чишмәсе тулып, ургылып агачак. Шул чагында гына башкаларга үрнәк булып, юл ярып барачак ул. Шул чагында гына аның янындагы нәни чишмәләр дә күркәмрәк һәм матуррак булып күренәчәк!

Туган ил каян башлана? Тату гаилә коруданмы? Томрап торган балалар үстерүдәнме? Әллә үзеңнең яшәвең белән тирә-юньдәгеләргә рәхәтлек тудыруданмы?.. Өзеп әйтүе җиңел түгел. Әмма шунысы хак: Фирая Маликова үзенең Туган ил каршындагы вазыйфасын дүрт бала тәрбияләп үстерүдә генә күрми, җәмгыятьтә тоткан урыны, кылган эше белән дә лаек булырга тырыша. Балаларының яшьтәшләренә бик матурлап «Яшь ленинчы» («Сабантуй») газетасы чыгарыша – корректор хезмәтен үти. Үзе дә җылы, матур язылган зарисовкалар белән катнаша.

– Балаларымны үстерешүдә, рухи көч биреп торуда – хезмәттәшләремнең игелеге зур, – ди ул. – Иптәшләрем һәрвакыт ярдәмчел, игътибарлы булдылар.

Һәр сабыемны алып кайту – редакция өчен дә олы бәйрәм иде. Өстәл әзерләп, кунак көткәндәй каршы алдылар мине.

Үзе сөйли, үзе кечкенә Кадриясен тезендә тирбәтә Фирая. Кадриягә исә рәхәт, бик рәхәт. Әнисе куенында тирбәлгән уңайга курчагына җыр җырлаша ул:

– Әлли-бәлли бәбкәсе,

Кая киткән әнкәсе?

– Каенлыкка җиләккә

Кадриягә бүләккә.

Бу минутта дөньяда Фираядан да бәхетлерәк кеше юктыр, мөгаен. Күзләрендә әйтеп бетергесез яшәү шатлыгы, яшәү яме. Чынлап та, теләп башкарган эшең, каршыңда томрап торган балаларың, яныңда яраткан ирең, ышанычлы дусларың булганда тагы ни кирәк? Кеше булган кеше бер-берсе өчен һәрвакыт әнә шундый бәхетле, ләззәтле минутлар тудырырга тиеш. Кылган изгелегеннән рәхәтлек табарга, көч алырга тиеш! Әгәр кешеләрне шундый төркемнәргә бүлеп карау хасияте булса, Фираяны, һичшиксез, кеше күңелен күрә белүче, кылган изгелегеннән дәрт-дәрман алып яшәүчеләр исемлегенә теркәр идек. Никадәр язмыш килеп тоташа аның күңеленә. Моннан дистә еллар элек мәктәпне бергә тәмамлаган иптәшләре бер-берсе белән Фирая аша элемтәгә керәләр, аның ярдәмендә бер-берсен табып очрашалар. Алай гына да түгел, Фираяның игътибары балаларының классташ дусларына да җитә. 80 нче мәктәпнең ата-аналар комитеты әгъзасы буларак, үз тәкъдиме белән экскурсияләргә, очрашуларга алып бара ул аларны. Редакцияләр каршында оештырылган яшь хәбәрчеләр түгәрәгенә тарта. Киңәш һәм юнәлеш биреп тора.

Урта белемне үзе дә Казанның 80 нче мәктәбендә ала Фирая. Шул елларда аларның классын токарь хезмәтенә өйрәтәләр. Авыр хезмәт, бигрәк тә кызлар өчен. Ләкин Фирая бөтен көчен, бөтен сәләтен, тырышлыгын бирә. Нәтиҗәдә, классларында берничә генә укучы белән II разрядлы токарь таныклыгы ала.

– Башкалар ике-өч сум премия белән бүләкләнгәндә, без бишәр сум алдык, – ди ул, елмаеп. Шул елның җәй аенда яңа үзләштергән һөнәре буенча токарь булып эшли. Һәм беренче эш хакына әнисен санаторийга җибәрә.

Фираяны татар теле һәм әдәбиятыннан укыткан Татарстанның атказанган укытучысы Бәрә Хөсәенова әйткән сүзләр искә төшә: «Сезнең гаилә тормышында ана белән бала арасындагы мөгамәләнең сәнгатьчә үрнәген күрәм мин», – ди торган була ул.

Гаилә – безнең җәмгыятьнең башлангычы, дибез. Ә әни кеше – аның умыртка баганасы, минемчә. Үткәнне – бүгенге, бүгенгене киләчәк белән тоташтыручы да ул. Барысы да аның йөрәге, аның күңеле аша үтә. Ана йөрәге – табигатьтәге барлык нурлар бәйләнешен җыеп, кире кайтаручы үзгә бер линза сыман. Гүя, ерак гасырлардан килгән матур кануннарны үзенә сеңдерә, бер ноктага туплый һәм тагы да камилрәк варианты белән табигатькә кире кайтара, халыкка бирә, киләчәккә тәкъдим итә.

1981 ■

Безнең мирас №10 октябрь 2019

СӘНГАТЬЧӘ ДӘ, ТАРИХИ ДА...

Әнвәр Шәрипов

Рухия Ахунҗанованың балалар өчен язган һәм 2015 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Шәһре Биләрдә кунакта» исемле китабы безнең әдәбиятта сирәк очрый торган, әмма бик тә әһәмиятле һәм кирәкле алым белән иҗат ителгән. Автор үзенә бүгенге укучыларны халкыбызның үткән тарихы белән кызыксындыруны, узган тарихыбызга карата мәхәббәт тәрбияләүне максат итеп куйган. Аңа ул кызыклы бер алым – Болгар чоры авыл балаларының Биләр шәһәренә сәяхәтен тасвирлау аша ирешә. Кушнарат авылының апалы-энеле Сөембикә белән Айтимер исемле балалары, әти-әниләренең рөхсәте белән, Биләр шәһәрен карарга чыгып китәләр һәм шул сәяхәт вакытында тормыш-яшәешнең күп яклары, күренешләре белән очрашалар, кешеләр белән танышалар, үзләре өчен ачышлар ясыйлар, тормыш тәҗрибәсе, белем туплыйлар. Әсәрнең бер отышлы һәм кызыклы ягы шунда – Сөембикә белән Айтимернең үзләре өчен ясаган ачышлары, аларның үзләренеке генә булып калмыйча, бүгенге чор укучылары өчен дә ачыш һәм белем чыганагына әверелә: аларның күргәннәрен бәян итү аша язучы бүгенге укучыларны да Болгар чорындагы бабаларыбызның яшәү рәвеше, гореф-гадәтләре, әхлакый сыйфатлары, тарихлары белән таныштыра, аларга тарихи белем, әхлакый сабак бирә.

«Озын хикәя» дип исемләнгән әлеге китап барлыгы 12 бүлектән тора. Язучы һәр бүлектә, Сөембикә белән Айтимернең сәяхәт вакытында нәрсә күргәннәрен бәян итүгә бәйләп, шул чорның табигате, Биләр шәһәренең төзелеше, биналары, Җәмигъ

мәчете, атаклы төзүчеләре, галимнәре һәм башкалар турында мәгълүматлар, белем биреп бара. Шунысы аеруча мөһим: бу мәгълүматлар бүгенге укучыга «коры» фактлар рәвешендә түгел, ә балалар белән өлкәннәрнең җанлы сөйләшүләре, сорау-җаваплары, балаларның сокланулары рәвешендә биреп барылалар. Әсәр Сөембикәнең – «апа кеше»нең сөйләме рәвешендә язылган.



Рухия Ахунҗанова тарихи мәгълүматларны әсәрнең сюжеты, сәнгатьчә сурәтләү, диалоглар белән дә органик рәвештә кушып алып бара белә. Беренче бүлектән генә дә без Болгар чоры кешеләренең нәрсәләр белән шөгыльләнүләре, яшәү шартлары, ашаган ризыклары турында да, үзара мөнәсәбәтләрдә кешелеклелек, ягымлылык, кунакчыллык кебек сыйфатлар өстенлек алуы турында да беләбез, аларның үрнәкләрен дә күрәбез.

Китапның башка бүлекләре дә шушындый ук тәртиптә, укыр өчен кызыклы, тарихи мәгълүматларга мул итеп иҗат ителгән. Тагын кайсы өлкәләрдәге тарихи мәгълүматларны таба ала бу китаптан безнең бүгенге укучы? Кыскача гына шуларга тукталып китик.

Бу әсәрдән без Биләр шәһәренең төзелешен күз алдына китерә алабыз. Билгеле булганча, Биләр шәһәре ике өлештән торган: тышкы шәһәр һәм эчке шәһәр. Р.Ахунҗанова сурәтләвендә шәһәрнең ул өлешләре күз алдына түбәндәгечә килеп баса: «Өч кат дивар белән әйләндереп алынган тышкы шәһәргә узу өчен, асылмалы күпер янына килеп бастык», – ди вакыйганы сөйләүче Сөембикә. Шунда аларга атарбалы юлаучылар очрый. Шуларның берсе – Теләй абзый белән һәм аның балалары белән танышып китәләр. Теләй абзый чакыруы буенча, аларның арбаларына утырып, шәһәргә керәләр. «Монда йортларның барысы да агачтан салынган. Нигезе – юан имән бүрәнәдән, диварын нараттан күтәргәннәр. Түбәләре такта белән ябылган», – дип сөйли Сөембикә. «Эчке шәһәрдә яшәүчеләрнең җәйге йортлары да бирედә урнашкан, – ди Теләй абзый. – Күрегезче, алар янындагы яшелчә һәм җиләк-җимеш бакчалары искитмәле!»

Тышкы шәһәрдәге зур базарда йөргәннән соң, юлаучылар шундагы Кәрвансарай янына киләләр. Сөембикә аны болай сурәтли: «Менә мәһабәт Кәрвансарай. Аның түбәсе гөмбәз сыман. Кунакханәгә алып керә торган юлга тигез итеп кирпеч ватыклары, вак ташлар түшәлгән. Ишегалдында кое бар. Ул имән агачыннан буралап ясалган». Балалар Кәрвансарай эченә дә керәләр. «Кәрвансарайның эчке ягы да күз явын

алырлык матур итеп эшләнгән, – дип дәвам итә Сөембикә. – Дивар, кытыршы урын калдырылмыйча, тип-тигез итеп сыланган. Аңа дарчин төсендәге табигый буяу белән төрле бизәкләр төшерелгән».

Аннан соң юлчылар эчке шәһәргә юнәләләр. Язучы аны Сөембикә исеменнән болай сурәтли: «Эчке шәһәр ике кат имән дивар белән әйләндереп алынган. Аңа юл Көнчыгыш капка аша үтә икән. Монда йортлар тыгыз урнашкан. Тәрәзәләре түгәрәк рәвешендә. Яшел пыялаларында кояш нурлары уйный». Теләй абзый да битараф калмый: «Күрегезче мондагы йортларны! – дип соклана ул. – Аларны таштан, кирпечтән төзегәннәр. Минем танышымның да йорты гөмбәз сыман түбәле, ике катлы. Үзе кирпечтән салынган, – ди дә, аларда җылыту системасы да булуын болай аңлата. – Зур мичтән килгән җылы һава, идән астындагы һәм диварлардагы һава юллары буенча үтеп, барлык бүлмәләрне дә җылыта. Шулай булмаганда, Хан сарае хәтле ул йортны ничек җылытып бетермәк кирәк?!»

Шуннан соң юлчылар шәһәр үзәгенә, Җәмигъ мәчетенә бару. Бу мәчетне күрү – Сөембикә белән Айтимер сәяхәтенең төп максаты иде. Шуңа күрә балалар аны аеруча кызыксынып карыйлар. «Мәхәллә мәчетләре белән чагыштырганда, Җәмигъ мәчете бигрәк мәһабәт бина шул, – дип тасвирлый аны Сөембикә. – Аның биек манарасы ерактан ук күренеп тора... Борынгырак өлеше – юан бүрәнәдән, яңасы ак таштан салынган изге йортка энем белән икәүләп тәэсирләнеп карап тордык... Ак таш белән кызыл кирпечтән салынган манара мәчеттән ике адымлап читтәрәк тора. Манараның кечкенә тәрәзә уемнары төрле биеклектә ясалган... Мәчет бинасы кыйблага карап тора. Бер ягы белән бина диварына кертеп ясалган дүрт кырлы терәк баганалар мәчетнең алгы ягына матурлык өстиләр. Керү ишеге бизәкләп эшләнгән».

Теләй абзый балаларга мәчетнең төзелеше турында: «Мәчет эчендә дүртәр терәк багана нәкъ алты рәт булып тезелгән. Түбәне егерме дүрт багана күтәреп тора. Бинаның түшәме бик биек. Идәненә фарсы келәме җәелгән, – дип сөйли. – Түр диварда, эчкә таба уеп, кыйбла тарафын күрсәтү өчен, михраб ясап куелган. Ул махсус урын, намаз укырга дип, мулла өчен билгеләнгән... Соңрак мәчетнең турыпочмаклы агач бинасына терәп, таштан яңасын төзеп куйганнар. Җәмигъ мәчетен «Бараҗ» дип атаганнар. Төзелешкә акчаны Субаш исемле бай сәүдәгәр биргән. Ул үләннәр белән дәвалаучы атаклы табиб та булган. Биләрдә хастаханә төзетеп, шунда ук даруханә дә ачкан».

Бу урында Р.Ахунҗанова татар җәмәгатьчелегенә әле 1997 елда гына билгеле булган Таҗетдин бине Юныс әл-Болгариның «Әт-тиръяк әл-кәбир» – «Агуланудан көчле дәва» дигән китабы турындагы мәгълүматны да укучыга Теләй абзый сүзләре аша җиткерә. Теләй абзый ул китапны: «Иясенә тапшырыйм», – дип, эчке шәһәрдәге бер танышына кертеп чыга.

Шулай итеп, язучы бүгенге укучыны Биләрдәге Җәмигъ мәчете, аның төзелеше белән таныштыра. Әмма шәһәр төзелеше темасы бу китапта моның белән генә тәмамланмый. Китапның «Төзүче Аслан» дигән өлешендә ул тагын күтәрелә.

Шуннан соң, Теләй абзый Биләр тарихына да кереп китә. Ул болай сөйли: «Шушы шәһәр төзеләсе урын элек тип-тигез киң ялан булган. Аулак урын, дип, өч би (түрә) киңәш-табышка һәрвакыт шунда җыелганнар. Халык биләр очраша торган бу яланны «Биләр» дип йөртә башлаган. Алмыш хан шушында яңа шәһәр төзеткән, Кәрвансарай һәм мәчет салып куйган. Хан үтенече буенча Багдад хәлифәсе җибәргән төзүчеләр бик тырышып эшләгәннәр. Әкияттәй гүзәл шәһәр шулай пәйда булган. Шәһәрне, әлбәттә, «Биләр» дип атаганнар. Чүти, Әбрак, Хум һәм Үбар кебек данлыклы төзүчеләр дә Алмыш һәм Хәсән ханнар заманында зур уңышка ирешкәннәр».

Рухия Ахунҗанова китабында икътисад, Биләр һөнәрчеләре, сәүдә элемтәләре, базардагы товарлар хакында да мәгълүматлар бар.

Әсәрдә Биләрнең тышкы шәһәрендәге базарда ефәк тукымалар, затлы келәмнәр, керәч (фаянс) чынаяклар, хәрби кирәк-яраклар (боҗралардан эшләнгән «көбә» күлмәк, күкрәк һәм арка япкычлары, калкан, хәрби баш киеме һ.б.) сатылуы әйтелә. Ә эчке шәһәр базарында сурәтле йозаклар, корычтан коелган пычак, балталар, бакыр казан, җиз комган, бизәкле көзге, бизәнү әйберләре, тарак, төймә, сәдәпләр, хәситәләр сатыла икән.

Рухия Ахунҗанова әсәре этнографик күзәтүләргә дә бай. Мисаллар китерик. Сөембикәләр күрше авылда танышкан Тәңкәсылу белән Айдашның «икесенең дә өсләрендә – киндер күлмәк, аякларында – бизәкле күн башмаклар». Теләй абзыйны автор «өстенә яшькелт казаки, башына җәйге бүрек кигән мөлаем гына абзый» дип сурәтли. Сусылу апаларының өе безнең күз алдына болай килеп баса: «Өй эче бик җыйнак һәм гади иде. Кышын – җылы, җәен ямь биреп торучы мич тигез итеп акшарланган. Мич алдында, учак көлен саклау өчен, чокыр ясалган. Түр яктагы такта сәке өстенә пөхтә итеп урын-җир өеп куелган. Янәшәдә ике агач сандык тора. Аларның икесенә дә җиз калайдан ясалган бизәкләр беркетелгән. Диварга кыска сүрәләр язылган матур шәмаил эленгән. Идән-сәке чиста итеп юылган...»

Бу китаптан ономастика өлкәсенә караган шактый материал табарга мөмкин. Анда Болгар чорында кулланылган кеше исемнәре күп китерелә. Тел белгече, академик М.З.Зәкиев исбатлаганча, болгарлар борынгы төрки-татар телендә сөйләшкәннәр. Кеше исемнәрендә нәкъ менә шул чор төрки-татар теле чагылыш таба да. Игътибар итик: хикәянең үзәк геройлары Сөембикә белән Айтимер. Әти-әниләре – Туктаман белән Албикә. Сөембикәләр күрше авылда танышкан балалар Тәңкәсылу белән Айдаш исемле; аларның әниләре – Сусылу, әтиләре – Иржемәс. Күрше авылда уен уйнаган балаларның исемнәре – Албарс, Алпак, Әрдуан, Күкләш, Аван, Байдык, Сыртлан. Сөембикәләрне атка утыртып баручы – Теләй абзый; аның балалары Белемчәк белән Айсылу. Теләй абзыйның Биләрдәге танышы – Шәехби, аның улы Шәмсираван («яхшы кылыч» мәгънәсендә). Боларның барысы да болгар исемнәре. Әсәрдә шулай ук Субаш һәм Әбүбәкер исемле сәүдәгәрләр дә искә алына. Төзүче Аслан, аның улы – Яхам. Тарихчы галим Ягъкуб бине Ногман, аның оныгы Давыт һәм башкалар. Алар – тарихи шәхесләр.

Әлеге китапта борынгы бабаларыбызның күчмә тормышта яшәгән вакытта иң якын ярдәмчесе һәм дусты булган атлар турында да хәзерге кешеләрнең бик сирәге генә белгән мәгълүматлар китерелә. Биләрдән кайтып барганда, безнең сәяхәтчеләр бер урында ялга туктыйлар һәм шунда Теләй абзый, малайларның сорауларына җавап бирә-бирә, атлар турында тулы бер «лекция» сөйли: «Ат – үзенчәлекле хайван. Түземле һәм көчле, өстәвенә аңлы да. Ат үзен кайгырта белә. Мәсәлән, җил чыга икән, болында утлап йөргән җиреннән китеп, ул үзенә тиз генә ышык урын таба. Андый очракта «югалган» атыңны урман тирәсеннән яисә чокыр-чакырлы урыннардан эзлисең. Ул шунда була да. Ат бигрәк тә агач төпләрендәге үләнне кыркып ашарга ярата.

Атлар теләсә кайсы вакытта йоклыйлар. Аягөсте йоклыйлар. Әйтик, хуҗасы йомыш белән кемгәдер кереп китте, ди. Капка төбендә калган ат, хуҗасы әйләнеп чыкканчы, бик рәхәтләнеп черем итеп алырга өлгерә. «Ничек егылмый соң ул?» – дигән сорауга Теләй абзый: «Ат, йокыга киткәч, аяк буыннарын «йозакка» бикләп куя икән. Җиргә аумавы шуннан. Аллаһы Тәгалә аны шундый итеп яралткан», – дип җавап бирә. Аннан тагын дәвам итә: «Атларның да аерым якын күргән дус атлары була. Ат-

лар ерактан ук кешнәшеп сәлам бирешәләр... Дус атлар ризыкны да бүлешеп ашыйлар. Алар бик сизгер хайван. Улагындагы ризык арасында ялгыш килеп эләккән чит нәрсә була икән, Ак кашка аны ашамыйча аралап калдыра. Гомумән, атлар хәтта энәне дә сизәләр. Хуҗаның да атка карата һәрчак игътибарлы булуы кирәк. Атны озак һәм кызу йөртеп, шабыр тиргә батырырга, хәлдән тайдырырга ярамый. Моны «атны яндыру» диләр. Атка артык авыр йөк төяп, өшәндерергә дә ярамый. Шула-ай, ат башы бик күп нәрсәләрне күрә. Дөньяда күпне күргән кешегә дә «тояк суы эчкән кеше», диләр бит».

Бераздан Теләй абзый, горурланып, тагын сөйләп китә: «Атны кулга беренче ияләштерүче халык – безнең бабаларыбыз ич! Алар атларны авыр эшләрдә, сәүдәдә, сәфәрдә, яуда кулланганнар. Озын торыклы, озын муенлы аргамак – иң яхшы хәрби ат. Андый ат сыбайны, ягъни атлы сугышчыны аңлый, тыңлый, төрле оста хәрәкәтләр башкара белә. Бу һөнәрләргә атны махсус өйрәтәләр. Сыбай аты, өстендәге сугышчы белән бергә авышып, тиз генә борыла алса, ат үзе дә, җайдак та үлемнән котылып кала. Атның бу һөнәре «дим» дип атала. Әлеге һөнәргә ия булган ат димле ат була. Андый ат бик кыйммәт тора.

...Атларның йөрешләре аларның холыкларына бәйле. Чаман ат әкрен йөри. Чалык ат тиз хәрәкәт итә. Чарыс ат – тиз йөрешле ярсу ат. Артак ат – өйрәтелмәгән, кыргый ат».

Шуннан соң Теләй абзый атларның төскә бәйле исемнәрен санап китә: ак, акбүз, алмачуар, бурлы, бүз, бүртә, кара, коба, кола, коңгырт, көрән, күк, күк-ала, күкбүз, сары, тимер-күк, туры, тәңкәчуар, чал, чуар, җирән... (Игътибар итик, атларның бу кадәр төрләрен хәтта энциклопедияләрдә дә табып булмыйдыр әле!)

Теләй абзый тарихка да кагылып ала: «Хәрби атлар элек «тулпар» дип йөртелгән. Димле тулпарларга атланган бабаларыбыз өченче гасырда вак атлы кытай гаскәрләрен тар-мар иткәннәр. Шуннан соң кытайлар да үз атларын яхшырту чарасына керешкәннәр». Ул бик сирәк очрый торган атамаларны да искә төшерә: «Конан – өч яшьлек ат. «Дүнән» дип дүрт яшьлек атка әйтәләр. Бер яшькә кадәрге ат баласын – «колын», ә икенче яшькә чыкканын «тай» дип атыйбыз».

Сәяхәтчеләр кайтыр юлга чыгалар. Юлда туктап, тамак ялгап алалар. Шунда алар атаклы галимнәр, белем алу турында әңгәмә коралар.

Р.Ахунҗанова әсәрендә Болгар дәүләте чорындагы гореф-гадәтләр дә чагылыш таба. Бездә борынгыдан кечкенә баланы яратып башыннан сыйпау гадәте булган. Әлеге гадәт бу әсәрдә дә бәян ителә.

Күренә ки, кечкенә генә бер китапта язучы никадәр тарихи мәгълүмат, яхшы әхлак үрнәкләре китергән, аларны укучыларга, кызыклы сюжет төзеп, мавыктыргыч вакыйгалар аша, сәнгатьчә алымнар белән җиткерә алган. Болай язу өчен, әлбәттә, халкыбыз тарихын бик яхшы белергә һәм аны укучыга кызыклы итеп бирү сәләтенә ия булырга кирәк. Ә Рухия Ахунҗановада ул сәләт бар. Киләчәктә без Рухия ханымга иҗатта үзенең шушы алган юнәлешенә тугры калып, укучыларны яңадан-яңа әсәрләр белән куандыруын теләп калабыз. ■

Безнең мирас №10 октябрь 2019

ТАТССР

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫНА – 100 ЕЛ

И, БӨЕК КИТАП...

Нәкыя Гыйләҗева

Шул вакытта мин кулыма китап алам,
Аның изге сәхифәләрен актарам...
Г.Тукай

Беренче рәттә: уң яктагы кыз бала – Нәкыя, аның артында – әнисе Нәүбаһар апа. 1944-1945 еллар

Ничәмә-ничә гасырлар дәвамында кешелек яшәеше турындагы мәгълүматны без бары тик китап аша гына күңелебезгә сеңдерә килгәнбез. Аллаһы Тәгалә тарафыннан иңдерелгән Бөек могҗизадыр ул китап дип аталган әсбап.

Китап, тарих тоткасы, гасырлар авазы булып, янәшәбездә яши бирә. Үземне белә-белгәннән бирле, укымышлылар гаиләсе булмасак та, өебездә гарәп шрифтында язылган китаплар бихисап иде. Әткәем Илһаметдинне «халык дошманы» дип юк иткән (1940) елларда да әнкәем Нәүбаһар үзенең кайгысына китаплар укып кына дәрман тапкан. Кайгысын кемгә генә сөйләп уртаклашырга теләсә дә, ул үзенең җанына җылылык таба алмаган. Кемнең дус, кемнең дошман икәнлеген ничек кенә чамалый алсын соң ул? Нинди китаплар укып үзен юатканлыгын төгәл генә әйтә алмыйм, әнкәемнең кайгы-хәсрәтенең тирәнлеген аңларлык яшьтә булмаганмын. Аның 36 яшенә кадәр никадәр җәбер-җәфалар чиккәнлеген чамаларга гына була... 1929 елда, кулаклар, дип йортларын сүтеп алып, Сарманда урта мәктәпнең бер бинасын корганнар. Инде килеп, 1940 елда әткәем йорт төзеп диярлек өлгерткәч кулга да алганнар. Миңа өч яшь ярым, бу хәлләрне бөтенләй белмим, тора-бара әзрәк чамалый башлаганда әнкәемнең җелый-җелый китаплар укып утырырга вакыт тапканын хәтерлим. Без – дүрт бала, миннән кече булып, 1940 елда туган Азатыбыз да бар. Әнкәй көне-төне эшләп дөнья куган, мал асраган, колхоз эшендә бил бөккән. Кышның озын төннәрендә керосин лампасы яктысында бөгелеп-бөгелеп, җелый-җелый китаплар укып утыра торган иде ул. Өйләрен төяп алып киткәндә юк ителгән китапларының язмышын уйлап өзгәләнә торган иде. Хәтта минем әткәемнең фотолары да шул ата – улны, ана – кызын танымаслык хәлгә китереп җиткерелгән чорларда юкка чыгарылган. Минем әткәемнең сурәте дә юк бит ичмасам...

Уйлануларым китап турында иде бит, әллә нинди хискә биреләдем. Әнкәем үзенең чордаш, теләктәш, фикердәшрәк булган дуслары белән безнең өйдә китап укып утыра торган иде. Ул китапларның истә калганнарыннан берсе – «Кыйссаи Йосыф» китабы. Алар аны укыйлар иде дә, билге өчен тукталган җирдәге битенә кәгазь кыстырып, иртәгесен дәвам итәчәкләренә вәгъдәләр куешып таралыша торганнар иде. Мин аларның шул ки-

тапны укыганда үз-үзләрен тотышларына, Корьәндәге сүрәләргә бәйләп бер-берсен бүлдерә-бүлдерә сөйләшүләренә колак сала торган идем. Ул китаплар нинди наширләр тарафыннан бастырылган булгандыр, анысыннан хәбәрдар булып өлгермәгәнмен. Ләкин шунысы хак, татар гомере буена китапны кадерләп яшәгән.

Татарстан китап нәшрияты үзенең 100 еллык юбилеен билгеләп үтәргә җыена. Бу аның рәсми билгеләнгән статусыдыр дип беләм. Юкса, әйткәнемчә, татар китаптан гомер-гомергә аерылмаган.

Аязымның инде ярыйсы гына язучы буларак танылган еллары иде. Берзаман ул миңа әйтә: «Нәкыя, Татарстан китап нәшрияты «Кыйссаи Йосыф» китабын чыгарган. Гарәф Низаметдинович Шәрәфетдинов, кош тоткан кебек куанып, култыгына бер данәсен кыстырып, Обком вәкилләренә күрсәтергә дип китеп барды», – ди. Бу хәл 1983 елда булган. Шул китапны кадерләп төреп куйган җиремнән кулыма алып, янәшәмә куеп, язып утырам. Бәяләп бетергесез бу зур хәзинә – СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы галимнәре чыгарган әлеге китап барлык татар интеллигенциясе тарафыннан да хуплап каршыланды. Бәясе 4 сум 30 тиен иде. Аның тиражы 10 мең данә генә булып, Аязны шундый аз тираж куркуга салды. «Бу бер атна эчендә сатылып бетәчәк!» – дип, кунакка барганда дусларыбызга бүләк итәрлек иң дәрәҗәле бүләк итеп, аны күпләп сатып алды. Өч улының өчесенә дә гомерләре буена сакларга, ул хакта мәгълүматлы булырга кушып, мирас итеп калдырды...

Нәкыя белән Аяз. 1959 ел

Мең-мең еллар яшә, милләтебез күгендә якты йолдыз булып балкуыңны дәвам ит, Татарстаныбызның китап нәшрияты! Амин! ■

КАЗАКЪ ӘДӘБИЯТЫ КЛАССИГЫ АБАЙНЫҢ ВАФАТ БУЛУЫНА 115 ЕЛ

ХИКМӘТЛЕ СҮЗ

Абай

Адәм баласының иң яманы – үз-үзенә таләпсезе, омтылышсызы булыр. Дөрес, кешедә таләп, омтылышлар төрлечә булырга мөмкин. Белемгә омтылу бар, һөнәр үзләштерү таләбе бар. Әйе, адәм баласының үз-үзенә таләп куеп яшәгәне һәм көн үтсенгә яшәгәне була. Ни-нәрсәгәдер омтылып гомер итүчеләр һәм максатсыз көн күрүчеләр була. Мондый сыйфатлар күпләребезгә хас. Иң яманы – шулар арасында үз-үзен һәм үзе кылган гамәлләрне һәрдаим мактатып торучылар, шуңа омтылып яшәүчеләрдер. Урынлымы ул, урынсызмы – андыйларның күңеле һәрчак мактау сүзе эзли, мактаулар көтеп тора. Алар өчен иң якын кеше – мактаган кеше. Шуңа күрә андый кешеләр теләсә кем белән дус, сердәш була. Тик ул бәндә дә аның кебек булсын. Мактансын, мактасын гына. Башка кешеләр аларга сердәш тә, юлдаш та була алмый.

Ә башка берәүләр мал, байлык артыннан куучан була. Саранлык беләнме, хәрәмләшепме – ничек булса булсын, тик баесын гына. «Мал тапкан ирнең языгы юк» яки «Байның йөзе һәрчак ак була» кебек әйтемнәр аларга акланыр өчен бик кулай фал инде. Эт булып өрсәң дә, бай булсаң, халык синә карата бер яман сүз дә әйтмәячәк, дип уйлыйлар инде алар. Андыйларның бар хасияте, омтылышы – башкалардан аерым булырга тырышу. Аларның мал, байлык туплавы да башкаларга да файда булсын өчен дип түгел, башкалардан өстен күренү өчен генә.

Безнең казакъларның хәзерге яшәү рәвешендә андый баю әле мәртәбәле дә, мактаулы да санала. Әмма бөтен кешелек акылы белән исәпләгәндә – мондый дәрәҗәгә омтылыш акланмый. Үз дәрәҗәңне күрсәтү өчен генә баю – җирәнгеч хәл.

Ә кайберәүләр үз ишләре арасында бик кирәкле саналырга тели, шуңа омтыла. Икенче берәүләрнең исә үз ише арасында батыр булып күренәсе килә. Бар яктан зур белгеч булып күренәсе килүчеләр дә, оста арадашчы исемен йөртергә теләүчеләр дә очрый. Һәркем үзенчә шул данга омтылмакчы. Үзләрен бар халыкка якын үз кеше, иң кирәкле зат итеп танытырга тырышучылар да бар. Әмма боларның барысыннан да диярлек казакъ халкына файда бик аз. Чөнки аларның күпчелеге үзләрен шундый кеше итеп күрсәтергә генә тырыша. Алар халыкка ничек ярарга кирәклеген китаплардан укып түгел, үз тирәлекләрендәге мохиткә нигезләнеп кенә беләләр. Китап укып, күпчелек тәҗрибәсенә таянып эш итсәләр, бар халыкка да файда булыр иде. Шул очракта күңелләре дә саф, омтылыш-таләпләре дә изге булачак. Халык өчен андый омтылыш-теләкләр бәрәкәт китерәчәк.

Бүген безнең төп омтылыш, төп таләпләр – белемле булуда...

*Казакъчадан тәрҗемә итүче – **Лирон Хәмидуллин***
(Абай Конанбаев җыентыгы «Абай». – Казан, 1981 ел)

***

Ышанма беркемгә, торса да ул мактап,
Мактар сине, эчендә ул хәйлә саклап.
Тик үзең ышан, – сине алга илтер
Хезмәтең һәм акыл, тотып ике яклап.
Ышанучан булып, үзең харап итмә,
Дан һәм мактаулар артыннан чабып китмә.
Үзеңне дә, илеңне дә бергә алдап,
Буш хыяллар куып, йөрмә йөгереп тиккә.
Кайгы килсә, гел каршы тор, башың имә,
Шатлык килсә, аңа артык күңел бирмә.
Йөрәгең эченә кер, төбен күзәт,
Табарсың чын асыл ташны тик шул җирдә.

*Казакъчадан **Әхмәт Исхак** тәрҗемәсе*

***

Татар-нугайны күрсәк тә без яман итеп көлешә башлыйбыз: «Татарның, дөя күрсә, коты алына», – дибез. «Атка атланып та йөри белмәгән ул бәндәләргә нугай дип түгел, нукай (килешсез, мәгънәсез) дип исем бирәсе калган», – дибез. «Качакны очратасыңмы, мескен солдатка тап буласыңмы, каңгырып йөргән кырык тартмачыны күрәсеңме – шул татар булыр», – дибез...

Инде татар-нугаена килсәң, солдат хезмәтенә дә чыдам, ярлылыкны да, килгән казаны да түзем генә кичерә белә алар. Мулла, мәдрәсәләрен саклап, Ходайга зарланмый гына яшиләр. Хезмәт куеп мал табуның да җаен шулар белә, зат-зиннәт тә юк түгел үзләрендә. Козгын тамагыбызны туендыру өчен без татар байларына әле ялчы, әле кош аулаучы булып ялланып кына торабыз... Андый халык һич хур булмас, чөнки һаман һөнәр үзләштереп, төрлечә мал табып, бер-беренә булышып көн күрәләр.

*Казакъчадан **Лирон Хәмидуллин** тәрҗемәсе* ■

Безнең мирас №10 октябрь 2019

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов

Васэда университеты студентлары, XX гасыр башы

ЭЛЕККЕГЕ ЧИТ ИЛЛӘР ЭШЛӘРЕ МИНИСТРЫ КОНТ ОКОМА

Конт Окома сүзләрен шул рәвешле тәмамлады:

– Сезнең белән танышуыма бик сөендем. Минем кебек карт кешене искә алып килүегез өчен аеруча рәхмәт. Әле тагын күрешеп сөйләшербез, дип өмет итәм. Тик, гафу итүегезне үтенәм: бу арада гына Сезне күрергә килә алмаячакмын, аякларымның авыртуы көчәеп тора. Минем исемнән Сезнең хәлегезне белергә киявем килер. Ә инде менә бу күрешүебезнең истәлеге итеп хәзер, әйдәгез, бергә рәсемгә төшик, безнең бакчабызны да күрерсез, рәхим итегез!

Шулай диде дә, Конт Окома ишеккә таба атлады. Мин дә аңа иярдем. Озын коридордан үтеп, пыяла бина эчендәге

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

гөл бакчасына чыктык. Шунда ук фотоаппарат та тора икән. Рәсемгә төштек, фотоаппарат рәсемне дә шул минутында ук чыгарды. Бер рәсемне миңа бирделәр. Бу минем өчен бик зур истәлек иде. Ләкин бик кызганыч, бу рәсем дә Русия почтаханәләрендә югалган яки алынган булып чыкты.

Шушы урында Конт Окома җәнапларының тормыш юлы хакында да бераз мәгълүмат бирергә телим.

Конт Окома – японнар элек *самурай* дип атап йөрткән аристократ сыйныфтан чыккан олпат ир. Япониядә алпавытлык бетерелеп, мөстәкыйль дәүләт оешкан вакытта, самурайлык та юкка чыккан. Ул вакытларда Конт Окома халкы өчен хезмәт итүче бөек шәхесләрнең берсе булып саналган. Дәүләтнең идарә эшләре җайга салынып, чит илләр белән бәйләнешләр корыла башлагач, Конт Окома чит илләр эшләре министры итеп куела. Шул көннән башлап, ул япон халкында иң могтабәр һәм иң эшлекле дәүләт кешеләренең берсе, милләтенең киләчәге өчен көн-төн хезмәт куюы белән горурланучы шәхес булып таныла. Халкының киләчәген уйлап, Конт Окома Васэда университетын ача. Югарыда телгә алынганча, башта 150 студентка белем биргән университетта бүген 8000 студент укый. Моны милләт өчен эшләнгән бик зур фидакарьлек дип атарга кирәк. Милләтенең киләчәген уйлап, Аврупа белән Япония хөкүмәте арасында сәяси һәм икътисади бәйләнешләр турында бер килешү дә төзи. Ул вакытларда японнарның кайберләре, бу хәлгә ризасызлык белдереп: «Безне аврупалылар әсир алачак!» – дип куркуга калалар, нәтиҗәдә, Конт Окомага һөҗүм итеп, өстенә бомба аталар. Менә шулвакыт аның уң аягы бик нык яраланган, тик үзе исән кала алган. (Бүгенге көндә уң аягы – протез аяк. – *Габдерәшит Ибраһимов искәрмәсе*.) Шул вакыйгадан соң, Конт Окома министрлыктан киткән, ләкин милләте өчен ул бүген дә иң могтабәр, иң абруйлы кеше.

Конт Окоманың бик сәер ышанулары бар: үзе бүген 70 яшьлек карт.120 яшенә кадәр яшәп, милләтенә шул вакытка кадәр армый-талмый хезмәт итәчәк. Япония киләчәктә иң зур, иң дәрәҗәле дәүләтләрнең берсе булачак һәм шул вакыт дөньяда сугыш коралы, кораллану дигән нәрсә бетәчәк. Аврупада тоташ инкыйраз булачак, хәтта Аврупаның бүгенге көч-куәтенең эзе дә калмаячак.

ВАСЭДА УНИВЕРСИТЕТЫ

Япониядә иң зур шәхси университетларның берсе – Васэда университеты. Илдәге уку йортларының күпчелеге – халык уку йорты. Дәүләт уку йортлары бөтен уку йортларының 7 процентын тәшкил итә. Бу халык уку йортлары арасында Конт Окома кебек шәхес яки берничә кеше берләшеп ачкан уку йортлары да аз түгел. Афора исемле бер сәүдәгәр ачкан – бөтен чыгымнарын берүзе күтәргән – өч лицей-интернат бар. Шундый шәхесләр рухи һәм матди көч куеп ачкан, халыкка хезмәт күрсәткән башлангыч мәктәпләр, лицейлар бик күп, университетлар да бар. Шундый университетларның берсе – менә шул Васэда университеты.

Бу уку йорты Конт Окоманың йорты каршысында моннан 25 ел элек 150 бала өчен ачылган, ул вакытларда бер бина булган. Аннан соң һәр ел, ихтыяҗ арткан саен, биналар да арткан, бүгенге көндә уку йорты шәһәрчек дип аталырлык мәйдан биләп тора, Япониянең үзәге булган Токио шәһәрендә иң зур һәм иң мәшһүр уку йортларының берсе булып санала. Иң дәрәҗәле профессорлар бу университетның шәрәфле укытучылары булулары белән горурланалар.

Уку йорты ике өлешкә бүленгән: университет һәм хәзерлек бүлеге. Боларда 8000 укучы укый, аларның 1261е – Кытай, 400дән артыгы – Корея, 28е – Филиппин, 14е Америкадан

килгән яшьләр икән. Менә шул Кытайдан килгәннәр арасында 38 мөселман бар. Мин уку йортын карарга барганда, җитәкчеләр һәм укытучылар белән күп тапкыр күрешеп сөйләштем. Укучылар белән дә аралаштым, бигрәк тә мөселман яшьләр белән аерым да күрештем.

Беркөнне Васэда университетына инглизчәсе бик яхшы булган Мисыр офицеры Әхмәт Фазлы бәй белән бергә бардык. Әхмәт Фазлы бәй югары сыйныфларда укучы ике меңгә якын студент алдында инглизчә чыгыш ясап, Исламның фазыйләтләре – яхшы сыйфатлары турында сөйләде. Студентлар бик канәгать калдылар. Моңа бигрәк тә мөселман яшьләр сөенде, безнең белән кабат күрешергә дә килделәр.

Әхмәт Фазлы бәй, әйткәнемчә, Мисыр офицеры, Судан һәм Мәһди[1] сугышларында катнашкан яшь мөселман кешесе, инглиз һәм француз телләрендә бик яхшы сөйләшә. Ни сәбәптәндер, белмим, моннан биш еллап элек, Мисырдан Япониягә күчеп килеп урнашкан. Биредә бер япон кызына – авыл кызына өйләнгән. Бераздан хатыны һәм хатынының анасы, бергәләп Мисырга барган җирләрендә, мөселманлыкны кабул иткәннәр. Гаилә кире Япониягә кайткан. Хәзерге вакытта алар Токиога якын гына урнашкан Нипполи дигән авылда яшиләр. Бүгенге көндә: «Япония мәмләкәтендә мөселманлыкны кабул иткән беренче хатын-кыз – Әхмәт Фазлы бәйнең хатыны һәм мөселман булып беренче туган бала – Әхмәт Фазлы бәйнең улы», – дип, Япония-Ислам тарихына теркәлсә, бик дөрес һәм бик урынлы булыр.

[1] 1885-1899 еллар арасында Аврупа колонизаторлары тарафыннан Суданны буйсындыру өчен алып барылган сугышлар һәм бу басып алуларга каршы баш күтәргән мәһдичеләр турында сүз бара. Баш күтәрүчеләрнең җитәкчесе үзенә Мәһди исеме ала, баш күтәрүнең атамасы да шуннан килә (тәрҗ. иск.).

ГАЗЕТАЛАР

Аннан соңгы көннәрдә шактый гына газета идарәләренә күрешергә бардым. Япониядә газеталарның саны искиткеч күп. Шәһәрләрдә генә түгел, хәтта авылларда да газеталар чыга. Һәр көн чыга торган газеталар да бар. Аерым алганда, Токиода чыккан газеталарның төгәл санын белмим, бары идарәләрен үзем барып күргән газеталарны гына биредә санап китәчәкмен. Боларның беренче һәм икенчесе көн дә ике тапкыр чыга торган газеталар: «Хоти Шимбон», «Йамато Шимбон», «Кокомин Шимбон», «Нижи-Нижи Шимбон», «Тохошики», «Җиҗи», «Асахи», «Май Ниҗи», «Җуэв», «Май Ниҗи Динпо», «Нирон», «Мийако Йоми Ори». Болар барысы да япон телендә нәшер ителә. Инглиз телендә дә шактый санда газета чыга, ләкин мин «Жапон Таймс» [«Japon Times»] газетасының мөхәррире Баба дигән кешедән башкасы белән күрешә алмадым.

Газеталар бик арзан. «Хоти Шимбон» газетасы көнгә ике тапкыр – иртән һәм кичен – чыкса да, бәясе айга 33 син. Безнең акча белән ул 4 куруш (тиен), бер нөсхәсе 1 син була, ягъни 5 акча дигән сүз.

«Йамато» газетасының айлык бәясе 17 син, ягъни ике куруш биш акча дигән сүз. Ләкин моның да бер нөсхәсе 1 син – 5 акча. Бары тик «Асахи» һәм «Манҗу» газеталарының нөсхәләре 2 син тора. Боларның икесе дә ярым рәсми газета булып санала, мәмләкәтнең алдынгы катлавы тарафыннан үз ителә.

Бу газеталарның һәрберсендә минем турында бик тәфсилләп язылган мәкаләләр басылды. Моннан тыш, татар мәктәбе турында тарихи вакыйгалар кергән язмалар да чыкты. Кайберләре рәсемемне, икенчеләре рәсемем белән бергә кулъязмамны һәм имзамны бастырдылар. Бөтен япон матбугаты шәхесемә зур игътибар һәм илтифат


回答諾否のばす

組合側 団交継続申し入れ

ハロー京都

八幡丸物代表取締役 堀川 修三

“オンボロ車”で世界旅行

米人夫妻、ひょっこり京都入り

帯ノコに巻きこまれ工員死ぬ

Япон газетасы

күрсәтте. Атналык газеталарның күбесендә минем хакта зур-зур мәкаләләр, рәсемнәрем басылды. Башкала газеталары Япониядә бик зур дәрәҗәгә ия, бик күп укыла. «Хоти Шимбон» газетасы, мәсәлән, 350000 нөсхә дә басыла икән. Көнгә ике тапкыр басылганга күрә, бу – 700000 нөсхә дигән сүз.

«Хоти Шимбон» газетасының 24 автомобиле бар, басылып чыккан газеталарны ул автомобильләрдә үзләре тараталар. Шул рәвешле, почтаны көтеп торырга да кирәкми. Газеталар бары тик бик ерак төбәкләргә генә почта аша җибәрелә. Токио тирәсендә 40-50 км, хәтта 100 км ераклыкта урнашкан торак җирләренә дә газеталарны үзләре илтәләр.

Моннан тыш, бөтен япон журналист-язучылары газеталарының сатылып акча китерүләрен генә көтеп яшәмиләр, басу машинасыннан чыккан иң беренче газетаны шунда ук редакция ишегенә һәр ике ягын да укый алырлык итеп рамага кертеп куялар. Фәкыйрь кешеләр дә бушлай укый алсын өчен, газеталарын шәһәрнең халык иң күп йөри торган мәйданнарына, күпер башларына элеп куялар. Бу дәрәҗәдәге юмартлыкның үзләрен бик мәдәни дип атап йөрткән мәмләкәтләрдәге газета идарәләрендә дә булуы мөмкин түгел, дип уйлыйм.

ПОЧТАЛАР

Японнарда почта эшләре бик яхшы җайга салынган. Почтаханәләр хат, акча һәм башка нәрсәләр җибәрү өчен көне-төне ачык. Бары тик анда эшләүчеләр генә алышына, сәгатьләп эшлиләр. «Почта ачылды, почта ябылды», дигән сүзләр бөтенләй юк. Беркөнне сәгать 12дә, ягъни төн уртасында, Йокохамада почтаханәгә кереп, бер дустыма тапшырыр өчен пакет бирдем. «Бу акчаны алсагыз, фәлән урамдагы фотографчыга кереп,

фоторәсемнәремне дә алып килегез!». Дустым Омиха икенче көнне сәгать иртәнге тугызда Йокохамага килеп, фоторәсемнәремне китереп тапшырды. Менә бу тәртип! Мондый почта челтәре булган мәмләкәткә телеграфның да хаҗәте юк!

Почтаханәләр шулкадәр күп: санап бетерерлек түгел. Моннан тыш, бөтен даруханәләрдә дә, кибетләрдә дә заказлы хат кабул ителә, почта маркасы бөтен кибетләрдә сатыла. Халыкка җиңеллек китерү менә шул була!

Тагын да сәеррәге: почта аша җибәреләсе әйберләр, мәмләкәт эчендәге берәр җиргә китәсе булса, кәгазьгә төрелеп, бау белән бәйләнә дә адрес языла – шул гына. Моның юлда югалуы яки алыштырылуы белән бәйле бернинди дә курку юк, хәтта андый хәлнең булу ихтималы да юк.

Безнең Русиядә почта аша җибәрелгән әйбергә «посылка» диләр. Аның почтаханәдә кабул ителүе өчен, иң беренче, ул тегелгән булырга тиеш. Тегелгән очракта да, йә ак, йә кара җеп белән генә тегелгән булырга тиеш. Яртысы ак, яртысы кара булырга тиеш түгел. Бәйләнгән булырга, мөһерле булырга тиеш һ.б., һ.б. Почта аша 110 акчалык әйбер җибәрергә кирәк булса, бер зур канун китабы укып ятларга кирәк була. Аңа да карамый, «посылка» барыбер югала. Японнарда андый вак-төяк әйбер җибәрү өчен һич кенә дә канун-фәләнгә хаҗәт юк, почтаханәгә китер дә тапшыр. Биредә хезмәт күрсәтүдәге иң төп максат – эш кешесенең вакытын алмау, эшне җайлы итү һәм тизләтү.

Токиода яшәгәндә, мин торган җиргә якын гына бер почтаханә бар иде. Иртән яисә кичен, кайчакларда шунда барып утырып тора идем. Беркөнне бер хатын вак-төяк нәрсәләр белән бер иске газета бите һәм бау кисәге китереп, почта хезмәткәренә бирде: «Омру дигән җиргә Такар Мийако дигән кешегә җибәрергә», – диде дә китте.

Почта хезмәткәре ул әйберләрне җыеп кәгазьгә төрде, бау белән бәйләде, адресын язды, дәфтәргә теркәгәннән соң, квитанция кәгазен почтада эшләгән курьер малайга бирде һәм: «Фәлән хатынга тапшыр», – диде. Менә почта хезмәте, менә милләт! Бу милләтне күпме генә мактасаң да мактап бетерә алмассың.

ЯПОННАРДА ТАРИХ БАШЫ

Һәр милләттә элек-электән үз тарихын исәпләү өчен атаклы вакыйгалардан берсен тарихның башлангычы итеп кабул итү гадәте булган. Көнбатыш халыкларында Гайсә галәйһиссәламнең тууы, мөселманнарда Пәйгамбәрнең (с.г.в.) һиҗрәте[2] кебек вакыйгалар – шулар исәбеннән. Японнарда исә, кытайлардагы кебек, һәр хөкемдарның тәхеткә утыруы тарих башы булып саналган. Хөкемдар тарафыннан ул көнгә нинди дер бер исем бирелгән. Әлеге хөкемдарның яшәве дәвамында тарих, дата шул исем белән аталып йөртелгән. Хөкемдар вафат булганнан соң, тарихның исеме дә, башланган көне дә үзгәрә. Мәсәлән, хәзерге вакытта японнарда Микадоның хакимият дәвере бара һәм тарих өчен Миди – Микадоның тәхеткә утырган көне башлангыч булып санала. Мин Японриягә 41 нче Мидидә килдем, 42 нче Мидидә киттем. Хәзер анда 43 нче Миди, димәк, Микадо тәхеткә утырганнан соң 43 ел үткән. Шәхесе хакында сүз алып барылган зат, ягъни Микадо 16 яшендә тәхеткә утырган. Шул рәвешле, бүген Микадо 59 яшендә. Микадо вафат булса, тарихның исеме һичшиксез үзгәрәчәк, аннан соң киләчәк император нинди исем бирсә, тарих шул исем белән аталып, беренче елы, икенче елы дип саналып китәчәк.

Милләтнең үткәне шул төрле-төрле исемнәр белән атала һәм санала. Мәсә-

[2] Мөхәммәт пәйгамбәрнең (с.г.в.) 622 елда Мәккәдән Мәдинәгә күчүе (тәрҗ. иск.).

Васэда университетының төп бинасының бүгенге күренеше

лән, үлеләрне яндыру ысулының кулланылышка керү вакыты итеп, 30 нчы Тимпотинно датасы күрсәтелә. Милләтнең үз елъязмалары да бар. 30 нчы Тимпотинноның милади кайсы елга туры килүен белергә теләп мөрәҗәгать итсәгез, шунда ук милади 673 елда икәнлеген күрерсез.

Мәсәлән: «Киото шәһәре башкала итеп кайчан кабул ителгән?» – дигән сорау куелса, җавап: «50 нче Коммотиннода». Аннан соң елъязмага карасаң, милади 782 ел булып чыга. Тагын, Токио шәһәренең кайчан башкала булуын белергә теләсәгез, әлеге вакыйганың 1 нче Миди елында булганын, аннары елъязмага карап, моның милади 1867 елга туры килүен белә аласыз. Ләкин үзләре һич тә алай миладигә күчерүнең кирәген күрмиләр, гел: «Фәлән тарихның фәлән елы», – дип атау белән чикләнәләр. Хөкүмәт даирәләренең һәммәсендә дә рәсми эш кәгазьләре шул шәкелдә теркәлә. Эш мөгамәләләренең барысы да Миди тарихы белән йөртелә, бары тик чит илләр белән булган мөнәсәбәтләрдә генә Чит илләр эшләре министрлыгы милади ел исәбен куллана. Мәмләкәтнең үз эчендә ел исәбендә берниндә дә үзгәреш юк.

Ай исәбе японнарда «икенче ай», «өченче ай» рәвешендә йөртелә. Мәсәлән, Нигаҗ, Сангаҗ, Иҗогаҗ һ.б., һ.б.

Көн исемнәре:

Ниҗобей – якшәмбе мәгънәсендә, «кояш көне».

Гиҗобей – дүшәмбе мәгънәсендә, «ай көне».

Кайобей – сишәмбе мәгънәсендә, «ут көне».

Сойобей – чәршәмбе мәгънәсендә, «су көне».

Мокийобей – пәнҗешәмбе мәгънәсендә, «агачлар көне».

Кинобей – җомга мәгънәсендә, «металл/алтын көне».

Дойобей – шимбә мәгънәсендә, «җир/туфрак көне».

Төрекчәдән
***Асия Рәхимова** тәрҗемәсе* ■

ХӨСӘЕН МИРЗА

Борынгы татар тормышыннан трагедия

Фәтхи Бурнаш

Сара, Солтан, Дивана

Солтан. Сара!.. Ул монда нишләп йөри?.. *(Сарага.)* Атаклы мирзаның кызын кайдан монда җил ташлады?

Сара. Син кем буласың? Сине күргәнем бар... алай да...

Солтан. Мин тегермәнче Бикморза картның көрәкчесе Солтан булам.

Сара. Ә, Солтан ага! Минем сиңа зур үтенечем бар...

Солтан. Ни белән мин синең теләгеңне тутыра алырмын икән, хуҗа ханым?

Сара. Син Мусаны күрмәдеңме?

Солтан. Мусаны? Болай иртә таңнан хуҗа ханымның Мусаны эзләп килүенә ышанырга кушасызмы?

Сара. Анысы сиңа кирәк түгел. Күргән булсаң, әйт, миңа Мусаны табарга кирәк.

Солтан. Табарга, дисез...

Сара. Әйе... Ә кирәк булса, мин сиңа аны табып китерергә әмер итә алырмын.

Солтан. А, хуҗа ханым! Нигә шундый кечкенә бер йомышны алай зур итәргә!..

Сара. Син минем сүземне җиргә салырга батырчылык итмәкчесеңме?

Солтан. Хезмәтегездә йөзем белән җир сөрергә хәзермен, хуҗа ханым. Алай да, мин кара кичтән бирле шунда булып Мусаны күрә алмаганымны әйтергә бурычлымын.

Дәвамы. Башы журналның 8 нче (2019) санында.

Сара. Ялганлыйсың!

Солтан. Хода сакласын!

Сара. Миңа аның бу якка таба киткәнен әйттеләр.

Солтан. Кемнәр алар ялган сөйләргә батырчылык иттеләр икән...

Сара. Аны миңа иң ышанычлы кешеләремнән берсе *(Диванага күрсәтеп)*, менә ул әйтте.

Солтан. Ә, дивана! Ха-ха-ха!

Сара. Җитәр! Мин дивана өчен дә синең белән сөйләшә алыр идем, ләкин хәзер вакытым артык санаулы.

Солтан. Мин хуҗа ханым өчен кулдан килгән һәр хезмәткә хәзер.

Сара. Әйдә, Диваначыгым... Мин ышанам, син Мусаны тапмыйча кайтармассың якын дустыңны.

Солтан. Мин хөкем иясе булсам, Сезгә аның белән мондай урыннарда очрашмаска киңәш бирер идем *(Диванины күрсәтә)*.

Сара. Ул минем иң якын дустым һәм ул миңа файдадан башка бернәрсә дә китермәс.

Солтан. Гакылыннан җода булган бер дивана булсадамы?

Сара. Юк, күңеленнән җода булмаганга. Әйдә, Диваначыгым! Әйдә, тизрәк, әйдә! *(Китәләр.)*

Солтан ялгыз

Солтан. Ха-ха-ха! Ул мине чынлап та Бикморзаның көрәкчесе генә диеп уйлады. Шулай, кошлар һавада очалар да, җирдәге бар нәрсәне дә түбән саныйлар...

Ә, әнә теләү намазын бетергәннәр... Монда киләләр.

(Китә, бераздан шаулап халык керә, алдан хәзрәт килә.)

Хәзрәт, халык

Хәзрәт *(туктап)*. Иляһым, бер дога! (*Халык кул күтәрә.)* Иляһым, безнең теләкләребезне кабул кылгай идең!

Халык. Амин!

Хәзрәт. Иляһым, күңелләргә шәфкать салгай идең!

Халык. Амин!

Хәзрәт. Картларның картлык белән, яшьләрнең яшьлек белән, ирләрнең егетлек белән, хатын-кызларның гакылсызлык белән яшерен кылган, әшкәра кылган кечек һәм олуг гөнаһларын ярлыкагай идең!

Халык. Амин!

Хәзрәт. Иляһым, патша хәзрәтләренә аманлык, ватан галиләренә тынычлык, түрәләргә тәдбирлек, илнең хуҗаларына, бәйләренә байлык вә саулык, кара халыкка сабырлык вә түземлек биргәй идең!

Халык. Амин!

Хәзрәт. Байларга тиҗарәт, сәгадәт, фәкыйрьләргә итагать вә дианәт биргәй идең. Амин! Бирахмәтикә йә әрхәмәррахимин! Аллаһы әкбәр!

Халык. Аллаһы әкбәр!

Хәзрәт. Җәмәгать! Бу бәлаләрнең башы үзебездән икәнен аңлагыз. Картларда – гыйбадәт, яшьләрдә – дианәт, хатыннарда хәя һәм итагать беткәнлектән икәнен хәтерләгез. Теләгегез кабул булсын, Хода үзе биргәнне үзе алсын! *(Китә.)*

Халык. Амин! *(Картлар китәләр.)*

Шакир һәм яшьләр

Шакир. Картлар, аман бирегез, яшьләр, монда килегез! Башлардан сулар аксын, учакларда утлар янсын, казаннарда ботка пешсен, туклыкта даннар китсен, савытлардан булар атсын, авызлардан майлар аксын, бездән теләк булсын, йолдызлар сирәк булсын, яңгырлар шау булсын, болытлар чаршау булсын, теләк чын теләк

булсын, кырларда җиләк булсын, игендә ут сирәк булсын, уң кулымда урак булсын, сул кулымда күрәк булсын!

(Егетләр, кызлар чиләкләр белән су ташыйлар, еракта учаклар ягалар, казаннар асалар.)

Халык. Шулай булсын! *(Музыка уйнала, җыр башлана.)*

Җыр

Башлаучылар. Киң басуларда ашлыклар үссен,
Энҗе бөртекләр тулып җитешсен.
Хор. Яңгыр, яу, яу, яу!
Яңгыр, яу, яу, яу!
Кыр, бакчалар җанлансын,
Яфраклары баллансын,
Зәгъфрандай саргайган
Бит алмалар аллансын.
Ай, яңгыр, яу!

Башлаучылар. Кара җир өсте яшел киенсен,
Өсләре матур гөлгә күмелсен.
Хор. Яңгыр, яу, яу, яу!
Яңгыр, яу, яу, яу!
Икмәк үссен кырларда,
Урак булсын кулларда,
Энҗе бөртек сулары
Чылтырап аксын юлларда.
Ай, яңгыр, яу!

Башлаучылар. Ач үлем китсен – кайтсын шат гомер,
Тормыш күгендә шат очсын күңел.
Хор. Яңгыр, яу, яу, яу!
Яңгыр, яу, яу, яу!
Яшь таммасын – чык төшсен,
Кан сармасын – дым төшсен,
Йөз сулары урнына
Җиргә муллык түгелсен!
Ай, яңгыр, яу!

(Муса, Бикморза, Солтан һәм шактый халык керә.)

Муса, Бикморза һәм башкалар

Муса. Туганнар, туктагыз! Сезнең җырларыгыздан башка да безнең колакларыбыз ачлыктан үлүче йөзләрчә мескеннәрнең аяныч авазларыннан тонган.

Шакир. Муса ага! Без ачлыктан киселгән бәгырьләрне бабайларның йолалары белән юарга тырышабыз.

Муса. Сез нәрсәгә монда җыелдыгыз? Сез нәрсә дип йөзләрчә картлар, яшьләрне эсселектән көйгән басуларга чыгардыгыз?

Шакир. Борын-борыннан калган йолалар белән без ачлыкка каршы Алладан мәрхәмәт сорарга теләдек.

Муса. Сез хәзрәтнең догасы белән болытлар кабарыр, дисезме? Башларыгызны сәҗдәдә ию белән күкләрнең йөзләре дымланыр, дисезме?

Бикморза. Ачлыктан кырылган вакытта түгел, туклыктан котырган вакытта да без ул догалардан сукыр бер тиен алганыбыз юк.

1 нче карт. Без соң Алладан башка кемнең ярдәменә таяна алабыз, Муса?

Муса. Дога, бәддогалар белән күңелне юатуның вакыты күптән инде артта калган. Инде

сезнең өстегезгә бернәрсә белән дә хисаплашмый торган ач үлем шәүләсе килеп баскан.

2 нче карт. Дөрес, Муса, мең кат дөрес!

Бикморза. Без инде хәзер очраган бер хәшәрәтне азык итү бусагасына җиткәнбез. Халыкның берсен-берсе ашар дәрәҗәсенә килгәнбез.

Муса. Туганнар! Алай да үлемнән котылуның форсатлары барысы да үтмәгән.

1 нче карт. Инде моңа җиткәч, безне кем коткара алсын!

Муса. Сезне коткара алырлык кеше бар. Ул кеше сездән еракта да түгел.

Халык. Зинһар, әйт әле, кем бар?

Муса. Ул кеше – Хөсәен мирза!

Халык. Хөсәен мирза! Син нәрсә сөйлисең?

Муса. Әйе! Ул гына сезне коткара алачак.

2 нче карт. 37 ел мин аның башмакчысы булып тордым. Менә ике айдан бирле икмәк валчыгы күргәнем юк. Ул миңа аягына егылып сорагач та бер сынык бирмәде.

Бикморза. Син эттән сөяк көткәнсең икән, дивана.

3 нче карт. Минем карчыгым аяктан егылганга кырык көн булды. Кырык тапкыр башмагына башымны куеп сорасам да, ул безгә кырып күзгә салырлык локмә бирмәде.

4 нче карт. Бер гомердә җиде егет үстереп, җидесенә җиде төрле һөнәр өйрәттем. Ул бу ел минем җиденче улымны да сатып, үземне мәчет алдында кул сузып утырырлык хәлгә төшерде. Инде мин шушы каруннан сорыйммы үлем тырнагыннан мине коткаруын?

Муса. Әнә, сез үзегез үк миңа әйтеп бирдегез. Боларның берсе дә дога, сәҗдәләр аша гына алына торган нәрсәләр түгел. Хөсәен мирза да үз ирке белән сезгә бер сынык ярдәм итмәс.

Бикморза. Ә аның бер генә амбары да безнең тирә-якны ачлыктан коткару өчен җитә.

1 нче карт. Бу гаделлек түгел!

2 нче карт. Без моны губернаторга языйк.

3 нче карт. Юк, бу хәлләрне бәйнә-бәйнә сөйләп сенатка прошение языйк.

4 нче карт. Без патшаның үзенә илче җибәрик.

Шакир. Картлар! Туганнар! Безгә сенаттан да, сыйраттан да һичбер нәрсә көтәргә ярамый. Беләсезме, нишлик? Без Хөсәен мирзаның манараларга тиңләгән амбарларына канатлары җилкенеп торган кызыл әтәчләр җибәрик. Аларның кикрикләре һавага күтәрелгән саен, җиргә агылган бөртекләрнең чабулары җәелер. Мир булса мир булсын – хөкем итүче дә, җавап бирүче дә ил булсын!

Муса. Туганнар! Шакирның әйткән сүзләре урынлы. Сезне хәзер бары шундый тәдбирләр генә тормыш юлына алып чыга алыр. Сез моннан да турырак, дөресрәк чара таба алмассыз.

Бикморза. Безне бары шундый юл гына коткара алачак!

Солтан. Җәмәгать! Безгә шул гына, бер генә юл калган.

Халык. Дөрес, бер генә юл!

Бикморза. Без нәрсә күрсәк тә шушы актыккы юлда күрербез. Әкрен, газаплы үлемгә караганда, үзебездән таланган сыныклар өчен көрәшеп үлү мең кат күңеллерәк булыр.

Муса. Безгә бу эшне хәзер үк эшләргә, оста итеп эшләргә, баштанаяк тәртип белән эшләргә кирәк. Бөтен нәрсәдә алдан ук хәзер торып, моның өчен иң каты җавапка очраганда да тимер кебек береккән булырга кирәк.

Халык. Дөрес!

Муса. Һәммәбез бер җан, бер тән булып керешергә, ахырына кадәр алып барырга кирәк.

2 нче карт. Күрсәк, ил белән күрербез.

Солтан. Без барыбыз да бер сүздә булырга ант итәбез.

Халык. Итәбез!

Муса. Бөтен ил һәрберегез өчен, һәрберегез бөтен ил өчен нык торганда гына сез бу эшнең уңышларына очрарсыз. Мин бу эшнең башына куяр өчен Бикморза картны күрсәтер идем.

Халык. Бикморза булсын!

Шакир. Без бөтен яшьләр аның кул астында корбан булырбыз.

Бикморза. Шулай, картлар, яшьләр. Бу эшкә мине баш итәсез икән, Шакирны, Галләмне, Колчураны миңа ярдәмче итеп бирегез. Алар минем тәдбирләремне, әмерләремне тотарлар, башкалар аларның кушуы белән бергәлек эшкә ярдәмгә килерләр.

Халык. Дөрес!

Бикморза. Егетләр! Без хәзер эшне мирзаның тегермән амбарларыннан башларбыз. Алар өчен безгә кызыл әтәчләр дә кирәк булмас. Озак ел тегермәнче булып торуымның ичмаса бер файдасы тисен! Мәгез, алыгыз ачкычларны *(ачкычларны ташлый)*, анда сез бүгенлек кенә икмәк табарсыз. *(Халык, ачкычларны алып, амбарларга чаба.)* Ә без, Шакир, хәзер утарга таба барып карарбыз, әйдәгез!

(Шулвакыт берәү йөгереп керә.)

Берәү. Хөсәен мирза!

Халык. Хөсәен мирза! *(Куркышалар.)*

Муса. Егетләр! Таралмагыз! Мондарак җыелыгыз! Курыкмагыз, чуалышмагыз!

(Хөсәен мирза, капитан-исправник, казаклар керәләр. Казаклар амбарларны, халыкны әйләндереп алалар.)

Хөсәен һәм башкалар

Хөсәен. Менә кайда алар җыйналганнар!

Бикморза. Хуш килдегез, Сөләйман улы Хөсәен!

Хөсәен. А! Әнә сез ничек яңгыр теләве ясыйсыз икән, ә!

Муса. Мирза! Яңгыр теләвен Сез хәзрәт аша үзегез җыйдыргансыз. Нигә аны безгә сылтарга!

Хөсәен. Ә монда җыелырга сезгә кем кушты? Кемнәр амбарларга кереп, ач этләр кебек онга буялганнар? *(Бикморзага.)* Син кырык ел хезмәтең соңында минем бер минутлык ачуыма сусаган идеңме? Әллә сез бу илне ташландык ил диеп уйлаган идегезме?

Капитан *(казакларга)*. Амбарларны бикләп алыгыз, һәммәсен дә камап куегыз!

Хөсәен. Җә, нинди җавап көтәргә кушасыз?

Муса. Сез халыкның далага нәрсә теләп чыкканын аңлагансыз, әмма ни өчен монда җыйналуын аңларга теләмисез ахры...

Хөсәен. Башбаштаклар үзләрен нәрсә көткәнен яхшы белсеннәр!

Муса. Куркытмагыз! Ач үлем тырнагына эләккән кешеләрне тиз генә куркытып булмый аларны. Алар өчен хәзер барыбер. Беләсегез килсә, алар монда үзләренең ач үлемнәрен Сезнең туклыклыгыз белән алмаштыру өчен җыйналганнар.

Хөсәен. Ә... әле шулаймы!

Муса. Әйе, шулай... Алар үлемнән котылуның маякларын утырту өчен җыелганнар.

Хөсәен. Алар өчен миннән этләр үлеме генә булачак.

Бикморза. Оятсыз син, мирза...

Хөсәен. Саклан, Бикморза!

Бикморза. Син әле аларның үлеп бетмәгән булуларын искә алмыйсың... Син этләр үлеме алында торган кешенең үч алуы никадәр каты булуын күз алдыңа китермисең... Без әле күрсәтербез!

Хөсәен. Җитәр, дим мин сиңа!

Капитан. Молчать, мошенник!

Бикморза. Куркытмагыз! Алар барыбер курыкмаслар... Алар үлем кәфенен сезнең үзегезгә киертерләр.

Хөсәен. Алыгыз шул эттән туган этне!

Капитан. Бәйләгез шуның кулларын да, алып китегез!

(Казаклар алмакчы булалар.)

Муса *(аралап)*. Юк! Менә сез иң элек мине алыгыз да аннан соң картны алырсыз.

Хөсәен. Югал каршымнан!

Муса. Сез еллар буенча йөз суларын таптадыгыз – алар түзделәр. Сез балаларны анадан, аталарны баладан аерып, иң түбән хайван урынында йөрттегез – алар чыдадылар. Сез аларны, дворняжкаларга алмаштырып, мыскыл иттегез – алар сабыр иттеләр.

Хөсәен. Тукта, җүнсез малай!

Муса. Юк, туктамыйм!

Хөсәен. Тукта, ләгънәт төшкере!

Муса. Туктамыйм, җир кыскыры! Сез хәзер сарайларда бәйрәм иткәндә, дөньяның хозурлыгыннан гакылларыгыз киткәндә меңнәрчә пот икмәкләрегез өстендә алар ачка үләләр.

Хөсәен. Үләрләр!

Муса. Юк, элек сарайларда утлар сүнәрләр, тук карыннарда майлар кибәрләр, аннан соң гына алар үлсәләр үләрләр...

Хөсәен. Җитәр, дим мин сиңа!

Капитан. Цыц, антихрист!

Муса. Менә, бүген алар нәрсә өчен җыелдылар...

Бикморза. Инде дә аңламадыгызмы?

Хөсәен. Бәйләгез! Икесен дә бәйләгез! Мин сезне иң каты җәзаларга дучар итәрмен... Әҗәлегезне үз кулым белән муеннарыгызга тагармын... (*Бәйлиләр.)*

Халык. Бирмәгез!

Хөсәен. Бәйләгез!

Халык. Бирмәгез, туганнар!

Капитан. Не сметь, мошенниклар!

Хөсәен. Мин сезнең телләрегезне турармын... Күзләрегезне казытып, урыннарына үлем шәмнәре куярмын...

Халык. Бирмәгез!

Муса. Егетләр! Курыкмагыз!

Бикморза. Минем сүзләремнән чыкмагыз!

Хөсәен. Югалтыгыз! *(Казаклар алып китәләр. Сара йөгереп керә дә атасының алдына егыла.)*

Сара һәм башкалар

Сара. Әткәй, син нишләдең?

Хөсәен. Сара!.. Син ничек монда?

Сара. Әткәй... Мин ишетеп килдем... Син мәрхәмәт ит кызың өчен!

Хөсәен. Нәрсә бар сиңа монда?.. Әллә югыйсә...

Сара. Калдыр син аны... аны гына калдыр...

Хөсәен. Син нәрсә сөйлисең?.. Ничек шундый сүзне күтәрә аласың?..

Сара. Мин куркам... Мин аны сөям...

Хөсәен. А! Телең корсын, явыз бала... Син минем дворняжкага алмаштырып алган бер крестьяным турында шулай әйтә аласың!

Сара *(сарылып)*. Әткәй... аны гына...

Хөсәен. Югал күз алдымнан, бәдбәхет! *(Алып ташлый.)* Алыгыз шуны...

(Капитан аптырап тора. Хөсәен чәчләрен уа.)

Пәрдә

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Терраса. Сулда өйгә керә торган ишек. Артта бакча.Пәрдә ачылганда Сара уң якта креслога утырган, тирәсендә кызлар, егетләр. Музыка уйный, җыр дәвам итә.

Җыр.

Башлаучы. Бөдрә талга басып сайрый
Сандугачның назлары.
Кунар урын таба алмыйдыр
Тулган күңлем зарлары.

Хор. Чын сөюдән кемнәр яна
Гүр азабын шул ала.
Йөзеңә баксам, хәсрәт ала,
Биби Сара бичара.

Башлаучы. Таңнар атты, чулпан калкты,
Ак көмештәй нур акты,
Ак таңнардай, сөйгәненә
Чын мәхәббәт кем атты.

Хор. Сөйгән өчен кемнәр яна,
Йөрәген ярып кем сала.
Йөзеңә баксам, хәсрәт ала,
Биби Сара бичара.

Башлаучы. Чылтырап аккан чишмәләрдән
Көянтәләп су алдым.
Көянтәләрдәй бөгелеп,
Хәсрәтеңнән уфтандым.

Хор. Ник сызлана яна-яна
Гөл – чәчкәдәй кыз бала,
Йөзеңә баксам, хәсрәт ала,
Биби Сара бичара.

Сара һәм башкалар

Сара. Кирәкми, җырламагыз сез миңа мондый җырларны. Мин сезгә ничә тапкыр әйттем, сез Иргалине тыңлыйсыз, ә мине тыңламыйсыз...

Хәдичә. Син тынычлан, Сара. Без менә сине тагын урманга, далаларга алып барырбыз. Синең авыруың җиңеләер... Күңелең ачылыр.

Сара. Сез аны бервакытта да ача алмассыз.

1 нче кыз. Әйдәгез, күңеллерәк бер нәрсә җырлыйбыз.

1 нче егет. Юк, әйдәгез, кызлар, биеп бирегез!

Тавышлар. Әйдәгез! Биегез!

(Музыка. Берничә пар кызлар, егетләр төшәләр.
Бераздан сәхнә артында тавыш башлана, Дивананың ыңгырашканы ишетелә.)

Сара. Нинди тавыш бар анда?

2 нче егет. Анда теге Дивана кермәкче булып дау күтәрә бугай.

Сара. Ай, сез аны кертегез... Беләсез бит, ул мине дөньядагы бар нәрсәдән дә артык ярата.

Хәдичә. Сара! Син аны юкка йөртәсең... Ул бит акылында түгел...

Сара. Юк, ул кайчан шундый акыллы сүзләр әйтә – аларны китап читләренә язып куярлык... А, әнә ул... Әйдә, Диваначыгым! *(Дивана керә.)*

Дивана һәм башкалар

Дивана. Канатым, түреңне көмешләп болай
Матурлап койган соң кем эшләп болай?
Боеккан йөзең – ай, җә, нишләп болай?
Сагышлы утыңнан янам мин – Дивана.

Хор. Йөрәгем яна ла... һ.б.

(Кызлар, егетләр бакчага таралалар, хор ерактан ишетелә.)

Сара *(хор арасында).* Мескен Гаскәр ага! Син киләсң дә минем хәлемнән зарланасың. Кирәкми... син минем өчен борчылма. Мин инде авырмыйм... миңа яхшырак...

Син дә кайгырма, Диваначыгым.

Дивана. Моңайдым йөзеңнең зарыннан, кызый.
Зарыкма Дивана сазыннан, кызый.
Сүзең бит риага ягынган, кызый.
Йөрәгең парәсен күрәм мин, Дивана.

Хор. Йөрәгем яна ла..... һ.б.

Сара. Ярый, мин сиңа карышмыйм, Гаскәр ага. Һәр көн иртән син шулай миңа кил дә, мине шатландыр, күңелеңне юат... Ләкин саклан. Син мине артык яратканга күрә атам сине бер дә яратмый...

Дивана. Үзен дә аның мин яратмыйм, бала.
Яратсын мине, дип җан атмыйм, бала.
Җаным зур, залимгә сынатмыйм, бала.
Сиңа тик, канатым, грифтар Дивана.

Хор. Йөрәгем яна ла... Һ.б.

Сара. Кил, утыр син яныма, Диваначыгым. Курыкма, мин сиңа китәргә кушмыйм әле.

Хәдичә. Сара, җаным, әйдә, урманга барыйк. Бераз күңел ачарбыз.

Сара. Урмангамы? Син нәрсә диярсең, Гаскәр ага? Урманда яхшы...

Хәдичә. Әйе... без анда җиләкләр, гөмбәләр җыярбыз. Беркөнге кебек егетләр очраса... үзләрен...

Нәфисә. Шаяртырбыз, ха-ха-ха! Ә кем белә, юлыбыз уңышлы чыкса, үзебезнең егетләр очрап куяр. Аларны бит хәзер якындагы урманнарда йөриләр, дип сөйлиләр.

Сара. Ярый, Хәдичә... барабыз. Урманнар хәзер минем өчен якынрак. Аларның дөм караңгы яланнары да хәзер минем өчен яктырак.

Хәдичә. Алайса, барабыз? Кызлар, кызлар! Әйдәгез, тизрәк,
Савытларыгызны алыгыз, урман авызына чыга торыгыз, без хәзер җитәрбез...

Сара. Син нигә, Диваначыгым, болай боегып карыйсың? (*Җиңелчә көлеп.)* Мин беләм, син ягыз калдырып китүемнән куркасың... Курыкма, мин озакламам... Мин үзем дә сине тиз юксынырмын. Менә *(акча бирә),* син моны үзеңә генә тотарсың.

Дивана. Кирәкми, кирәкми, күралмый күзем –
Ерак куй күземнән сары алтын йөзен,
Малым да, җаным да миңа тик үзең,
Синең зар хәлеңнән йөрәгем яна ла.

Хор. Йөрәгем яна ла... һ.б.

(Дивана урыныннан торып китә башлый.)

Сара. Тукта, Гаскәр ага (*тора, артыннан бара),* син нигә киттең? Юкса миңа ачуландыңмы? Кирәкми, мин сине үзем белән алып барырмын. *(Китәләр. Иргали чыга.)* ■

Кем ул – Карәхмәт?

Фатиһ Кутлу

«Башлыйк әле сүзне Карәхмәт илә,
Яд итәрләр, кем белә, рәхмәт илә».
Г.Тукай



Карәхмәтнең Парижда төшкән фотосы. 1899 ел

Әйе, мәгълүм булганча, Габдулла Тукайның мәшһүр поэмасы «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» шулай башлана. Алга таба бу *мөселман пәһлеван* Диюдән коткаручы батыр булып тасвирлана.

Моннан берничә ел элек әлеге поэманы төрек теленә тәрҗемә иткәндә, бу мөселман пәһлеванның кем икәнлеген беләсе килеп, татар чыганакларына

мөрәҗәгать иттем. Һәм шунда: *«Бу көннәрдә ат кәмитендә көрәшергә Карәхмәт исемле бер төрек килде. Буның килүе Казан халкының милли хисләрен ни дәрәҗәгә ирештергәнлегене тәүсыйф кылып (тасвирлап) бетерергә мөмкин түгел», – дигән юлларга юлыктым («Яшен журналы». 1908. 2 нче сан. 10 сентябрь)*[1]. Әлеге юлларны укыгач, төрек кешесе буларак, бик зур горурлык хисләре кичердем һәм эчтән генә: «Тукайның иң атаклы поэмасының коткаручы каһарманы төрек милләтеннән булган! Көрәшчебез Карәхмәтне татар әдәбиятында мәңгеләштергәне өчен рәхмәтләр яусын Тукайга!», – дип, күпме вакыт сөенеп-куанып йөрдем. Яшерен-батырын түгел, үзебезнең тарихта Карәхмәт исемле төрек көрәшчесе булуын Тукайның «Печән базары...»ннан белдем. Аннары төрек чыганакларыннан Карәхмәтне өйрәнә башладым. Төркиядә 2006 елда дөнья күргән «Җиһан чемпионы Кара Аһмәт» исемле тарихи романга да тап булдым. Авторы – Һалиль Дәлиҗә. 459 битлек саллы әсәр. Әлеге романны таптырып, Казандагы Тукай музеена бүләк итәсем килде. Анда махсус Карәхмәт почмагы булдырылган. Музейга менә дигән бүләк булыр, дип уйлап куйдым. Бу роман шул көнәрдә табылды һәм минем кулыма керде, шөкер!



Карәхмәт турындагы романның тышлыгы

Язмамда башта сезне кыскача булса да төрек чыганакларындагы Карәхмәт белән (төрекчә – Кара Аһмәт) таныштырырга булдым.

Ул Госманлы дәүләте чорында хәзерге Болгариянең Дәли Орман (Лудогория) өлкәсендәге Омур бәй авылында 1870 елда дөньяга килгән. Гомеренең иң уңышлы көрәшләрен Франциядә һәм Русиядә үткәргән.

Карәхмәт 1897 елда остазы Һәргәләҗи Ибраһим белән беренче тапкыр Аурупага бара һәм анда үзе катнашкан барлык көрәшләрдә дә җиңә. 1899 елда, XX гасырга керү уңаеннан Парижда үткәрелгән олы ярминкәгә мөнәсәбәтле рәвештә беренче тапкыр үткәрелгән «Бөтендөнья грек-рим көрәше чемпионаты»нда катнаша. Анда дөньяга танылган иң оста көрәшчеләрне бер-бер артлы җиңә һәм шул рәвешле дөнья чемпионы исемен яулый. Истанбулга кайткач, ул солтан 2 нче Габделхәмит тарафыннан Госманлы ордены белән бүләкләнә[2].

Карәхмәт тәүге тапкыр үткәрелгән әлеге бәйгедә финалда француз көрәшчесе

---

[1] Габдулла Тукай. Әсәрләр. – Академик басма. Алты томда. 1 том. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2011. – 385-386 бит.
[2] https://tr.wikipedia.org/wiki/Kara_Ahmed

Карәхмәт кабере. Истанбул шәһәре, Әйүп районы

Laurent Le Beaucairois белән бил алыша. Карәхмәт гәүдәгә әллә ни зур түгел, буе – 180 см. Авырлыгы 105 кг булса да көндәшләрен егуы белән халыкны шаккатыра. Ә француз көрәшчесе Laurent Le Beaucairoisның авырлыгы исә 138 кг була. Карәхмәт, финалда әлеге көндәшен җиңеп, 1899 елда бөтен дөнья күләмендә рәсми рәвештә тәүге тапкыр үткәрелгән бәйгедә дөнья чемпионы исемен яулаган беренче төрек була[3].

Ә хәзер Казанда басылып чыккан «Габдулла Тукай энциклопедиясе»нең 518 нче битендәге «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» дигән аңлатмада Карәхмәт турындагы юлларга күз ташлыйк: «*...1870 елда төрекләргә буйсынган Болгариядә туган, 1899 елда Франциядәге ярышларда дөнья чемпионы исемен яулаган реаль көрәшче Карәхмәт илә урыннарын алмашалар*»[4]. Ике мәгълүмат та бер-берсенә тәңгәл килә, хилафлык юк.

Хөрмәтле укучы! Язмамның иң хикмәтле ноктасына килеп җиттек.

«Яшен» журналында язылганча, Карәхмәт Казанга 1908 елда килә. Тукай да «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасын шул ук елны яза. Ә чынлыкта исә 1899 елда Франциядә дөнья чемпионы булган төрек пәһлеваны Карәхмәт 1902 елда 32 яшендә авырып вафат була! Кабере – Истанбулның Әйүп районы зиратында[5]. Чыннан да дөрес укыдыгыз. Бу мәгълүмат дөресме икән, дип, булган чыганакларны тикшереп чыктым. Әйе, Карәхмәт 1902 елның 24 маенда утырган җирендә кисәк кенә йөрәк өянәгеннән җан тәслим кыла[6]. Хак! Дөнья чемпионы Карәхмәт 1902 елда вафат! Күңелем тулысы белән канәгать булсын өчен, кабереңең фоторәсемен эзләдем. Әйүп район хакимияте тарафыннан каберенә эленгән такталы фотоны тапкач, бу хакта минем күңелемдә бернинди шик-шөбһә калмады. Болай булгач, 1899 елда Парижда дөнья чемпионы исемен яулаган төрек пәһлеваны Карәхмәтнең 1908 елда Казанга килүе мөмкин хәл түгел! Моннан чыгып, ул елларда Карәхмәт исемле тагын

[3] Әмрә Гүл-Дөнья бүльтәне – Тарих досъясы – Икъдам газетасы (1894-1928 нче елларда Истанбулда көндәлек басылып чыккан гыйльми, сәяси газета). – Номерлар – 1983, 1987, 1990.
[4] Габдулла Тукай энциклопедиясе. – Казан: 2016.
[5] https://tr.wikipedia.org/wiki/Kara_Ahmed
[6] «Гәнч» журналы, 2008. Февраль, 17 нче сан. – Ибраһим Рәфик язмасы.

«Яшен» журналы тышлыгы һәм Карәхмәт турында хәбәр. №2 (Сентябрь, 1908)



تیمر بای حاجیغه اچق خط.

حاجی افندی، سین قزاندن چیتك بولغانغه کوره قزانده‌غی واقعه‌لرنی، خلق آراسنده‌غی فکرلرنی، عمومی اشلرده‌گی حرکتلرنی بله‌سك کیله طورغاندر.

مونه، شونك اوچون مین سیگا همان بر آز خبرلر یازوب طورماقچی بولام.

بو کونلرده قزانغه آت که‌میتنك کوره‌شورگه قارا احمد اسملی کوره‌شچی بر ترك کیلدی. بونك کیلووی قزان خلقینك ملی حسلرینی نی درجه‌گه ایرشدرگانلگینی توصیف قیلوب بتررگه ممکن توگل. هرکم قارا احمدگه خدادن قوّت تلی. حتی کوب کشیلر نماز آرتندن‌ده بونك اوچون دعا قیلالر. هم تیز کونك، دعالقلر باصدرا طورغان بر کتاب شرکتی اوز مطبعه‌لرنده «قارا احمد دعاسی» دیگان بر دعاده باصدراچق ایمش. حاضرچه‌ن بازارنك، مسجدلرده‌ده بونك اوچون دعا قیلونی ملالردن اوتنو اوچون بر کاغزگه قول قویدروب

бер төрек көрәшчесе булмадымы икән, дип эзләнә башладым. Ә татарча чыганакта бу кеше хакында: «Циркта французча көрәшеп йөргән»[7], – дигән юллар да бар. Дөнья чемпионы Карәхмәт тә грек-рим стилендә, ягъни французча көрәшүче пәһлеван булган. Исеме дә, көрәш стиле дә ничек туры килергә мөмкин, дидем үзалдыма. Шуннан, безнең дөнья чемпионы Карәхмәт Казанга килгәнме, юкмы, дип, югарыда телгә алган, Тукай музеена бүләк итәргә дип китерткән Карәхмәт турындагы романны актара башладым, чөнки тарихи чыганакларга нигезләнеп язылган романда дөнья чемпионы Карәхмәтнең чит илдә кайсы шәһәрләрдә кемнәр белән ничә мәртәбә көрәшкәнлеге хакында бәйнә-бәйнә язылган.

Мәсәлән, ул 1896 елның азакларында Варшава, Мәскәү, Санкт-Петербургта узган көрәшләрдә катнашкан. Петербургтагы Чинизелли циркында Һакеншмидт белән бил алышкан. 1897 елның февралендә Истанбулга кайткан[8]. 1900 елның гыйнвар аеның урталарыннан азагына кадәр Парижда легендар рус көрәшчесе Пытлясинский белән өч мәртәбә көрәшкәнлеге, көрәшләрнең ничек барганлыгы турында ул вакыттагы матубагатта чыккан мәгълүматлар белән баетылып бирелгән[9].

Әмма Карәхмәтнең Казанга килгәнлеге турында бер мәгълүмат та юк. Шулай ук башка җирләрдә дә очрамый. Була да алмый. Икенче яктан караганда, Габдулла Тукай Карәхмәт образын һавадан алмаган, уйдырма кеше түгел ул. «Яшен» журналында чыккан хәбәр ялган була алмый, анысы да факт. Моны куәтләп, Гыйльметдин Шәрәф истәлекләрендә: *«Шул вакытлар (1908 нче сәнә, сентябрь) Казанда Никитин циркына көрәшчеләр килә. Башка батырлар арасында Карәхмәт исемле бер мөселман пәһлеваны да килеп, циркташы батырларны егып, Печән базары халкын шаулата. Җитмәсә, Карәхмәт, Болгар номерларына төшеп, Тукайдан берничә номер аркылы тора башлый.*

[7] Габдулла Тукай. Әсәрләр. Академик басма. Алты томда. 1 том. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2011. – 385 бит.
[8] «Cihan Şampiyonu Kara Ahmet» Роман. Авторы – Һалил Дәлиҗә. Нәшрият исеме – «Бабыали Культур Йайынҗылыгы(БКЙ). – 241-243 бит. 2 басма. Гыйнвар. 2009. Истанбул.
[9] «Cihan Şampiyonu Kara Ahmet». Роман. Авторы – Һалил Дәлиҗә. Нәшрият исеме – «Бабыали Культур Йайынсылыгы(БКЙ). – 2 басма. Истанбул. Гыйнвар, 2009. 327-336 бит.

Карәхмәтнең гадәти киемнән төшкән фотосы

Биек, юан, фәсле Карәхмәтне Тукай коридорда беренче мәртәбә очратып: «Карәхмәтне күрдем...» – дип көлеп сөйләве исемдә[10].

Гыйльметдин Шәрәф Карәхмәт турында: «*Биек, юан, фәсле*», – ди. Тукай да, аны куәтләп:

«Шунда бардыр бер мөселман пәһлеван –
Бик озын, бик көчле, гайрәтле җиван», –

дип яза.

Ә тарихтагы дөнья чемпионы Карәхмәтнең буе 180 см, авырлыгы 105 кг булган[11]. Көрәшче өчен әллә ни зур гәүдә түгел бу. Чын Карәхмәт алып гәүдәле булмаган. Икенчедән, дөнья чемпионы чын Карәхмәтнең фәс киеп йөрүе, фәсле булуы икеле. Моның сәбәбен аңлатыр өчен, фәс турында кыскача гына мәгълүмат бирергә туры килә. Госманлы солтаны 2 нче Мәхмүт вакытында сарайда аурупача киенү модасы китә. Ул елларда Фастан (Мароккодан) фәс баш киеме кайта. Патшаның фәрман-боерыгы белән, 1840 елда хәрбиләр униформаларының баш киеме фәс була. Истанбулда хәрбиләр һәм дәүләт хезмәткәрләре 1925 елга кадәр фәс киеп йөргәннәр. Чалманы галимнәр һәм дин әһелләре генә урап йөргән ул елларда. Истанбулдан читтәге халык күпчелек чалма урап йөргән[12]. Фәс киеп йөрү аурупалашу галәмәте булган. Шуңа күрә, фәсне төрекнең милли киеме дип атау бик үк дөрес тә түгел. Монысы сүз уңаеннан гына булды. Аннары Карәхмәтнең милли киемнән төшкән чалмалы фотосы да бар. Ә ул еллардагы төрек көрәшчеләренең фәсле фотосы юк, һәммәсе дә чалмалы.

Шуннан соң мин Никитин циркында көрәшеп йөрүче Карәхмәт дип бирелгән көрәшченең берәр фоторәсемен табып булмасмы, дип, эшкә керештем. Чөнки төрек чыганакларында дөнья чемпионы төрек Карәхмәтнең үз вакытында төшерелгән фотолары бар. Алар белән моны чагыштырып карыйсым килде.

Беренче адым итеп, Милли китапханәнең сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегенә бардым. Тукай хезмәтләрендә астөшермә белән бирелгән, 1908 елның сентябрь аенда басылган «Яшен» журналының 2 нче санын эзләргә тотындым. Укучыларга мәгълүмат булсын өчен әйтеп узасым килә: «Яшен» журналы рәсемле, иллюстрацияләр белән чыга торган журнал булган. Карәхмәтнең дә берәр рәсеме булуы бик ихимал, дип, эшкә керештем. «Бәхет»емә, «Яшен»нең 1, 3, 4 нче саннары бар, ә 2 нче саны юк! Менә сиңа мә! Башка журналларны да актарып чыктым, тапмадым. Хәзер нишләргә? Хезмәткәрләр миңа Лобачевский исемендәге университет китапханәсенең сирәк кулъязмалар фондына барырга киңәш иттеләр. Икенче көнне

---

[10] Тукай турында замандашлары. – Казан: Татарстан китап нәшрияты. 1960. – Гыйльметдин Шәрәф./ Тукай турында истә калганнар. – 101 бит.
[11] https://www.dunyabulteni.net/tarihten-olaylar/pehlivanlar-pehlivani-kara-ahmed-h287660.html
[12] https://tr.wikipedia.org/wiki/Fes_.

Рәссам Госман Арслановның (1897-1941) «Габдулла Тукай шигырьләре»нә ясаган ике рәсеме. 1926 ел

шунда кердем. «Яшен» журналының 2 нче саны бар, дигәч, бик сөендем! Берәр фоторәсем эзләп, 16 битлек журналның сәхифәләрен актара башладым. Юк, Карәхмәтнең фотосы юк! Шуннан Тукай хезмәтләрендә астөшермә белән бирелгән хәбәрнең оригиналын эзләргә тотындым һәм шуны икенче биттә көчкә-көчкә таптым. Моның сәбәбе – хәбәр эре, калын хәрефләр белән бирелмәүдә. Санлы (цифровой) вариантын махсус сорап алдым. (Тукай җыентыкларында бу хәбәрнең ничәнче биттә булуы күрсәтелмәгән). Һәм анда тагын бернәрсә ачтым – әлеге астөшермәләрдә: *«Бу көннәрдә ат кәмитендә көрәшергә*

Безнең мирас №10 октябрь 2019

Среда, 17 сентября 1908 г. № 4658 годъ XVI-й. № 4658 Среда 17 сентября 1908

КАЗАНСКІЙ ТЕЛЕГРАФЪ.

ГАЗЕТА
ПОЛИТИЧЕСКАЯ, ОБЩЕСТВЕННАЯ, ЛИТЕРАТУРНАЯ и КОММЕРЧЕСКАЯ.
Выходитъ ЕЖЕДНЕВНО, за исключеніемъ дней послѣпраздничныхъ.

КАРТИНЪ. 3—20 к., для учащихся и дѣтей: 1 мѣсто 30 к., 2—20 к., дѣти 10 к. 11042 8м

ТУРЬ ДЕ-БРА

Циркъ бр. Никитиныхъ

Въ среду, 17 сентября дано будетъ большое экстренное представленіе

въ пользу Казанскаго общества Вольной Пожарной Дружины.

Программа представленія составлена изъ лучшихъ номеровъ циркового репертуара, лучшихъ европейскихъ артистовъ и артистокъ при участіи вновь прибывшихъ артистовъ изъ Н.-Новгорода, во главѣ знаменитыхъ летающихъ людей тріо Дехертсъ. А также состоится продолженіе международнаго чемпіоната французской борьбы на призъ 3000 фран., золотыя и серебряныя медали. 1-я фран. борьба знаменит. турокъ Кара-Ахметъ и Матюшенко 2-я борьба Гриша Кащеевъ и Грангаузъ. 3-я борьба Медвѣдевъ и Чернецкій. 4-я борьба Заикинъ и Мартыновъ. Парадный выходъ всѣхъ борцовъ и борьба состоится въ 3-мъ отдѣленіи около 10½ ч. веч. Анонсъ. Готовится бенефисъ Волжскаго богатыря И. М. Заикина.

«Казанский телеграф». 17 сентябрь, 1908 ел (№4658)

Карәхмәт исемле бер төрек килде», – диелгән. Ә журналдагы төп нөсхәдә: «*Карәхмәт исемле көрәшче бер төрек килде»,* – диелә. Бик мөһим булган «көрәшче» сүзе төшеп калган икән һәм алга таба китапларда шулай кулланылышка кереп киткән.

Шуннан 1908 елдагы татар газеталарында берәр фоторәсем табылмасмы, дип эзләргә тотындым. Ни кызганыч, тапмадым. Аның каравы, 2016 елда Казанда чыккан «Тукайга сәяхәт» исемле китапның 314-316 нчы битләрендә рәссам Госман Арслановның (1897-1941) 1926 елда басылган «Габдулла Тукай шигырьләре»нә ясалган Карәхмәтнең ике рәсемен таптым. Госман Арсланов әлеге ике рәсемне истәлекләргә таянып ясагандыр, мөгаен. Ә ул рәсемнәрдәге Карәхмәт белән дөнья чемпионы Карәхмәт бер-берсенә охшамаганнар. Госман Арсланов рәсемендә, аерма буларак, Карәхмәткә, фәстән башка, пиджак-костюм да кидерелгән. Ул елларда мондый кием Госманлы дәүләте хезмәткәрләрендә генә булырга мөмкин, көрәшчеләрдә, халыкта андый киенү рәвеше юк.

Никитин циркында көрәшкән Карәхмәт дип бирелгән көрәшченең фотосын тагын кайдан эзләргә! Тукай буенча белгеч, хөрмәтле галим Җәүдәт абый Миңнуллинга шалтыратып, бу хакта киңәш-табыш сорадым. Ул сүзен: «Бу – өйрәнелмәгән тема, – дип башлады һәм болай дәвам итте: – Ул вакыттагы урыс гәҗитләрендә фотосы булмадымы икән? «Казанский телеграф» һәм «Камско-Волжская речь»не карарга кирәк булыр. Аннары ул вакытта цирклар көрәшченең сурәте белән афиша бастырган булганнар. Ә Никитиннарның нәселләре – Түбән Новгородта. Аннан эзләсәң генә. Аларда булуы да бик икеле».

Чыннан да, бик яхшы фикер бу! Рәхмәт яусын Җәүдәт абыйга! Мин шунда ук интернеттан Никитин циркы турында мәгълүмат эзләргә керештем. Баксаң, Казан циркына 1890 елда нигез салучылар Никитиннар икән. Ул башта Черек күлдә урнашкан булган. Шушы мәгълүматны белгәч, тукта әле, циркның архивында Карәхмәт турында берәр нәрсә табылмасмы, дип Казан циркына шалтыратып, гозеремне әйттем. Татарча бик матур сөйләштек. Телефон номерымны язып алдылар да, без сезгә шалтыратырбыз, диделәр. Икенче көнне «ватсаб»ыма бер-бер артлы фотолар килә башлады. Алар Җәүдәт абый телгә алган «Казанский телеграф» гәҗитенең 1908 елның 17 сентябрендә чыккан 4658 нче санынннан алынган иде. Шатлыгымнан нишләргә дә

Үз вакытында төрек матбугатында Карәхмәт турында язмалар һәм фотолар күп басылган

белмәдем! Анда Карәхмәтнең фотосы булмаса да, аның хакындагы юлларны теркәп китәм: «*А также состоится продолжение международного чемпионата французской борьбы на 3000 фран., золотыя и серебряныя медаль. 1-я фран. борьба знаменит турком Кара-Ахметь и Матюшенко*.

Нинди приз, суммасы һәм Карәхмәтнең кем белән көрәшәчәгенә хәтле бәйнә-бәйнә язылган! Бу хәбәрдән тыш, циркның директоры миңа үзем дә тапкан төрек чыганакларындагы дөнья чемпионы Карәхмәтнең фотоларын да салган. Димәк, архивларында болар гына бар. Шундук циркның директорына шалтыратып, миңа булышканнары, шушы бик кадерле мәгълүматны җибәргәннәре өчен мең-мең рәхмәт әйттем. Өстәп: «Ә афиша сакланмаганмы?» – дип сорадым. Директор циркның башта Черек күлдә төзелгәнлеге, соңыннан бинаның янганлыгы турында әйтте. Ни кызганыч, афишасы сакланмаган икән! Миңа бик нык булышканнары өчен, Казан циркы дирекциясенә ихлас рәхмәтемне белдерәм!

Башта әйтеп үткәнебезчә, 1899 елда Франциядә дөнья чемпионы булган һәм 1902 елда дөньядан киткән Карәхмәт 1908 елда Казанга берничек тә килә алмый. Ә Никитин циркында халыкка төрек пәһлеваны Карәхмәт дип танытылган ул кеше кем булган? Башыма мондый бер уй килә: циркның хуҗасы Никитин, күпләп акча эшләр өчен, мөселманнарның милли хисләреннән һәм дөньяга танылган Карәхмәтнең даныннан файдаланып, ул көрәшчене Карәхмәт дип танытып, башына дә фәс кидереп көрәштермәдеме икән? Әлеге шигемне куәтләп, *«Мөселман пәһлеван» турындагы аңлатмада мондый юллар бар: «Мөселман батыр»ның «кяфир батыр» белән көрәшүе Казандагы татарларны аеруча кызыксындырган. Цирк хуҗасы Никитин, үзенең керемен күбәйтү өчен, бу хәлдән бик оста файдаланган. Печән базары татарлары күпләп-күпләп циркка йөри башлыйлар. Яңа чыга башлаган «Яшен» журналы бу вакыйганы сатира угы астына ала»*[13].

Әйе, 1902 елда вафат булган дөнья чемпионы, төрек көрәшчесе Карәхмәтнең 1908 елда Никитин циркында көрәшкән кеше булмавы ачык билгеле. Ә Печән базары халкына Карәхмәт дип танытылган әлеге көрәшче кем булган?

Ни кызганыч, минем «Җиһан чемпионы Кара Аһмәт» исемле романны Тукай музеена тапшыру хыялым шул рәвешле чынга ашмый калды... ■

[13] Габдулла Тукай. Әсәрләр. – Академик басма. Алты томда. 1 том. – Казан: Татарстан китап нәшрияты. 2011. – 385 бит.

«ТАТМЕДИА» республика матбугат
һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы
Татарстан китап нәшрияты,
«Безнең мирас» журналы редакциясе

ТАССРНЫҢ ҺӘМ ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫНЫҢ 100 ЕЛЛЫКЛАРЫНА БАГЫШЛАП, «ХӘТЕРГӘ УЕЛГАН КИТАП» ИСЕМЛЕ КОНКУРС ИГЪЛАН ИТӘ

КОНКУРСНЫҢ МАКСАТЫ – татар китап мирасын пропагандалау, республикабызда телләрне саклау һәм үстерү, яңа авторларны табу, алар белән хезмәттәшлек итү.

Конкурс 2019 елның 1 апреленнән 2019 елның 15 декабренә кадәр үткәрелә.

Конкурска үзегез бик тә яратып укыган, тормышыгызда мөһим роль уйнаган, хәтергә уелып калган яки сез «өстәл китабы» буларак файдалана торган китап турында татар телендә язылган очерк, эссе, мәкалә кабул ителә. Күләме А4 форматында 12 нче кегельдә 2 биттән дә артмаска тиеш.

Конкурста катнашучылар үзләренең эшләрен «Безнең мирас» журналына 2019 елның 2 нче ярты еллыгына яки 2020 елның 1 нче ярты еллыгына язылу турындагы квитанция фотосын (скан вариантын) беркетеп, yanamiras@mail.ru электрон почтасы адресына «КОНКУРСКА» дигән сүз белән җибәрергә тиеш.

Конкурска юлланган эшләр Татарстан китап нәшриятының генераль директоры һәм «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире раслаган жюри әгъзалары тарафыннан бәяләнеп, җиңүчеләр 2019 елның 1 декабрендә игълан ителә.

Җиңүчеләргә акчалата премияләр, Татарстан китап нәшриятыннан китап алу өчен сертификатлар, «Безнең мирас» журналы редакциясеннән конкурста призлы урын алучыларга сертификат һәм барлык катнашучыларга дипломнар биреләчәк.

Барлык материаллар да «Безнең мирас» журналында яки http://beznenmiras.ru/ сайтында басылачак.

Конкурс турындагы мәгълүмат **http://beznenmiras.ru/** сайтына урнаштырыла.

Безнең мирас №10 октябрь 2019

ГОМӘР БӘШИРОВ
көндәлегеннән[1]

САРА САДЫЙКОВА (1906-1986)

Сара Садыйкова Мәскәү консерваториясендә укыган чакта. 1924 ел

Сара Садыйковада булдым. Үзе куллама пешерде, чәй эчтек. Аның бер күзенә күптән түгел операция ясаганнар иде, һәйбәт кенә төзәлеп килә. Аның яше шактый ук инде, әмма күңеле күтәренке, төшенкелеккә бирелми. Өе (ягъни бүлмәләре) бик пакь, идәнендә бер чүп күрсә, хәзер тезләнеп чүпләп ала. <...>

1983, 23 гыйнвар

Дәвамы. Башы журналның 8 нче (2019) санында.

[1] Бәширов Г.Б. Күңел дәфтәре: көндәлек язмалар [төзүчесе, кулъязмаларны һәм искәрмәләрне әзерләүчесе Зөфәр Бәширов]. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2011. – 464 б.

Сара Садыйкова. 1984

Бу арада композитор Сара Садыйкованың сәламәтлеге бик борчый. Соңгы айларда ул берничә мәртәбә шифаханәгә кереп чыкты. Аны эченә операция ясарга дип салалар да, операцияне күтәрерлек хәле булмагач, яңадан өенә кайтаралар. Мин аны моннан ике-өч ай күргәндә үк ул бик ябыккан иде инде, хәзер исә нибары 38 килога калган.

Күптән түгел телефоннан хәлен сораштым. «Аппетитым юк, ашыйсым килми, хәлем дә юк, һавага чыга алмыйм», – дип зарланды. Әмма җай килдеме, авыруы хакында сөйләшүне ташлап, иҗат эшләренә күчә.

Г.Тукайның 100 еллыгы уңае белән аның кайбер шигырьләренә музыка язган икән. Әмма үзе канәгать түгел, бик аз яздым, алар гына җитми, менә тагын байтак шигырьләренә көй язасым бар әле, вакыт юк, өй эчендәге эшләр кулымны тота, шуларга вакыт әрәм була, ди.

Әгәр дә Сара каты авырып китсә, ул сәнгать дөньясы өчен бик аяныч хәл булачак. Халыкка иң якын торган композитор инде ул.

1986, 21 февраль

Кичә кич Сара ханым белән телефоннан сөйләштем. Урын хастасы булмадымы икән, хәле авыр түгелме икән, дип борчылган идем, шөкер, сөйләшүенә, тавышының көрлегенә караганда, андый мөшкел хәлгә төшмәгән икән әле. Билгеле, ул авыру, белгән кешеләрнең әйтүенә караганда, ул инде нибары 30 кило гына калган. Минем белән сөйләшкән саен, ул аңа шифаханәдән өенә чыгып, тәмлерәк ашап, тазарырга киңәш итүләре хакында сөйли. Аңа, шулай тазарып кергәннән соң, май-июнь айларында операция ясарга тиешләр икән... Ярый әле кеше үзенең язмышын алдан белеп тормый. Юкса аңа яшәве бик кыен булыр иде... Ул Сара ханым кебек дәртләнеп, үз эшенә үзе куанып, соңгы айларда язган әсәрләренә шатланып сөйли алмас иде.

– Беләсеңме, мин, авыру булсам да, һаман да эшлим бит әле. Соңгы айларда гына Г.Тукай шигырьләренә, башка шагыйрьләр җырларына көйләр яздым. Бер шигыренә шундый көй яздым, аны еламыйча бер кеше дә тыңлый алмаячак. Кайберләрен Хәйдәр Бигичев, кайсыберсен аның хатыны Зөһрә Сәхәбиева алды.

Сара ханым шундый оптимистка, сөйләшә торгач, аның шундый рухи халәте сиңа да тәэсир итә дә, «әллә авыруы чын түгелме икән, бәлки, табиблар ялгышалардыр», дип уйлый башлыйсың. Табиблар ялгышса, Сара ханымда андый авыру булмаса, барыбыз өчен дә бик зур шатлык булыр иде сана. Ләкин... ай-һай.

Гомәр Бәширов белән Сара Садыйкова. 1984 ел

Моны шул сәбәпле әйтәм: Сара ханым үзенең уникаль талант икәнлеген әллә ничә мәртәбәләр раслады. Әгәр Сәйдәш белән Нәҗип Җиһанов булмаса, Сара ханым татар совет композиторларыннан иң мәшһүр кеше булып саналыр иде. Болай да ул иң популяр композитор булып танылды. Халык күңелен аның кадәр оста һәм әтрафлы итеп музыкада әйтеп бирүче хәзергә юк әле, дисәм, шәт, ялгыш булмас. Билгеле, бу әле Н.Җиһанов кебек зур талантларны инкяр итү түгел. Аларның амплуасы, музыкада тоткан урыны башка. Сара ханым – җырлар остасы, музыкада кечерәк формалар маһире. Җыр, романс һ.б. шундый кечкенә жанрлар – менә аның стихиясе. Бу өлкәдә аның дәрәҗәсенә беркемнең дә менеп җитә алганы юк. Яшь композиторлар арасында аның иҗат юнәлешен дәвам итәргә сәләтле булган талант хәзергә күренмичәрәк тора. Андый көч әллә була моннан соң, әллә юк. Сара ханым кебек көчле талант булу өчен, элекке моңнарны белергә кирәк. Хәзерге яшьләр исә хәзергене яхшы белсә дә, элеккене белми, шул сәбәпле, алар халык моңы белән сугарылган яңа көйләр яза да алмыйлар.

Бик кирәк безгә Сара ханымның сәламәтлеге, бик тә кирәк.

Әмма ул авыру. Үзенең авыруы никадәр куркыныч булуын ул үзе белми. Бәлки, белсә дә, сиздерми торгандыр. <...>

1986, 20 март

Сара ханымның вафаты[2] миңа (хәер, миңа гына түгел) бик авыр тәэсир итте. Ул хакта хәтта менә бу дәфтәргә язарга да күңелем бармады. Ул бик сирәк очрый торган гаҗәп бер талант иде. Ләкин аның кадерен белмәделәр, кайбер композиторлар хәтта аның популярлыгыннан көнләштеләр, аңа кырын карадылар. Шул сәбәпле, ул партия учетында да, Композиторлар союзында да түгел, Язучылар союзы каршысындагы партия оешмасында торды.

Август аенда «Казан утлары» журналының баш редакторы миннән Сара Садыйкованың 80 еллыгына мәкалә язуымны үтенде. Мин аны яздым, һич көчәнергә туры килмәде, мәкалә, ничектер, үзеннән-үзе язылды. Сәбәбе билгеле, Сара ханым зур талант иясе һәм яхшы күңелле, халыкка хезмәт итүне үзенең төп вазыйфасы итеп танучы кеше иде. <...>

1986, 3 ноябрь ■

[2] Сара Гариф кызы Садыйкова 1986 елның 7 июнендә Казанда бакыйлыкка күчә. – **Редакция.**

Безнең мирас №10 октябрь 2019

Бер рәсем тарихы

Әхтәм Зарипов

Рәсемдә (сулдан уңга): Шәүкәт Биктимиров, Равил Гайнетдин, Әхтәм Зарипов һәм Гали Ильясов.
Рөстәм Нәбиуллин фотосы. 1973 нче еллар

ССРның халык артисты Шәүкәт абый Биктимиров, телевидение тапшыруларында катнашырга сирәк ризалашса да, килгән чакларында онытылмаслык хатирәләр калдыра иде.

Әлеге фотода (диктор Рөстәм Нәбиуллин фотога төшерде) аның телевизион тапшыруга кермәгән кызыклы хәлләрне хәтерләп утырган чагы.

...Сирәк булса да, Кырымга ял итәргә барган чакларында ул, «Кырым күчтәнәче», дип, диңгез ярында тапкан төсле таш кисәкләрен, әкәм-төкәм кабырчыкларын җыеп кайтып, безгә тарата иде. Миндә берничәсе хәзер дә саклана әле.

Бу юлы ул күренекле артистлардан ишеткән театр мәзәкләре, анекдотлар язып кайткан иде. Эфирга чыгуны көткән буш арада, шулар белән таныштырып, көлдереп утыруы хәтердә.

Һәр мәзәкнең кем авызыннан ишеткәнен дә әйткән иде. Күбесе онытылган.

Сабакташыбыз «Малый театр» артисты Филлипов сөйләгән мәзәк: «Кайсыдыр бер спектакльдән соң тамашачылар белән очрашуда үзен «драматург» дип таныштыручы берәү Игорь Ильинскийга сорау бирә:

– Бүген трагедия, комедия, водевиль бер-берсеннән нәрсә белән аерыла?

Ильинский:

– Җавап сезнең соравыгызда ята: шуны белмәвегез – водевиль материалы. Монда утырган тамашачыларга – комедия, ә сезнең үзегез өчен – трагедия. Талант йөген күтәрмәсә дә, шуңа дәгъва итүче бу драматург: «Вольтерны укыгач, мин трагедия язуны ташлап, комедияләр яза башладым», – ди.

– Алайса, синең әле Мольерны укыганың юк, – ди аңа Ильинский...

Кемнән ишетүе хәтердә сакланмаган мәзәк җөмләләр:

Амплуа – режиссерның артистны бер сыйфатта гына уйнатуы.

Антракт – тамашачының: «Театрда калыргамы, кайтып китәргәме?» – дигән сорауга җавап эзләү вакыты.

Вариант – пьеса сәхнәдә куелганнан соң калган «хәрабәләр».

Интрига – сәхнәдә персонажлар, ә сәхнә артында артистлар арасындагы мөгамәлә.

Рецензия – тәнкыйтьче фикеренчә, әсәрнең кыскача эчтәлеге (яхшы дигәне).

Тәнкыйтьче – режиссерларга, завлитларга ничек итеп драматургларга пьесадан баш тартырга өйрәтүче инструктор.

Күренекле артистның дәфтәрендә мондый мәзәкләр күп иде. Бәлки ул аларны кемгәдер биргәндер? Бирмәгән булса, архивында ятадыр? Шәүкәт абыйның үзе белән булган бер мәзәк: «Ялтада ял итеп ятканда төрле шуклыклар уйлап чыгарырга яраткан Жук дигән Ленинград театралы «Пляжная красавица» дигән конкурс оештыра. Мине дә жюри составына кертә. Чибәрләрнең һәркайсына катыргыга язылган номер бирелә. Комиссия әгъзалары шул номерлардан үзенә иң охшаганын раслаган язу бирергә тиеш иде. Без – жюри әгъзалары – иң карт дигәннәрдән өчәү идек. Кичке ашка кадәр фикерләребезне рәисебез Жукка бирергә тиешбез. Көн эссе. Хатын-кызларның күбесе диңгездә су коена. Кояшта кызынып ятканнары битләрен шул номерлы катыргы белән каплаган, кайберләренең номерлары күкрәгендә, яисә кендектән түбәндәрәктә ята. Ә бер ханым капланып яткан да аркасын кыздыра, номеры гәүдәсеннән ике-өч адым читтә аунап ята. Ул җиденче номер иде. Кичке ашка җыйналгач, жюри әгъзаларының икесенең дә кәгазьләре буш – йөрмәгәннәр, язмаганнар. Мин язганча, алар да «7» санын гына язып куйды. Нәтиҗәдә, иң күп очко җыйган «7» нче сан (хуҗабикәсе) булды.

Жюри рәисе Жук миңа сүз бирә:

– Телдән әйтегез – ни өчен «7» нче номерга салдыгыз? – ди.

Мин дөресен әйттем:

– Чөнки миңа аннан да гүзәлрәк хатын очрамады. Минем Рәмзиям – пляжда гына түгел, дөньяда бер гүзәл, – дидем.

Кунакханәгә кайткач, мин шуны аңладым: Рәмзия апагыз номерлы катыргының нигә бирелүен дә аңламаган икән. «Гомер буе кеше көлдердең», – дип, миңа үпкә саклады. Бу миңа юморны аңламаган кеше белән шаярырга ярамый, дигән нәтиҗәгә килерлек сабак булды».

Мәрхүм Шәүкәт абый, төрле шуклыклар ясарга яратса да, үзе кыен хәлләргә калганда үпкәли дә, ачу саклый да белми иде.

Урыннары оҗмахта булсын! ■

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНЕҢ ОЕШУЫНА 85 ЕЛ

Шәриф Камал (икенче рәттә уңнан өченче) татар зыялылары белән. Оренбург. 1925 ел

Сурәтле хатирә

Шигъри митинг. Рәсемдә (уңнан сулга): Әхмәт Исхак (чыгыш ясый, аның артында Мөхәммәт Садри, Әмирхан Еники һәм Зөлфәт), Нури Арслан, Галимҗан Латыйп. 1970 нче еллар

Татарстан Язучылар берлегенең чираттагы җыелышы. Рәсемдә: алгы рәттә (сулдан) – Мөхәммәт Садри, Мәхмүт Хөсәен, Нури Арслан. 1980 нче еллар уртасы. Фәрит Гобәев фотосы

Истәлеккә – бер кадр (сулдан уңга): Әхмәт Рәшит, Айрат Арсланов, Разил Вәлиев, Харрас Әюпов һәм Мәдинә Маликова. 2000 нче еллар башы

*Фотолар **Л.Лерон** архивыннан алынды.* ■

МӘКТӘПЛӘР ҺӘМ САБАКТАШЛАР

Ләбиб Лерон

Барысы да истә, хәтердә кебек. Олыгая барган саен, авылны, мәктәпне, сыйныфташларны, укытучыларны ныграк сагынасың икән...

Әле 1983 елда ук, университетның дүртенче курсында укыган чакта, авылны сагынып, «Җирсү» дигән шигырь язган идем:

Авыл дәшә. Дәшә дә бит...
Вакытны булмый кысып, –
Тузан суырткычтай йота
Кала ыгы-зыгысы.

Тишек кесәдән коелган
Бакыр акчалар кебек,
Чылтырап коела көннәр, –
Алып булмый иелеп.

Юкса, әле кайчан гына
Авылдан киткәнемә?!
Баксаң, шактый бушый төшкән
Хәтер төенчеге дә.

Юк, каладан алай минем
Зарлануым түгел лә!..
Кайчак миңа трамвайлар
Атлар булып күренә...

Шуңа мәллә, төшкә түгел,
Өнгә керә Олыйман:
Кала буйлап авыл өе
Эзләп йөргән тиле мин!

Олыгаябыз... Башлангыч мәктәптә бергә укыган сыйныфташларым инде берәмберәм бакыйлыкка күчеп бара: Илһар Вәлиев, Фәндәвис Шәйхетдинов, Мәрвә Әһлиева, Индус Хәйретдинов... Сыйныфташым Азатның әтисе, фронтовик-укытучы Шәрип абый Каюмовның, шулай ук бала һәм үсмер чагымда яшәешемә, хәл-халәтемә, холык-

Беренче укытучым Ания апа Әбүярова белән. 2019

Дәвамы. Башы журналның 8 нче (2019) санында.

фигылемә азмы-күпме йогынты ясаган авылдашларым – әбием Мофаккирә ягыннан безгә туган тиешле Габит абый Галиев, Асия җиңгәмнең абыйлары Фангел һәм Фидәкәр Сәләховлар, Гыйбадулла Заһидуллин (сыйныфташым Рәмиләнең әтисе), Мирхаҗиян Әюпов, Әхәт Бәхтиев, Имам Шәйхуллин, Мирза Әхмәтов (сыйныфташым Рәфинәнең әтисе), Зәкәрия Фазуллин, балачак дустым Әбүзәрнең әтисе Әхсән Әюпов (шагыйрь Харрас Әюпов белән бик якын туганнар), Фарсый Фатыйхов (сыйныфташым Рәсхәтнең әтисе), аталы-уллы Галим һәм Рафаил Каһировлар, Госман, Җәмил (без үскәндә авыл мулласы иде), Мирзашәех (авыл халкы «Мирзәкәй» дип кенә йөртте), Фазлый, Гомәр, Рамазан бабайлар, ирле-хатынлы Лена һәм Мөдәррис Әһәзовлар, Флүр Шакиров, Нияз Кәшфиев, Зөлфәт Исламов һәм Мәних, Муфакки, Дөлфәт, Фәнтимер, Зәкәр, Габдулла, Мирзәрип абыйларның да Мәңгелек йортка күчкәненә шактый еллар узды... Барысының да урыннары җәннәттәдер, шәт!

...Быел 2 сентябрьдә Олы Имәндә булган чакта, форсаттан файдаланып, янә беренче укытучымның хәл-әхвәлен белешеп чыктым. 86 яшьлек Ания апа Әбүярова балаларының, кияү-киленнәренең һәм оныкларының тәрбиясендә бик рәхәтләнеп яшәп ятуы турында кабат искәртеп әйтте. Җитәкчеләргә, авылдашларга бик рәхмәтле ул. Саубуллашкан чакта: «Илкөнебез тыныч, күгебез аяз булсын!» – диде укытучым...

Сыйныфташым Илһар Вәлиев

Сыйныфташым Индус Хәйретдинов

ТӘКМӘК АВЫЛЫ. СЫЙНЫФТАШЛАР

Балачактан бер вакыйга истә калган.

Олы Имән башлангыч мәктәбендә укыган чак. Беркөнне: «Югары Яхшый авылына Казаннан Курчак театры килгән икән», – дигән хәбәр ишеттек. Берничә малай (сыйныфташларым Илһар, Мөнир дип исемдә калган) киттек курчаклар уенын карарга. Җәяүләп, әлбәттә. Олы Имән белән Югары Яхшый арасы – биш чакрым чамасы. Курчаклы тамашаны моңарчы беребезнең дә караганы юк. «Нинди була икән ул Курчак театры дигәннәре, курчаклар ничек сөйләшә икән?» – дип, үзара бәхәсләшә-гәпләшә барабыз очынып. Юлыбыз Тәкмәк авылы аша уза. Авылга керүгә, сагаебрак атлый башладык. Ят авыл бит, бераз шөлләтә (кем очрамас, кем килеп чыкмас, янәсе). Үзебездән

Безнең урам кызлары: алда – әнием Шәргыяның бертуган энесе Рөстәмнең олы кызы Ләлә, икенче рәттә сулдан – Айзирәк (сыйныфташ), Халидә, Рәфинә (сыйныфташ), Фәндәрия, Рәмилә (сыйныфташ)

олырак малайлар очраса, шүрләгәнебезне сиздермәскә кирәк, дип, кызу-кызу атларга тырышабыз. Менә бервакыт буйлары безнеке чамасы булган ике малай, әллә каян гына калкып чыкты да, янәшәбездән теркелди башлады. Сөйләшмиләр, безгә күз кырые белән генә караштыргалап, атлый бирәләр. Авылның уртасына җитәрәк, безнең түземлек төкәнде.

– Яхшыйга Курчак театры килгән. Без шунда барабыз! – дидем мин.

– Без дә! – диде Тәкмәк малайлары.

Янә авызга су каптык. Сөйләшми генә барабыз. Кинәт Мөнир:

– Минем Җәүдәт абыйның солдат каешы бар... Аелы ялтырап тора! – дип әйтеп куйды.

Шул сүзләрне генә көткәндәй, Тәкмәк малайлары кабат телгә килде:

– Минем ике абыемның да солдат каешы бар! – диде берсе.

– Минем абый юк, аның каравы, әтинең каешы бар! – диде малайларның икенчесе.

Илһарның да, минем дә абыйлар юк. Мөнирнең генә ул әллә ничә абыйсы бар. Абыйларсыз Илһар үзен ничек хис иткәндер ул вакытта, белмим, әмма миңа кыен булып китте. Шулчак мин, әле генә флоттан кайткан күршебез Илфак абыйны искә төшереп, ярып салдым:

– Безнең күршедә генә Илфак абый яши. Аның да каешы бар. Ул – моряк! – дидем.

Кыскасы, абыйларыбыз һәм аларның каешлары белән мактанып бара торгач, Югары Яхшыйга килеп җиткәнебезне сизми дә калдык...

Безнең белән бергә курчаклар уенын карарга барган әлеге Тәкмәк малайларының чынлыкта кемнәр булуы, ни кызганыч, хәтеремдә калмаган.

Ул көнне исә без «Дутан батыр» дигән әкияти тамаша карадык. Әлеге әкият-пьесаның авторы драматург һәм режиссер Сәлах Хөсни (1912-1974) икәнен мин соңыннан белдем, әлбәттә. Сүз уңаеннан әйтеп үтим, Сәлах Хөснинең улы Роберт абый Казандагы Ш.Мәрҗани исемендәге 2 нче гимназиядә ике кызымны – Айсылу белән Ләйләне – тарихтан, Роберт абыйның кызы Фиалка (Миләүшә) исә Айсылуны алгебрадан укытты...

Ошбу урында сыйныфташым Зиннур Бәдретдиновның Тәкмәк башлангыч мәктәбендә укыган чагын исенә төшереп сөйләгәннәреннән бер өзекне сезнең дә игътибарга җиткерим әле: *«Тәкмәктә беренче һәм икенче класста безне Әминә апа Хуҗина укытты. Яңа мәктәптә уку насыйп булды безгә. Хәтерлим әле, кышкы салкын көннәрдә, бураннарда, зур шәлләргә төреп, чанага төяп, безне мәктәпкә әти-әниләр илтә иде. Бер вакыйга аеруча истә калган. Кояшлы, җылы май азаклары. Беренче классны тәмамлаган*

чак. Соңгы дәрес беткәч, ындыр артлап өйгә кайтырга чыктык. Радик Ситдыйков әйтә: «Әйдә, ручкаларны, карандашларны сындырабыз, хәзер бер нәмәгә дә кирәкмәй алар», – ди. Тотындык сындырырга: каләм-карандаш та, ручкалар да, санау таякчыклары да калмады – барысын да чәчеп бетердек, китапларны, дәфтәрләрне ертып ташладык. Өйгә кайткач, безгә бик каты эләкте инде, әлбәттә...»

Сыйныфташым Зиннур Бәдретдинов

Озакламый без – Олый Имән башлангыч мәктәбенең өченче сыйныфын тәмамлаган балалар, тәкмәклеләр белән бергә, Югары Яхшыйда укый башладык. «А» һәм «Б»га бүленгән ике сыйныфка без биш авылдан (Югары Яхшый, Түбән Яхшый, Олы Имән, Тәкмәк, Наратлы (элек Мәчти исемен йөртә иде, хәзер бу авыл юк инде)) җыелган идек. Тәкмәктән килеп, безнең белән шушы укучылар укыды: Сәвия Әмирова, Нурания Гыймазетдинова, Роберт Заһиров, Әгъләметдин Зиннәтуллин, Фирдәвис Имамов, Салават Нәгыймов, Илһам Нәҗмиев, Гөлфая Нуретдинова, Равилә Хәбирова, Фазыл Һашимов...»

Сыйныфташлар (сулдан уңга): Азат Каюмов, Зиннур Бәдретдинов, Ленарис Гыйльфанов (Ләбиб Лерон) Бишенче сыйныфта укыган чак. Беренче рәттә (сулдан): Вера Сәлахова, Дәнирә Нигъматуллина, Рәфинә Әхмәтова, Рәмилә Заһидуллина, Мәрвә Әһлиева, Мөнирә Ганиева, Айзирәк Хәтимова, Нурия Гарифуллина, Дилүсә Шәвәлиева, Нәфисә Солтанова; икенче рәттә: Фазыл Һашимов, Ленарис Гыйльфанов (Ләбиб Лерон), Илдар Саматов, Мөнир Әһлиев, Флүс Нургалиев, Данир Сафин, Илһам Әмирҗанов; өченче рәттә: Дәбир Нәгыймов, Азат Каюмов, Илһар Вәлиев, Азат Вәлиев, Рәдиф Нажаров, Альберт Җиһангиров. 1973 ел

*Фотолар **Ләбиб Лерон** архивыннан алынды.* ■

Истә, һаман да истә!

Шагыйрь Әхмәт Саттарның тууына 80 ел

Шагыйрь, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (2011), М.Ломоносов һәм Һ.Такташ исемендәге әдәби премияләр лауреаты Әхмәт Саттар улы Саттаров 1939 (кайбер чыганакларда 1935 дип язылган) елның 17 октябрендә Түбән Новгород өлкәсенең Сергач районындагы Кочки-Пожарки авылында туган.

Ә.Саттар 1963-1972 елларда Мәскәү Кремлендә дәүләт җитәкчеләрен, чит ил кунакларын, төрле рәсми делегацияләрне аш-су белән тәэмин итүче махсус төркемдә өлкән метродотель булып эшли. Шунда эшләгән чагын ул үзенең «Метродотель язмалары» дигән истәлекләр китабында мавыктыргыч итеп сурәтли.

Ә.Саттарның төрле елларда «Закон колодца» (1989), «Җырлар» (1999), «Прощай, XX век» (2002), «Избранное» (2009), «Робагыйлар» (2015) дигән китаплары дөнья күрә. Аның кайбер шигырьләренә композитор Рөстәм Яхин тарафыннан романслар язылган.

Ә.Саттар 2003 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы иде.

Шагыйрь 2018 елның 16 июнендә Анапада вафат булды. Җәсәде туган авылы зиратында җирләнде.

Журналист-тәнкыйтьче Лотфи Гаделнең тууына 125 ел

Хикәяләр авторы, журналист-тәнкыйтьче Лотфи (Лотфулла) Карибулла улы Гаделев 1894 елның 22 октябрендә (1 ноябрь) Вятка губернасына караган Алабуга өязендәге Салагыш авылында (хәзерге Әгерҗе районына керә) туган.

«Бубый» мәдрәсәсен тәмамлагач, 1911 елда Казандагы Мөгаллимнәр мәктәбенә укырга керә.

Беренче Бөтендөнья сугышы башлангач, үз теләге белән фронтка китә һәм якынча 1915 елда һәлак була.

Язган әсәрләре: «Көнчелек» (1913), «Аерылышу» (1914), «Ике хат» (1914), тәрҗемә мәсьәләләре һәм Г.Тукай иҗаты турындагы язмалар.

Артист Гали Надрюковның тууына 110 ел

Актер, ТАССРның халык (1967), РСФСРның атказанган артисты (1976) Гали (Мингали) Ислам улы Надрюков 1909 елның 25 октябрендә хәзерге Чиләбе өлкәсенең Варна районындагы Варна авылында туган.

1927 елда ул Троицк татар театрында эшли башлый.

1931-1933 елларда – Свердловскида Урал татар эшче театрында, 1935-1936

елларда – Әстерхан татар театрында, 1936 елдан Татар академия театрында хезмәт куя.

Бөек Ватан сугышында катнаша.

Г.Надрюков 1989 елның 24 ноябрендә Казанда вафат булды.

Уйнаган рольләре: Севастьянов – «Безнең шәһәрнең егете» (Константин Симонов); Ниязов – «Дәүләт Бәдриев» (Газиз Иделле); Харитонов – «Диңгездәгеләр өчен» (Борис Лавренёв); Осип – «Ревизор» (Николай Гоголь); Галәви – «Зәңгәр шәл» (Кәрим Тинчурин); Орлов – «Мулланур Вахитов» (Нәкый Исәнбәт); Җиһангир – «Хуҗа Насретдин» (Нәкый Исәнбәт); Шәүлихан – «Ташкыннар» (Таҗи Гыйззәт); Җамалетдин – «Банкрот» (Галиәсгар Камал); Бардин – «Дошманнар» (Максим Горький); Аманҗолов – «Гүзәлем Әсәл» (Чыңгыз Айтматов); Дәүләтбай – «Кыз урлау» (Мостай Кәрим); Госман – «Күк капусы ачылса» (Хәй Вахит) һ.б.

Баянчы, композитор Марс Макаровның тууына 80 ел

Баянчы, композитор, виртуоз музыкант, мөгаллим, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1987) Марс Андрей улы Макаров 1939 елның 28 октябрендә ТАССРның Биләр районындагы (хәзерге Нурлат) Чурабатыр авылында туган.

1953 елда ул Казанга килә һәм 26 нчы татар мәктәбендә укый башлый. 1962 елда Казан музыка училищесын (баян классын) тәмамлый.

1962-1968 елларда – Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә баянчы, 1968-1977 елларда – Татар дәүләт филармониясендә, 1977-1978 елларда – Башкорт дәүләт филармониясендә, 1978-1982 елларда – Татар дәүләт опера һәм балет театрының концерт төркемендә концертмейстер вазыйфасын башкара. 1982 елдан исә 18 нче Казан сәнгать мәктәбендә эшли.

М.Макаров – 200дән артык җыр һәм романс («Агыла да болыт агыла», «Ай чыга Арча кырыннан», «Юксындырсаң, нишләрмен», «Кара шәле килә сөйрәлеп», «Көмеш тояк – тулпар атым», «Татарстан таңнары», «Мәк чәчәге», «Төнбоеклар», «Язгы ташу» һ.б.) авторы. Иң беренче язган җыры – «Киек казлар» (Х.Туфан шигыре, 1964).

1968 елда бер төркем сәнгать әһелләре (И.Шакиров, Р.Яхин, А.Арсланов, В.Шәрипова, М.Әхмәтов) белән Финляндиядә була һәм президент Урхо Кекконен белән очраша.

2011 елда «Сәнгатебез йолдызлары» дигән китабы дөнья күрә.

М.Макаров 2016 елның 16 мартында вафат булды.

Сәхифәне ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №10 октябрь 2019

НӘДЕР, ГАЛИ АБЫЙ, МИНГАЛИ ИСЛАМОВИЧ...

Әхтәм Зарипов

Замандашлары аны «Нәдер», дип, фиркалеләр «Мингали Исламович», без – яшьрәкләр исә «Гали абый» дип йөри идек. Мин белә башлаганнан бирле, аның, партком секретаре, худсовет әгъзасы булып, театрның яшәешендәге мәсьәләләрне чишкәндә хәлиткеч сүз әйткәнлегеннән тәкрарлый алам. Ул Ватан сугышының башыннан ахырынача, рядовой булып, илне азат итүдә катнашкан, орден-медальләргә лаек булган кызылармеец иде. Чын фронтовик. Чын сугышчы.

...Мингали Ислам улы хәзерге Чиләбе өлкәсенең Варна авылында туып үскән, шундагы мәктәптә башлангыч белем алып, үзешчәннәр түгәрәкләрендә күңеленә театрда эшләү, артист булу уе сеңдергән тәвәккәл егет була.

Солдат хезмәтенә чакырылганчы үзешчәннәр түгәрәкләрендә төрле рольләр уйнап, солдат хезмәтеннән кайткач, Троицкидагы профессиональ театрга эшкә алына. Ә 1931 елдан 1933 елга кадәр Свердловск шәһәрендәге Урал өлкә театрының татар-башкорт бүлегендә артист була. 1933 елдан 1934 елга кадәр Чистай театрында эшли. Шунысы игътибарга лаек, аны русча куелган спектакльләргә дә, татарча спектакльләргә дә, «колоритный роль»ләргә артист кирәк булганда режиссерлар үзләре чакырып алалар. Ә 1934 елда, Троицк театрында бергә эшләгән талантлы артист Бари Тарханов тәкъдиме белән, Мингали Надрюков Академия театрына чакырыла. Сугышта булган елларын санамаганда, үзенчәлекле артист бөтен гомерен Академия театрында иҗат итүгә багышлый. Аның без – щепкинчылар театрга кайтып эшли башлаганчы катнашкан спектакльләре, башкарган рольләре турында хезмәттәше Халит Кумысников тарафыннан язылган мәкаләләрдә артист иҗатына тәфсилле тикшерү – анализ ясалып, бәһа бирелә. Без исә аның катнашында куелган кайбер спектакльләр буенча гына фикер йөртеп, үз тәэсирләребезне яза алабыз. Андый спектакльләрнең берсе – Мостай Кәрим әсәре буенча куелган «Кыз урлау». Бу спектакльдә ул хатынсыз калган Дәүләтбай ролен башкарды. «Башкарды» дигән сүзем очраклы түгел. Гали абый нинди рольгә алынса да, ул аны уйнамый, ә шул персонаж буларак башкара. Аның «Кыз урлау»дагы Туктабикә артыннан кияүләп йөрүләренә уен итеп түгел, ә чын итеп карамый мөмкин түгел иде. Һәр сүзгә ышана торган, беркатлы Дәүләтбай бүген дә хәтеремдә юмарт холыклы, мәрхәмәтле кеше булып яңара. Үз кирелеге аркасында җиңелеп хурлыкка калган «Усман Галиевич» ролендә Гали абый күзгә бәрелеп тормаган әсәрләрдә дә кеше карап гыйбрәт алырлык образ тудыру мөмкин булуын күрсәтте.

Аның белән «Татар хатыны ниләр күрми» спектаклендә бергә уйнавым истәлекле. Мал бүлешү күренеше бара. Ата малын бүлешергә малайлары җыелышкан. Гали абый – өлкән улы, мин – Фәсхи ролендә – уртанчысы. Һәркайсыбыз үзенә нинди мал кирәген әйтергә

Сәнгать советы әгъзалары. Сулдан: Х.Уразиков, Г.Шамуков, М.Миңлебаева, Г.Нигъмәтуллина, Ф.Халитов. Басканнар: Х.Сәлимҗанов, Г.Зыятдинов, Г.Надрюков. 1965 ел

тиеш. Фәсхинең чираты җиткән икән. Ә ул дәшми – утыра тамашачыларга карап. Сәхнә өчен кирәкле вакыт уза – Фәсхи һаман да дәшми. Башка артистлар башлыйлар. Ә Фәсхигә «хоть бы что». Шунда олы туган Гали абый: «Фәсхи!» – дип кычкыра. Аптырауданмы, куркуданмы, тамаша залы «чымырдап» ала. Мин шунда гына уянып киткәндәй булам һәм: «Башмак минеке», – дим. Мал өчен көрәш дәвам итә. Спектакльдән соң Гали абый, нәзакәтле генә итеп, ни булуын сорады. Мин аңа беренче мәхәббәтемнең әни ягыннан туганым белән миңа хыянәт итүен, ул туганымны да алдалап, Сәмәрканд кешесенә кияүгә чыгуын, шул ире безнең спектакльне карап утыруларын сөйләдем. Гали абый тыңлап утырдымы, уйланып утырдымы – дәшмәде. Ә икенче көнне иртән очрашкач, көтмәгәндә-уйламаганда: «Син ул кәнтәй белән очрашмавыңа шатланырга гына тиешсең. Аңа өйләнгән булсаң да, ул нәфесенә хуҗа була алмас кәнтәй булыр иде», – диде.

Шулай да, аны бик тә күрәсем килүне әйткәч, Гали абый мине шәһәр карарга – экскурсиягә чакырды, шуннан соң гына «хыянәтчеңне эзләрсең», диде. Ризалаштым.

Биби-ханым мәчетен караганда әллә көлеп, әллә башка уйлардан: «Синең хатыныңа атап мәчет салдыру мәшәкатең юк», – дип әйтеп куйды. Регистанны карадык, ә Гүр-Әмирдә очраган саилчеләргә хәер өләшкәненә аптырап торуымны күргәч: «Сине коммунист кешенең хәер бирүе гаҗәпләндерде. Мин алардан дога көтмәдем бит, хәеремне алып, баласы кулындагы савытка салуын гына күрәсем килде», – диде. Дөресен әйтим – бу сәяхәттән соң минем хыянәтчел беренче мәхәббәтемне күрәсе килү теләгем калмады. Шулай җайлап кына, үзенең өстенлеген алга куймыйча гына, ялгыш адым ясарга омтылучыларны «акылга утырту» сәләте бар иде Гали абыйның.

Партиягә керү өчен рекомендация сорап мөрәҗәгать иткәч, икенче бер өлкән халык артисты: «Син әле коммунист булырга өлгермәгән», – диде. Ах-зарымны, рәнҗүемне белдерергә партком секретаре Гали абыйга килдем. Ул сораулар бирми генә тыңлады да миңа: «Дөрес эшләгән, сиңа әлегә анда керергә кирәкми. Өч бала үстерәсең, өч эштә эшлисең, фатир көтәсең. Безнең сафта эшсезләр җитәрлек. Син – эш кешесе, иҗат кешесе. Вакыты җиткәч, үзем рекомендация бирермен», – диде. Шулай мин, фиркасез генә эшләп, «перестройка» чорына җиттем. Ә Гали абый ул фирканең үзе таралуын күрмәде шикелле, ягъни ул чорларны күрми китәргә «ашыкты».

Театрдан китмәсә дә, анда эшләми башлагач, мин аны телевидение йомышлары белән барганда Крутушка шифаханәсендә очрата идем. Казансу елгасы буенда, Зәңгәр күл тирәсендәге урманнарда йөрергә ярата иде ул.

1975 елда, улларымның күңелен күрәм, дип, хатыным ризалыгыннан башка «Прогресс-4» дигән моторлы көймә-катер сатып алдым. Кредитка, әлбәттә. Хатыным белән кызым Крутушкада ялда. Мактанасы килеп, ике улым белән, катерны күрсәтергә, Казан су буйлап, Крутушкага менәргә булдык. Бездән дә бәхетле кеше юктыр кебек тоелган мизгелләрне күз алдына китерәсездер: «Җәй. Челлә, кечкенә булса да үз «парахутыбыз». Катерны нәкъ санаторий янында туктатып, чылбырын бикләдем дә, башта санаторий янындагы пионер лагерена – кызымны күрергә киттем. Палаткалары буш. «Урманга яки су буена киткәннәрдер», – диде әйберләр саклап калган тәрбияче кыз. Вакытны әрәм итми, санаторий администрациясеннән хатынымның кайсы бинада булуын белергә килсәм, аның, стандарт урыннар җитмәү сәбәпле, аерым бер агач йортта булуын әйттеләр. Агач икән – агач, үзем агач булмаска тиешлектән киттем стандартсыз йортны эзләп. Бер катлы, алтыпочмаклы ярым җимерек бина икән. Йортның бер ягында – 4 ир, икенче ягында 3 хатын яши. Минем хатын анда юк иде, бүлмәдәшенең берсе «процедурададыр», дигәч, икенчесе, минем хатын постеленә карап: «Ул процедурасында булды инде, су буенда яисә урмандадыр, покрывалосын алган», – диде. Бу сүзләрне ишеткәндә, мин инде яртылаш үлгән идем. Шулай да: «Урманга кем белән кереп китте?» – дип сорарга көчем җитте. «Кем белән?» дигәнгә җавап алырга бүлмәдәш ханымның берсе домино «бәреп» утыручы өч иргә: «Дүртенчегез кая?» – дигәч, өч ирнең яшьрәге: «Аның каялыгын сезнең өченчегез генә белсә-белә инде», – диде киная белән. Кинаясез дә миңа инде яшәү мөмкинлеге калмаган иде: «Йә – үзем бетәм, йә – аларны бетерәм», дигән гөнаһлы уй белән урманга өстерәлдем. Кирәк бит, урман сукмагында Гали абый Надрюков очрады. «Көнгә 8 чакрымны, обязательно, җәяү йөрим, 2 мәртәбә су коенам», – ди ул миңа, шатлык әйткәндәй. Мин – телсез. Аны хуплый да, нидер сорый да алмыйм. «Син дә ялдамы, әллә телевидение эшләре беләнме?» – диде ул, бераз баргач.

Мин катер алуымны, ике улым белән монда ял итүче хатыным белән кызымны күрергә килеп, хатынымның ниндидер бер ир белән урманга кереп китүен аңлатырга тырыштым. Аңлагандырмы хәлемне, юкмы, Гали абый миңа, бик кискен һәм әмер биргәндәй:

– Урманга кереп киткән хатынны табам, дип урманны яндырсаң да таба алмаячаксың. Алар утта янмый, суда батмый. Язу калдыр да, бар, юлыңда бул. Үзеңнән көлдереп йөрмә! – диде.

– Балаларга ни дип әйтергә? Алар бит: «Әни кая?» – дип сораячаклар...

– «Әти кая?» – дип сораганда хатының җавап таба ич, син дә тап. Әйдә, борыл, катерыңны күрсәт.

Катер карарга дип биек ярдан аска карасак, хатыным өч бала белән, чирәмгә җәймә җәеп, нидер ашап утыра (салат чоры иде).

Бу – кешегә сөйләргә ярамый торган серемне Гали абыйга сөйләвемнән минем чамадан тыш көнчел булуымны күреп, өлкән артистның кеше хәленә керә белүе, аны дөрес юлга бастырырга тырышуы мактауга лаек икәне аңлашылса иде. Рәхмәт аңа.

Гали абый белән соңгы күрешүем шушы буласын сизенсәм, мин әле аны гаиләм янына чакырып, катерда да йөртеп хозурландырган булыр идем. Ул 8 чакрым җәяү йөрергә дигән нормасын тутырырга ашыкты. Ә мин Гали абый ярдәмендә сакланып калган түгәрәк гаиләм янына төштем. Хатыным безнең катерның мотор тавышын әллә каян ук ишетеп, кайда тукталуыбызны карап торган икән.

Шушы урында мин дә тукталып, хатирәләрем Гали абыйга дога булып ирешсен иде, дип теләп калам. ■

БОРЫНГЫ ТАТАР МИЛЛИ МУЗЫКА УЕН КОРАЛЛАРЫ

Ринат Гыйләҗев,
«Сорнай» фольклор ансамбленең сәнгать җитәкчесе

ТАЛЬЯН ГАРМУН

Халык музыка уен коралы гармунның тарихы әллә ни зур түгел. Аны, беренчеләрдән булып, 1822 елда Берлин мастеры Хр.Ф.Бушман эшләгән. Ул гармунның уң ягында – биш тел, сул ягында ике тел булган. Ә, Бушман нигез итеп Кытай халкының борынгы «Шэн» дигән музыка коралын файдаланган. Өреп уйный торган әлеге коралда тавыш хасил итүче бамбуктан эшләнгән планкалар бар. Шулай итеп, гармунның тарихы Кытайга – Азиягә барып тоташа. Шул елларда Вена шәһәрендә яшәүче К.Демиян исемле оста да гармуннар ясый. Ул беренче тапкыр гармунның сул ягына әзер аккордлар куя. Ауропада тиз арада бу эшкә танылган орган ясаучы Ф.Киршман, Ф.Кауфман, И.Мельцель кебек осталар да алыналар.

Россиядә беренче гармуннар 1830 нчы елларда күренә башлый. Гармун Ауропадан, ниндидер юллар белән, Русиянең төрле төбәкләренә килеп керә. Аның Россиягә кайчан һәм ничек эләгүе төгәл билгеле түгел. Озак еллар Германиядә тоткынлыкта булган рус һәм татар әсирләре гармунны бирегә алып кайткан булырга да мөмкиннәр.

19 йөзнең азакларыннан башлап, Тула шәһәре үзенең гармун ясау осталары белән дан тота. Бер Тула остасыннан: «Син бу һөнәргә каян өйрәндең?» – дип сорыйлар. Ә ул: «Әти миңа Мәкәрҗә ярминкәсеннән гармун алып кайтып бирде, шуны сүтеп ясарга өйрәндем», – дип җавап бирә. Шул елларда Русиянең төрле төбәкләрендә бер үк вакытта гармунның бер-берсенә охшамаган Ливенка, Елецкий, Вятский, Венский, Черепашка, Саратов, Касимовский һ.б. төрләре барлыкка килә. 1890 нчы елларда Тула шәһәрендә беренче тапкыр хромка гармунын ясыйлар. Хромкадан соң, Русиядә – баян, Австриядә аккордеон ясала.

Ни хикмәт, тарих өчен кыска гына вакыт эчендә гармунны халык бик тиз үз итә. Ул, Германия, Австрия чикләрен үтеп, бөтен дөньяга тарала. Гармун, һичшиксез, дөнья мәдәниятенә яңа юнәлеш алып килгән. Яшьләр аны бик тиз күтәреп алалар һәм ул күп кенә милли уен коралларын кысрыклап чыгаруга да сәбәпче була. Шуңа да, шул чорның күренекле шәхесләре гармунның тиз таралуына борчылганнар. Бөек урыс җырчысы Ф.Шаляпин: «Бу халыкка ни булды, белгән җырын онытып, гармун тартып такмак әйтүгә күчте», – дип офтана. Танылган татар композиторы

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2019) санында.

С.Габәши дә гармунны татар тормышына керттермәскә тырышкан. Бәлки алар хаклы да булганнардыр. Әмма инде бу вакытта халыкны гармунсыз күз алдына да китереп булмый. 1990-2000 елларда нәкъ шундый ук хәл синтезаторлар белән дә кабатланды.

1850 нче елларда Вятка губернасында гармун ясау эше бик җанланып китә. Россиянең башка төбәкләрендә эшләнелгән гармуннарның уң якта урнашкан телләре күрекне тартканда – бер, япканда икенче төрле яңгырый. Ә Вятка гармунының уң як телләре күрекне ачканда да, япканда да бер үк тавыш чыгара. Бу система беренче тапкыр Вятка гармуннарында кулланыла.

Татар гармунының тарихы Михаил Вараксин исеме белән бәйле. XIX гасыр азакларында бу кеше, Вятка губернасыннан алып килеп, Казанда гармуннар сата башлый. Соңрак алар гаиләләре белән Казанга күчеп киләләр. Вараксинның ике улы да гомер буе Казанда яшәп, гармун ясау эше белән шөгыльләнәләр. Шуңа да, әлеге гармуннарны халык «Вараксин гармуны» дип йөртә башлый. Ни өчен гармунның шушы төрен үз иткән соң татар халкы? Әгәр дә Вараксин гармунының төзелешенә игътибар итсәк, без анда татарның халкыбыз меңнәрчә еллар уйнаган думбыра, кыл кубыз кебек традицион уен кораллары белән зур охшашлык күрәбез. Гармунның уң яктагы унике теле думбыраның беренче нәзек кылы кебек көй уйный. Сул ягында урнашкан баслары (бакасы) тоника-кварта тавыш аралыгына көйләнелгән. Думбыра һәм кыл кубызның да кыллары кварта аралыгына көйләнелә һәм уйнаганда бер тавышны (тоника) тотып тора. Шул рәвешле уйнаганда гармунда да, думбырада да бер үк төрле көй озатылышы (аккордлар) яңгырый. Ягъни гармунны тартканда – кварта дүртенче тавыш, ә кысканда – беренче тоник тавыш.

Тик, бу урында тагын бер бик әһәмиятле сорауга ачыклык кертик әле. Халыкта «русский строй» дип аталган гармуннарның мехларын ачканда бака ягында – тоник тавыш, япканда бишенче тавыш (квинта) ишетелә. «Немецкий строй» дип аталган гармуннарда нәкъ киресенчә: ачканда – бишенче тавыш, япканда тоник тавыш яңгырый. Ә менә Вараксин ясаган тальян гармуннарның бака ягында мехны ачканда

– тоник тавыш, япканда дүртенче тавыш (кварта) ишетелә. Бу охшашлык бүтән бер генә төр гармунда да юк. Вараксин гармунның бака ягына беренче тапкыр тоник тавыш (пискун) өсти. Вятка гармунын Вараксинга кадәр үк беренче тапкыр ясаган осталар Данила Нелюбин да, Степан Новосёлов та, Семён Шельпяков та Нократ (Вятка) буйларында киң таралган кыллы уен кораллары белән таныш булганнардыр, минемчә. Шул ук вакытта татар музыкасын да яхшы белгән булырга мөмкиннәр. Бу урында миндә бер шик тә туа. Вятка гармуны гомумән татар мохитенә махсус атап эшләнелмәдеме икән? Чөнки, 1883 нче елларда иң яхшы гармун ясаучы осталар бертуган Половниковлар да, бертуган Вараксиннар да Казанга күченеп киләләр һәм гармун ясау үзәге, акрынлап, Казанга күчә. Алардан соң гармун ясый башлаган татар осталары да әлеге алымны үзгәртмәскә тырышканнар, чөнки меңнәрчә еллар формалашкан татар музыка дөньясы өчен бу ясау алымы алыштыргысыз. Әлеге төр гармунны икенче төрле «тальян гармун» дип тә йөртәләр. Кайбер белгечләр «тальян» сүзе – «итальян», ә гармун сүзе шулай ук итальянча «һarmonia» сүзеннән алынган, диләр. Ә мин үзем талир, тальян, сафьян, бадиян сүзләре кебек татар сүзеннән килеп чыкмадымы икән, дип уйлыйм.

«Эскерипкәм, талиян,
Агачлары бадиян.
Кара әле талиянны,
Күрекләре каеган».
(Татар халык җыры)

Вараксиннар ясап тәкъдим иткән икенче төр гармунны да татар халкы үз итә. Бу төр гармуннарның да төзелеше шундый ук, тик музыкаль авазлар гармунның уң ягында да ачканда – бер төрле, япканда икенче төрле яңгырыйлар.

1934 елда Казанда гармун фабрикасы ачыла. Бу әлеге уен коралының татарлар арасында таралуына аеруча зур йогынты ясый. Фабрика каршында яшьләрне гармун ясарга өйрәтү курслары ачыла. Шулар арасыннан бик талантлы гармун ясау осталары үсеп чыга. Арчадан – Салих Вәлиев, Шәмәрдәннән – Михаил Титов, Балтачтан – Рамазан Әсхәтдинов, Сарманнан – Сәгетдин Камалиев, Казаннан – Илдус Җаббаров, Александр Голованов, Салих Шәйдуллин, Тәлгать Гыйззәтуллин һәм тагын күп кенә осталар, шушы курсларны тәмамлап фабрикада озак еллар эшләп киткәннән соң да гармун ясау сәнгате белән шөгыльләнүдән туктамыйлар. Әлеге осталар ясаган гармуннар сыйфаты буенча фабрикада эшләнгән гармуннардан күпкә өстенрәк, шуңа да аларга сорау зур була. Бу осталардан тыш, үзлегеннән өйрәнеп, Татарстанда һәм татарлар яшәгән бүтән төбәкләрдәге осталар да гармун ясау һөнәрен үзләштерәләр. Аларның хезмәтләре бәяләп бетергесез. Андыйлардан Самара өлкәсенең Иске Ярмәк авылында яшәгән Гали ага Гәрәевнең хезмәте аеруча хөрмәткә лаек. Санап киткән әлеге осталарның берсе дә инде арабызда юк. Авыр туфраклары җиңел булсын.

Аллага шөкер, гармун ясау сәнгате бүген дә дәвам итә. Теләгән кеше, мөмкинлегенә карап, яхшы сыйфатлы, зәвык белән эшләнгән гармуннарны үзендә булдыра ала.

Татарстан хөкүмәте 1996 елда, гармун ясау эшен тагын да үстерү максатыннан, НИОКР фонды аша Казан музыка уен кораллары фабрикасына акча бүлеп биргән иде. Әлеге акчаның бер өлешенә Казан авиация институты галимнәре Вараксин гармунының техник үзенчәлекләрен (металл планкаларның, телләрнең составына, тавыш резонаторларына һ.б. анализ ясап) өйрәнеп, зур гына фәнни хезмәт эшләп бирделәр. Бу эштә, ул елларда фабриканың директоры буларак, мин үзем дә катнаштым. Эш башында Татарстан авылларыннан Вараксин тамгасы сугылган һәм

чыннан да аны Вараксин ясаганына инанып, төрле-төрле биш гармун сатып алдык. Белгечләр шушы гармуннар нигезендә Вараксин гармуннарының тавышлары ни өчен көчле, тембрлары матур икәнен ачыкладылар. Әлеге галимнәрнең берсе Таһир Вәлиуллин соңыннан да уен коралларын өйрәнү, камилләштерү, ясау эшен дәвам итте. Ул шушы технология ярдәмендә фәнни нигезләп, халкыбызның гөслә, думбыра, ятаган, саз, сорнай кебек уен коралларын ясау эшен дә башлап җибәрде. Әлеге хезмәтнең бер данәсе миндә саклана.

Фабрика ябылгач, 2016 елда Казанда беренче тапкыр гармун ясау остаханәсе ачылды. Бу эшкә яшь, талантлы егет, гармун җене кагылган оста Айрат Харисов алынды. Ул ясаган гармуннарның һәрберсе сәнгать әсәренә тиң. Татарның иң дәрәҗәле гармунчылары да Айрат Харисов ясаган гармуннарга күчтеләр, аларда яратып уйныйлар.

Айрат Харисов Башкортстанның Борай районындагы Кәшкәләү авылында туып үсә. Уфада студент булып йөргән елларында ул удмурд милләтеннән булган атаклы гармун ясау остасы Җидеяр Мөхәяров дигән оста белән очраша. Менә шуннан башлана инде аның гармунга булган мәхәббәте. Айрат Харисов аннан соң остазы белән Яр Чаллы каласына күчеп килә һәм алар анда да гармун ясау эше белән шөгыльләнәләр, ә инде тагын берничә елдан Айрат Харисов Казанга килеп төпләнә һәм, җиң сызганып, гармун ясау эшенә тотына.

Яхшы, сыйфатлы гармун ясау – ул катлаулы хезмәт, зур осталык сорый торган шөгыль. Бер гармун ясау өчен генә дә меңнән артык деталь, төрле җайланмалар, эш кораллары кирәк. Тальян гармун өч өлештән тора: уң як өлеш, сул як өлеш һәм күрек (мех) өлеше. Уң якта бер генә рәт булып унике тел (клавиш), сул якта бас һәм аккордлар урнашкан. Тальян гармун күп очракта биш планкалы була. Планкаларны тоташ итеп җиздән, латуньнан ясаганнар. Гармунның тавыш чыганагы – шушы планкаларга беркетелгән җиз, көмеш, мельхиор, корыч пластинкалардан ясалган телләр. Алар уң як һәм сул як өлешләрнең эченә беркетелгәннәр. Күректән килгән һава агымы телне тибрәндерә һәм ул аваз чыгара башлый. Тавышның сыйфаты телләренең нинди материалдан эшләнүенә һәм дөрес көйләнелүенә бәйле. Телләр беркетелгән ике планка төп тавышларга көйләнелә, кечерәк ике планка төп тавыштан октавага югары, ә бишенче зур планка бер октавага түбән яңгырый. Димәк, гармунның бер телен басып күрекне тарткач, бер үк вакытта ике урта, ике югары, бер түбән тавышлардан торган биш тавыш чыга. Уйнаганда гармунның тавышын тагын да төрләндерү, баету өчен, һәр планкага да берәр регистр куелган. Уң як корпусның өстенә беркетелгән регистрларның берсен өскә күтәрсәң, махсус җайланма планкаларга беркетелгән телләрне каплый (глушить итә). Регистрларны үзең теләгәнчә ачып-ябып, унга якын тавыш тембрын көйләп була. Гармунның агачтан эшләнгән барлык кирәкле әйберләре (детальләре) кипкән каен агачыннан ясала. 1950-1960 нчы елларда гармун ясаучы бер останың: «Мич алдында яткан каен утын агачына да налог салып чыгып китәләр иде», – дип сөйләгәне истә. Димәк, өеңдә каен агачы булса, син – гармун ясаучы. Күрек электрокартоннан эшләнелә. Бүтән төр картоннар исә күрек ясау өчен яраксыз.

Казан гармун фабрикасында эшләнгән гармуннар 1960-1980 елларда үзлегеннән өйрәнүче яшьләр, үзешчән сәнгать коллективлары өчен алыштыргысыз уен кораллары булды, чөнки алар чыдам, уйнарга уңайлы, кибетләрдә сатуда бар, арзан иде. Фабрика осталары татар гармунын һәрвакыт камилләштереп тордылар. Озак еллар цех начальнигы булып эшләгән Салих ага Шәйдуллинның хезмәте зур булды. Ул гармунның тышкы кыяфәтенә, планкаларына, сул якта урнашкан механизмнарына



аеруча күп үзгәрешләр кертте. Шуңа да халыкта 12х3, 16х12 гармуннарына сорау зур иде. Фабрика гармуннары «ре мажор», «ля мажор», «ми мажор» тональностьларына көйләнелгән.

Аерым осталар эшләгән гармуннар арасында аеруча күп таралган тональностлар- «соль мажор», «до мажор», «ре мажор», «фа мажор».

«Гармунчы дигән даны бар, сөеп туймас яры бар», – дип җырлый безнең халык, үзенең гармунчыларын яратып. Гомумән, музыка коралында уйнаучылар – тормышта мәртәбәле кешеләр. Халык аларны яратып тыңлый, мактап сөйли, мәҗлестә дә, сәхнәдә дә аларның урыннары түрдә. Моннан йөз еллар элек үк инде халык күңеленә кереп калган Исмәгыйль Галиәкбәров, Хөсәен Йосыпов, Фәйзулла Туишев, Фәйзи Биккинин, Гали Җәмниханов, ә инде соңрак Рәшит Мостафин, Рөстәм Вәлиев, Флера Хөрмәтова һәм тагын күп кенә данлыклы гармунчыларыбыз белән халык горурлана, яшьләр алар уйнаган көйләрне бүген дә яратып уйный, тыңлый. Бу урында татар халкының беренче профессиональ виртуоз гармунчысы, Татарстанның халык артисты Фәйзулла ага Туишевны искә алу урынлы булыр.

Фәйзулла Кәбир улы 1884 елны Сембер өязенең Мәләкәс авылында туа. Кечкенә Фәйзулла биш яшендә гармунда уйнарга өйрәнә, ун яшендә исә якынтирә авылларда, шәһәрләрдә концертларда катнаша башлый. Аннан соң Мәскәү, Петроград, Урта Азия, Киев, ә инде соңрак Кытай, Япония, Германия, Америка һәм тагын башка илләрдә дә булып, дөнья халыкларын татар музыкасы белән таныштыра. Ил күләмендә данлыклы артистлар белән ул зур концертларда катнаша, җырлаганда

Ф.Шаляпинга да кушылып уйнавы билгеле. Халык арасында «Гармунчылар короле» дигән даны тарала.

Фәйзулла Туишев 1939 елда халык музыка уен коралларында уйнаучыларның Бөтенроссия смотр-конкурсында катнашып, татар музыкантлары арасында беренче тапкыр дәрәҗәле икенче урынны ала. Бу бик мәртәбәле җиңү, чөнки әлеге бәйгедә Россиянең иң данлыклы музыкантлары катнаша. Аның исемен мәңгеләштереп, 1988 елда Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы гармунчыларның Фәйзулла Туишев исемендәге конкурсын булдырды. Ике елга бер тапкыр үткәрелә торган әлеге конкурста җиңүчеләренең күбесе талантлы яшьләр, милләтебезнең киләчәге.

Югарыда санап киткән профессиональ гармунчыларыбыз да, бүгенге яшь буын гармунчылар да бер тальян гармунда гына түгел, барлык төр гармуннарда да уйнаганнар һәм уйныйлар. Өч телле концерт гармуныннан башлап ун-унике телле «русский строй» дип аталган Вараксин, Саратский, хромка гармуннарында, баянда аеруча яратып уйный безнең халык.

Уен коралы булмаган очракта әле яшьләр кичке уеннарда, аулак өйләрдә, мәҗлесләрдә гармунга охшатып такмаклар әйтеп җырлап, биеп тә алганнар. Әйтик, тальян гармунга охшатып такмак әйтү:

«Әңгер-гер-гер, күә-күә,
Әңгер-гер-гер, күә-күә».

«Әңгырт, гырт-гырт, кыңгырт чак,
Җитте җырлап биер чак».

«Тиллин-тилли, тиллин-тилли,
Тиллин-тилли, тилли-ли, лә».

Саратов гармунына охшатып әйтү:

«Кма теке, кма-кма, кмая,
Кма теке, кма-кма, кмая».

Тальян гармунда уйнауның бабаларыбыздан килгән үзенә генә хас үзенчәлекләре бар. Бу уен үзенчәлекләрен бүтән бер генә гармунда да, хәтта баянда да уйнап күрсәтеп булмый. Аларны нотага язып калдыруы да бик читен. Иң дөрес юлы – вакытында өлкән гармунчылардан өйрәнеп, яшь буынга өйрәтеп калдыру. Шушындый эзлеклелек булганда гына уен коралының эшләнелеше дә, уен алымнары да чарлана, формалаша, камилләшә генә. Халык аны вакыт үтү белән тагын да баета төшә. Халыкның ул йөрәк бәгыренә үтеп керә башлый. Менә шушы вакыт аралыгын уңышлы үткән уен коралы гына гомумхалык уен коралы дип аталырга хаклы. Гармун, һичшиксез, бу вакыт аралыгын үтте. Уйнаучыларның күплеге буенча да аның белән тиңләшерлек уен коралы юк. Халык уен коралларында уйнаучыларга кытлык заманда бер «Уйнагыз гармуннар» республика фестивалендә генә дә ике меңнән артык гармунчыларны бер мәйданга җыя алабыз икән, бу инде – татарның милли байлыгы. ■

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе

КИТАПХАНӘ НӘШЕР ИТКӘН БАСМАЛАР

Фәнни, белешмә, мәгълүмати һәм башка төр әдәбият нәшер итү эше Милли китапханә тарихында электән үк килә, аңа йөкләнгән бурычларның үтәлешенә һәрдаим ярдәм итә. Нәшрият басмаларының репертуарын киңәйтү зарурлыгы, аларның сыйфатына карата югары таләпләр куелу китапханәдә махсус бүлек булдыру ихтыяҗын тудырды. 1996 елда Татарстан Республикасының Милли китапханәсе үзенең «Милли китап» дип аталган нәшриятын оештырды.

«Милли китап» нәшрияты продукциясе гаять күптөрле һәм үз укучыларының ихтыяҗын канәгатьләндерүгә генә юнәлдерелмичә, китапханә эшчәнлегендә булган көндәлек бурычларны үтәү максатын да күз алдында тота. Укучылар өчен төрле жанрдагы библиографик кулланмалар, дайджестлар, истәлекле һәм онытылмас даталар календарьлары, белешмә һәм фәнни-популяр әдәбият һ.б. нәшер ителә. Китапханә эше белгечләре өчен – методик-библиографик ярдәмлекләр, китапханә эшендәге алдынгы тәҗрибәгә аналитик күзәтүләр, фәнни хезмәтләр җыентыклары, китапханәдә үткәрелә торган социологик яки башка төр тикшеренү материаллары, һөнәри матбугат басмалары һ.б.

Милли китапханә басмалары арасында методик ярдәмлекләр һәм төрле жанрдагы библиографик кулланмалар беренче урында тора. 1996 елдан 2015 елга кадәр барлыгы 307 исемдәге басма дөнья күргән, аларның 86сы – татар, 221е – рус телендә. Методик материаллар 245 исемдә, ягъни барлык басмаларның 80 процентын тәшкил итә. Методик ярдәмлекләр нәшер итүгә зур игътибар бирелүне Милли китапханәнең республика Мәдәният министрлыгы буйсынуындагы китапханәләр өчен методик үзәк булып торуы белән аңлатырга кирәк.

Китапханә методик басмаларының зур күпчелеге аерым шәхесләргә – барыннан да бигрәк, татар әдәбиятының, сәнгатенең, мәдәниятенең күренекле эшлеклеләренә багышланган, алар, нигездә, методик-библиографик сыйфаттагы китапчыклар. Татарстан Республикасы һәм Россиянең төрле төбәкләре китапханәләрендә Ибраһим Газига, Габделҗәббар Кандалыйга, Галимҗан Ибраһимовка, Кол Галигә, Ризаэддин

Ахыры. Башы журналның 2017 елгы 10 нчы санында.



Фәхреддингә, Заһир Бигиевкә, Гаяз Исхакыйга, Әхмәтһади Максудига, Галиәсгар Камалга, Нәкый Исәнбәткә, Габдулла Тукайга, Салих Сәйдәшевкә, Хәсән Туфанга, Һади Такташка, Гомәр Бәшировка, Илдар Юзиевкә, Шәйхи Маннурга, Нур Баянга, Мирхәйдәр Фәйзигә, Аяз Гыйләҗевкә, Мөсәгыйть Хәбибуллинга, ӘхмәтЕрикәйгә, Фатыйма Ильскаяга һәм татар халкының башка мәшһүр ул-кызларына багышланган методик басмалар киң кулланыла.

«Татарстан: истәлекле һәм онытылмас даталар календаре» – Милли китапханәнең иң популяр басмаларыннан берсе. Мондый календарьлар 1950 нче еллар ахырыннан башлап чыгарыла. Ул туган якны өйрәнү эшчәнлегендә китапханәчеләр, укытучылар, төбәк тарихчылары, журналистлар тарафыннан киң кулланыла. Календарьның электрон варианты Милли китапханә сайтына урнаштырылган.

Шәхесләргә багышланган библиографик күрсәткечләр «Татар әдипләре» дигән традицион сериядә нәшер ителә. Әлеге уникаль библиографик басмалар укучыга милли мәдәнияттәге теге яки бу күренекле шәхес турында тулы мәгълүмат җиткерә. Нәшрият репертуарында күргәзмә каталоглары, фондтагы тупланмалар каталоглары, социологик тикшеренүләр нәтиҗәләрен тасвирлаган җыентыклар да әһәмиятле урын алып тора.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе уникаль китап тупланмаларына ия. Соңгы вакытта аларны таныту юнәлешендә күркәм гамәлләр кылына. 2004 елда «Мәрҗани китапханәсе» дип аталган фәнни-библиографик җыентык (төзүчесе – Р.Ф.Мәрданов) нәшер ителгән иде. Күпчелек басма каталогларның автор-төзүчеләре – китапханә хезмәткәрләре: «Каталог библиотеки Второвых» (автор-төзүчесе – Г.Г.Шаһиәхмәтова), «Академик Ә.Г.Кәримуллин китапханәсе» (төзүчесе – Н.Ә.Асылкаева), «Библиотека Ивана Александровича Сахарова» (төзүчесе – Л.П.Юревич) һ.б. Алар Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана торган китап тупланмаларына тулы тасвирлама бирәләр.

«Милли китап» нәшрияты 2008 елдан башлап «Татар археографиясе» дип аталган фәнни-популяр җыентыклар сериясен нәшер итеп килә, аның максаты – Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана торган әдәби, тарихи, документаль һәм башка төр язма истәлекләрнең текстларын бастырып чыгару. Хәзерге вакытка әлеге сериядән 23 җыентык дөнья күрде, барысын да басмага китапханәнең фәнни хезмәткәре, археограф һәм текстолог Раиф Мәрданов әзерләде.

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе 1996 елдан башлап «Китапханә хәбәрләре» дип аталган фәнни-гамәли журнал чыгара. Ул татар һәм рус телләрендә елга ике тапкыр дөнья күрә, республикадагы китапханәләрнең эшчәнлеген киң яктырта. Аның сәхифәләрендә китапханәчеләрнең, библиографларның, методистларның, китапханәләр җитәкчеләренең һәм гап-гади хезмәткәрләренең, фән эшлеклеләренең, шулай ук язучыларның һәм публицистларның, башка төр иҗат әһелләренең мәкаләләре басылып чыга.

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе нәшер иткән басмалар, аның эшендәге барлык мөһим юнәлешләрне колачлап, китапханәчелек, мәгълүмат ресурсларын булдыру, фәнни-тикшеренү, методик булышлык күрсәтү, китапханәләрдә туган якны өйрәнү, милли мәдәният һәм сәнгатьне таныту өлкәләрендәге киңкырлы эшчәнлекне чагылдыра. ■

СЕНТЯБРЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● 27 августта язучылар Рәдиф Сәгъди, Хәбир Ибраһим, Фирдәвес Зариф һәм Марат Закир Мамадышта булып, район хакимияте һәм җәмәгатьчелек белән очрашты.

● 28 августта Яшел Үзән шәһәренең Татар милли китапханәсендә шагыйрә Эльмира Шәрифуллина, прозаик Марат Әмирханов, прозаик һәм шагыйрь Фирдәвес Зариф белән очрашу узды. Очрашуны китапханә мөдире Юлия Фәрит кызы Борһанова алып барды.

● Август ахырында һәм сентябрь башында язучылар һәм журналистлар Камил Кәримов («Казан утлары»), Алмаз Хәмзин («Чаян») һәм Ләбиб Лерон («Безнең мирас») Минзәләдә (Минзәлә картлар йортында һәм район китапханәсендә, шулай ук Тулыбай, Югары Тәкермән, Коноваловка, Әтрәкле, Иркәнәш, Кадрәк, Яңа Мәлкән, Аю һәм Бикбау авылларында), Актаныштa (Пучыдагы картлар йорты, Уразай) һәм Мөслимдә («Мизгел» яшьләр үзәге, Метрәй, Тугаш, Әмәкәй, Теләнче (Октябрь), Татар Буләр, Олы Чакмак, Баек, Яңа Усы) булып, халык белән белән очрашты.

● 10-11 сентябрьдә ТР Фәннәр академиясендә Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оешуга 80 ел ел тулуга багышланган чаралар үткәрелде. Анда чит илләрдән һәм Россиянең төрле төбәкләреннән күренекле галимнәр катнашты. ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, ТР Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева, институт галимнәрен юбилей белән котлап, аларга бүләкләр тапшырды.

● 11 сентябрьдә Татарстанга, архитектура өлкәсендә халыкара премия җиңүчеләрен бүләкләү өчен, принц Кәрим Ага Хан килде.

«Казан» аэропортында кунакны Татарстан Республикасының Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев каршы алды. 12 сентябрьдә М.Шәймиев һәм Кәрим Ага Хан Болгар тарихи-археологик комплексында булды. 13 сентябрьдә Казанның М.Җәлил исемендәге татар дәүләт академия опера һәм балет театры бинасында Халыкара премиянең җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы узды.

● 12-13 сентябрьдә Томск шәһәрендә «Татар шәһәр бистәсе: үткәне, бүгенгесе һәм үсеш перспективалары» (Россия Федерациясе шәһәрләрендә татар бистәләрен саклау стратегиясе) исемле Бөтенроссия татар төбәген өйрәнүчеләр форумы булды. Әлеге чарада «Безнең мирас» журналы хезмәткәре Ленар Гобәйдуллин да катнашты.

● 15 сентябрьдә Казанның Архангел зиратында театр әһелләре Кәрим Тинчурин каберенә чәчәкләр салды. Ш.Мәрҗани мәчете имам-хатыйбы Исмәгыйль хәзрәт Биккинин һәм зыялыларыбыз мәшһүр язучыбыз рухына дога кылды.

● 16-17 сентябрьдә Мөслим районында татар әдәбияты көннәре булып узды. Чарада Мөслим муниципаль район хакимияте башлыгы Рамил Муллин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, язучылар һәм шагыйрьләр Ф.Садриев, М.Галиев, Г.Морат, Л.Лерон, Р.Рахман, Ф.Сафин, В.Нуриев, Ф.Галимуллин, В.Имамов, Ш.Җиһангирова, М.Әмирханов, Г.Гыйльманов, Г.Рәхим, Р.Хәбибуллина, Ә.Шәрифуллина, Ә.Ситдыйкова һәм башкалар катнашты.

● 27 сентябрьдә Казанның «Корстон» мәдәни-күңел ачу үзәгендә Татарстан Язучылар берлеге оешуга 85 ел тулуга багышланган тантаналы кичә узды.

● 30 сентябрьдә К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасында, Татарстанның халык шагыйре, республикабызның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты,

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Зиннур Мансуровка 70 яшь тулу уңаеннан, «Җәрәхәтле йөрәк җылырак» дип исемләнгән иҗат кичәсе узды. ■

Мирасворд

1902-1921 елларда Казанда эшләгән нәшрият

Атаклы тимер юл

Җәләлетдин ... (урта гасыр фарсы шагыйре)

Монарх

Җиләннең бер төре (иск.)

Үрнәк

Шагыйрь ... Аймәт

Күчмә мәгънәдә кулланылган сүз яки әйтелмә

... Цзэдун

Чәкчәкнең икенче атамасы

Бертольт ... (алман шагыйре, драматург)

Кәрим Тинчурин драмасы

Гаскәри хезмәткә иң беренче барырга тиешле ир кеше (иск.)

Борынгы грек шагыйре

Муса ... (башкорт шагыйре)

Урта таш гасыры

... Коләхмәтов

Янартау авызы

Тукыма бизәге, чүпләм

Нәүрәп

Бергәләп бушка эшләү

Кыргыз эпосы

Нурихан Фәттах романы

Әдип ... (татар шагыйре, прозаик)

Парагвай чәе

...-мачта

Әфганстанда 1920-1929 елларда коелган алтын акча

Азов диңгезенә коючы елга

Данлы исем, яхшы ат (иск.)

...-йолт

... Миндияр

Алман фәлсәфәчесе

Конфуций Ватаны

Яхшы, әйбәт (диал.)

Шахмат буенча 12 нче дөнья чемпионы

Шагыйрь Зыя ...

Соры корт (диал.)

Беләп (иск.)

Талкыш ... (татлы ашамлык)

Тутый кош та, маймыл да

Рәис Габдулла төзеде.

9 нчы санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: Илсөяр, сәмруг, до, «Әманәт», ирбис, «Әнбия», Клавдий, эргә, Раил, рети, дәф, «Чам», тарпан, пан, Ге, чавыл, «Бердәмлек», пырак, нәхү, лай, «Урал», пьеса.
Өстән аска: Нур, «Милләтчеләр», Аида, Ха, Ихсанова, Дәүли, драп, «Самат», аем, әйрән, Яһудин, чеп, горбәт, Гакыйль, Бигичев, «Ра», ияр, алыс, «Әлмәлек».

«Сәйяр»:
Г.Кариев (алда),
К.Тинчурин,
З.Солтан,
Г.Мангушев.
1916 ел

«Безнең мирас» елъязмасы /октябрь

100 ел элек (1919)

Октябрь башында Казанда «Шәрык консерваториясе» ачыла.

100 ел элек (1919)

«Эш» газетасында Афзал Шамовның «Анда... монда...» исемле беренче шигыре басыла.

100 ел элек (1919)

Оренбургта артист һәм журналист Габдерахман Мангушев (1887) вафат була.

95 ел элек (1924)

Казанга А.В.Луначарский килә һәм опера театрында «Тормышның мәгънәсе һәм бәхет нәрсәдә?» дигән темага лекция сөйли.

95 ел элек (1924)

«Кызыл Татарстан» газетасында – Хәсән Туфанның «СССРны таныйлар», «Яшь юксыл» газетасында исә Әхмәт Ерикәйнең «Яшь игенче җыры» исемле шигырьләре басылып чыга.

90 ел элек (1929)

Казан шәһәр партия оешмасы активының солтангалиевчелек мәсьәләсенә багышланган җыелышы була. Җыелышта «Солтангалиевчелекнең тарихи тамырлары, сабаклары һәм Татарстан партия оешмасы алдындагы бурычлар» дигән темага доклад белән Өлкә Комитеты секретаре М.А.Разумов чыга.

90 ел элек (1929)

Мәскәүдә Художество фәннәре дәүләт академиясендә татар бүлеге эшли башлый. Беренче утырышта Девишевның «Казан татарларының чигешле сугылма әйберләрен сәнгать күзлегеннән тикшерү тәҗрибәләре» дигән темага докладı укыла.

85 ел элек (1934)

«Литературная газета»да Г.Тукайның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасыннан «Похождения Карахмета» исеме белән өзек (В.Виткович һәм Д.Осин тәрҗемәсе) басылып чыга.

85 ел элек (1934)

28 октябрьдә Уфа шәһәрендә Мәҗит Гафури (1880) вафат була.

80 ел элек (1939)

Совет Язучылар союзы Милләтләр комиссияләренең татар комиссиясе утырышында М.Җәлил татар әдәбиятының торышы һәм Татарстан Язучылар союзы үткәрә торган чаралар турында доклад ясый.

*Журналга **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■



СОДЕРЖАНИЕ. ОКТЯБРЬ 2019

И останется в мире слово моё…: Ахмат Саттар.

Историческое наследие: «Сююмбике». О.Иванова; «Этруски – римские умельцы». С.Шамси; «День памяти». Х.Бадиги; «Кто такой Лутфи Исхаки?» Ч.Сафиулла; «Духовная жизнь татар 1920-х годов». И.Тагиров; «Археологический дневник». М.Уусманов.

Татарский мир: «С чего начинается Родина?» Э.Шарифуллина; «И художественно, и исторически…». А.Шарипов; «О, ты могучая книга…» Н.Гилязова.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов.

Литературное наследие: «Хусаин мирза». Ф.Бурнаш; «Кто такой Карахмет?» Ф.Кутлу.

В глубине памяти: «История одной фотографии». А.Зарипов; «Школы и одноклассники». Л.Лерон; «В памяти, до сих пор в памяти!»

Художественное наследие: «Древние национальные музыкальные инструменты». Р.Гилязов.

На страже памяти: «Национальная библиотека Республики Татарстан».

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT. OCTOBER 2019

There will be left my word in the world…: Akhmat Sattar.

Historic heritage: «Suyumbike» by O.Ivanova; «The Etruscans are the Roman craftsmen» by S.Shamsi; «Commemoration day» by Kh.Badigi; «Who is Lutfi Iskhaki?» by Ch.Safiulla; «The spiritual life of the Tatars of the 1920s» by I.Tagirov; «Archeological diary» by M.Gusmanov.

Tatar world: «What from does the mother land begin?» by E.Sharifullina; «And artistically, and historically…» by A.Sharipov; «Oh, the great book you are…» by N.Gilyazova.

Religious heritage: «Islamic world» by Gabdurashit Ibragimov.

Literary heritage: «Khusain mirza» by F.Burnash; «Who is Karakhmet?» by F.Kutlu.

From the deepest store of memory: «The history of one drawing» by A.Zaripov; «Schools and classmates» by L.Leron; «Still keeping in the memory, still keeping!».

Creative heritage: «The ancient Tatar national musical instruments» by R.Gilyazov.

On the guard of the memory: «The National library of the Republic of Tatarstan».

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation's life.

«Крутушка». 1981.
Картон, майлы буяу



Николай Индюхов

Рәссам Николай Петрович Индюхов 1932 елның 17 апрелендә Орел өлкәсенең Протасово авылында туган. Казан рәсем сәнгате училищесын (1965 ел) тәмамлаган. 1974 елдан СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы. ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1999 ел), Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе (2006 ел).

«Яңа уңыш ашлыгы». 1971-1972.
Картон, майлы буяу

«Ашлык келәтендә». Фрагмент. 1977. Киндер, майлы буяу

АЛДАГЫ САНДА УКЫГЫЗ:

Рәсемдә (уңнан сулга): М.Җәлилнең кызы Чулпан, хатыны Әминә Җәлилова, Андре Тимерманс һәм аның хатыны. «Казан» кунакханәсе. 15 февраль, 1966 ел. М.Шакирҗанов фотосы
(Ә.Фәйзрахманов. «Гаделлек барыбер җиңде».)

Дәрдемәнднең барланмаган иҗат үрнәкләре. **Лирон Хәмидуллин**
Күл – күз яше (хикәя). **Сәгыйть Сүнчәләй**
Сириннең Халыкара сугышка каршы конгресста сөйләгән беренче рече (поэма). **Сирин**
Дин кушканча яшәде. **Нәкыя Гыйләҗева**
Гаделлек барыбер җиңде. **Әгъзам Фәйзрахманов**
Көрәшчеләр. **Рәдиф Сәгъди**

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
www.beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:
- **uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә**
- **редакциядә**
- **podpiska.pochta.ru сайты ярдәмендә электрон версия**

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.